ИШЕТМӘСКӘ ТАВЫШЫҢНЫ

Яңа закон күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салырмы?

> 7

ОНЫТЫРЛЫК ТҮГЕЛ

Сугыш чорында тылдагыларның батырлыклары

> 16

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА:

«Шагыйрь булу – Ходай бүләге»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 84 (28857) | Җомга | 17 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

media.kpfu.ru

КЕМ БУЛЫРГА?

ЧЫГАРЫЛЫШ УКУЧЫЛАРЫ – КИЛӘЧӘКНЕ САЙЛАУ АЛДЫНДА

Күңел тартсынмы, кесә чыдасынмы? Чыгарылыш укучыларының «урак өсте» бара. Имтихан белән сыналганнар хәзер инде уку йортын сайлый. Шунысы куандыра: югары уку йортларында бюджет урыннары артты. Алар барысына да җитәрме? Киләчәк өчен нинди һөнәрләр кирәк? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда соңгы 30 ел эчендә әйләнә-тирә мохиткә чыгарылучы зарарлы матдәләр күләме 21,4 процентка кимегән. Экология министры Александр Шадриков белдергәнчә, һаваның елдан-ел чистаруы күзәтелә. Шушы вакыт эчендә машина төтене, 72,6 процентка кимеп, 437 мең тоннадан 119 мең тоннага калган.

Бу – экологик чиста транспорттан һәм ягулыктан файдалану нәтиҗәсе. Электр транспортын үстерү һаваны елына 22,8 мең тоннага кимрәк пычрату мөмкинлеге бирә. Утыз ел эчендә зарарлы матдәләр чыгаруны ягулык сәнәгате – 2 тапкыр диярлек, җылылык энергетикасы 5 тапкыр киметкән.

Россия Президенты Владимир Путин күпбалалы гаиләләргә көллиятләрдә түләүле уку өчен компенсация бирү мөмкинлеген карарга кушкан. Кремльнең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, бу мәсьәлә 1 августка кадәр өйрәнелеп, хәл ителергә тиеш. Шуннан соң ул алты айга бер тапкыр каралачак. Уку өчен түләүне өлешчә компенсацияләү планлаштырыла. Моны хәл кылу субъектлар җитәкчеләре өстенә төшәчәк.

Россиядә доллар, евро һәм башка валюталар тыелмаячак. Бу хакта Үзәк банк башлыгы Эльвира Нәбиуллина Петербург халыкара икътисади форумында белдергән. Шул ук вакытта, аның әйтүенчә, валюта кертемнәрен конфискацияләү дә планлаштырылмый.

Татарстанда Бердәм дәүләт имтиханнарының тәүге нәтиҗәләре билгеле. Рус теле һәм әдәбияты, рус теле, химия буенча БДИне 8 бала 200 баллга тапшырган. Казан шәһәре 94 нче гимназиясеннән Дәүләтшина Лия, Казан шәһәре 26 нчы лицееннан Егорова Амалия, Казан шәһәре 18 нче гимназиясеннән Мөслимова Эвелина рус теле һәм әдәбияты буенча иң югары балл җыйган. Ә инде Бөгелмә районы 2 нче лицееннан Абдуллаева Азизә, Минзәлә 2 нче мәктәбеннән Дяшкина Дарья, Казан шәһәре 83 нче лицееннан Ибраһимова Румия, Бөгелмә районы 5 нче мәктәбеннән Рыжикова Маргарита, Чаллы шәһәре 26 нчы гимназиясеннән Сәйфуллина Альбина рус теле һәм химия фәннәрен 200 баллга тапшырган.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) быел коронавирусның чираттагы күтәрелеше булачагын күздә тота. ВОЗның Россиядәге вәкиле Мелита Вуйнович белдергәнчә, бу вирус йоктырмыйча калган һәм прививка ясатмаган кешеләрнең күп булуына бәйле. Әмма Вуйнович сүзләренә караганда, вирусның кайчан көчәеп китәчәген төгәен генә әйтү кыен. Моннан тыш быел грипп эпидемиясенең киңрәк колач җәюе көтелә. Шул сәбәпле ул өлкәннәр, иммунитеты начар кешеләр, йөкле хатын-кызларга игътибарны көчәйтергә тәкъдим иткән.

Сүз уңаеннан, Татарстанда инде өч атна рәттән коронавирустан үлем-китемнәр күзәтелми. Соңгы тапкыр 25 майда ковидтан 2 кеше үлгән.

Районнарда ни хәлләр?

Кукмара

Татарстан тарихында тәүге мәртәбә районда бер тәүлектә 400 тонна сөт савып алуга ирешелде. Бу уңайдан район башлыгы Сергей Димитриев исеменә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановтан телеграмма килеп иреште. «Бүген, безнең ил катлаулы глобаль каршылыклар алдында торганда, бу җитештерү нәтиҗәсе һәм бигрәк тә сезнең хезмәт сөючәнлегегез, туган ягыгызга тугрылыгыгыз, уртак зур максатка ирешүдә бердәмлек үрнәге бик зур әһәмияткә ия. Сез актив, җайга салынган, профессиональ эшегез белән азык-төлек иминлеген тәэмин итүгә, республикабыз һәм бөтен илебезнең агросәнагать комплексы потенциалын арттыруга мөһим өлеш кертәсез. Татарстаныбыз һәм бөтен илебез өчен әһәмиятле булган олы хезмәтегез өчен зур рәхмәт белдереп, яңаданяңа уңышлар телим сезгә», – диелә телеграммада.
(«Хезмәт даны»)

Мөслим

Михайловка авылында Чаллының 5 нче номерлы шәһәр хастаханәсенең «мобиль комплексы» килеп, эндокринолог, невролог, онколог, кардиолог, хирург, гинеколог, окулист, уролог бирелдә яшәүчеләрнең сәламәтлеген тикшерде. Июнь башында белгечләр Иске Карамалы авылында эшләде. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының «Мобиль поликлиника» проекты «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты кысаларында тормышка ашырыла. Хәзерге вакытта мобиль поликлиникалар берничә районда эшли.
(Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте)

Зәй

Зәйдә районның элекке җитәкчесе Ринат Фәрдиевне искә алдылар. 15 июньдә аңа 66 яшь тулган булыр иде. Искә алу чарасы аның исемен йөрткән татар гимназиясенә истәлек тактасы ачудан башланды. «Районда ул башлаган эшләр дәвам итә. Киләчәккә матур эш-гамәлләр корган иде. Аның белән булган хәтер-хатирәләр безнең күңелләрдә. Без аны онытмыйбыз», – диде районның хәзерге башлыгы Разиф Кәримов. Истәлек тактасын ачканнан соң, Ринат Фәрдиевне искә алу аның исемен йөрткән ял паркында дәвам итте.
(«Зәй офыклары»)

Буа

Районда биш айда туучылар да, үлүчеләр дә, өйләнешүчеләр дә кимегән. ЗАГС бүлегеннән алынган мәгълүматларга караганда, быел ел башыннан алып май ахырына кадәр районда 77 бала туган. Бу былтыргының шул чорындагыдан 4кә ким. Шул ук дәвердә 259 үлем очрагы теркәлгән. Бу сан былтыргы шул вакыт белән чагыштырганда 63кә ким. Никахлашучылар саны да алдагы елдагы гыйнвар – май күрсәткече белән чагыштырганда минус тамгасы белән. Ягъни быел 44 пар законлы өйләнешкән, былтыр шул чорда 67 булган.
(«Байрак»)

ПИТЕРДА КИЛЕШТЕЛӘР

Төбәк башлыклары белән очрашу, мөһим килешүләр төзү, яңа хезмәттәшлек юлларын барлау... Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Санкт-Петербургка эшлекле сәфәре әнә шуннан гыйбарәт иде. Алда телгә алынган очрашу-килешүләрнең барысы да Санкт-Петербургта үткән икътисади форум кысасында узды.

tatarstan.ru

Очрашулар

Президент иң элек **Архангельск өлкәсе** губернаторы Александр Цыбульский белән очрашты. Очрашу барышында ике арадагы хезмәттәшлекнең яңа юллары барланды. Рөстәм Миңнеханов белдерүенчә, Татарстан йөк машиналары, суднолар төзелеше, цифрлаштыру, фармацевтика юнәлешләрендә хезмәттәшлекне киңәйтү яклы. Александр Цыбульский, үз чиратында, Рөстәм Миңнеханов белән соңгы очрашудан соң төбәкара багланышларның активлашуын искәртте. Очрашу барышында Татарстан белән Архангельск өлкәсе арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешүне гамәлгә ашыру буенча 2022–2024 елларга чаралар планы да имзаланды.

Санкт-Петербургта Рөстәм Миңнеханов **Коми Республикасы** башлыгы Владимир Уйба белән дә очрашты. Татарстан Президенты сүзләренә караганда, бүген ике төбәк арасында товар әйләнеше 3,5 миллиард сум тәшкил итә. «Безнең эре машина төзелеше оешмалары, нефть, нефть химиясе тармакларында хезмәттәшлекне үстерү өчен мөмкинлекләр зур. Ике төбәк арасында товар әйләнеше 3,5 миллиард сум тәшкил итә. Аны тагын да арттырып, хезмәттәшлек өчен яңа юнәлешләр табарбыз дип өметләнәм», – диде Рөстәм Миңнеханов. Аерым алганда, Коми Республикасына Татарстанның машина төзелеше продукциясен, медицина җиһазларын кертү, суднолар төзелеше тармагында хезмәттәшлек итү мөмкинлеге карала. Коми башлыгы Татарстаннан вертолетлар сатып алырга теләүләрен дә белдерде. Аннары Рөстәм Миңнеханов белән Владимир Уйба хезмәттәшлек турында килешү имзалады.

Килешүләр

Петербург халыкара икътисади форумы кысасында тагын берничә мөһим килешү төзелде. Шуларның берсе Татарстан Хөкүмәте белән «Россия – мөмкинлекләр иле» оешмасы арасында имзаланды. Бу килешү талантлы яшьләргә ярдәм итү буенча уртак эшнең яңа юлларын табарга, уртак бәйгеләр, акцияләр һәм чаралар үткәрергә мөмкинлек бирәчәк. **«Россия – мөмкинлекләр иле»** платформасы 26 төрле проект, олимпиада һәм бәйгене берләштерә. «Татарстан әлеге платформа белән актив хезмәттәшлек итә. Республикада «Синең йөрәш», «Зур тәнәфес», «Россиянең ел студенты», «Россиянең студентлар язы», «Мәдәни код», «Цифрлы алга китеш» кебек зур проектларны күп тапкыр оештырдык. Анда 252 меңнән артык татарстанлы катнашты, 1801е бәйге һәм олимпиадаларда җиңүчеләр арасына кергән. «Россия – мөмкинлекләр иле» платформасы – үзеңне күрсәтү, үз сәләтеңне бәяләү мөмкинлеге. 2022 елда без Казанда бөтен илдән иң яхшы IT-белгечләрне җыябыз, Иннополис базасында ясалма интеллект буенча Бөтенроссия хакатоны уздырачакбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Көн дәвамында төзелгән килешүләрнең чираттагысы Татарстан Президенты белән **«Почта Банк»** акционерлык җәмгыятенең идарә рәисе Александр Пахомов тарафыннан имзаланды. Бүген әлеге банк республиканың барлык районнарында эшли. 300 авылда исә ул бердәнбер кредит оешмасы булып тора. «Әлеге банк һәр авылдагы почта бүлекчәсендә эшләргә тиеш», – диде Президент.

Тормышка ашыру дигәннән, быел башкалада тагын бер зур чара көтелә. Санкт-Петербургта узган икътисади форум кысасында 2022 елда Казанда сәнәгать төзелеше өлкәсендә **II Халыкара һөнәри осталык чемпионатын** оештыру буенча хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Аны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия торак һәм төзелеш министры Ирек Фәйзуллин белән атом энергиясе буенча «Росатом» дәүләт корпорациясенең генераль директоры Алексей Лихачев имзалады. Казанда узачак Чемпионатта 23 илдән килгән вәкил катнашачак. «Халыкара чемпионат үткәрү яңа технологияләр һәм компетенцияләр белән танышырга, иң мөһиме – бу юнәлештә иң яхшыларны табарга мөмкинлек бирәчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан белән **«ВК компаниясе»** арасындагы килешү белем бирү һәм фәнтехника тармагында хезмәттәшлекне күздә тота. Килешү кысасында «ВКонтакте» челтәре ярдәмендә дәүләт порталларын кулланучылар, дәүләт хезмәтләре күрсәтү сервислары белән кызыксынучылар санын арттырырга җыеналар.

Форум кысаларында **«Бөек Идел юлы» төбәкара туризм проектын** гамәлгә ашыру буенча хезмәттәшлек турында да килешү имзаланды. Туризм буенча федераль агентлык, Татарстан, Мари Иле Республикасы, Ульяновск өлкәсе Хөкүмәте, Самара өлкәсе һәм Чуашстан Республикасының Министрлар Кабинеты арасында төзелгән әлеге килешү төбәкара елгаларда пассажирлар йөртү системасын торгызуны күздә тота.

Рөстәм Миңнеханов белән **«Газпром нефть»** оешмасының башкарма директоры Александр Дюков имзалаган килешү кысаларында исә нефть-газ өлкәсендә хезмәттәшлек итү планлаштырыла. Очрашуда «Газпром нефть» һәм «Татнефть» оешмалары арасында робот техникасы буенча тармак компетенцияләре үзәген булдыру, «Газпром нефть» һәм «Иннополис» махсус икътисади зонасы арасында инновацион эшчәнлек өлкәсендә стратегик хезмәттәшлек турында килешү дә имзаланды.

Утырышлар

Петербург халыкара икътисади форумы кысасында узган **панель сессиясе** утырышында җирлекләрне үстерү турында фикер алыштылар. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, җир һәм күчемсез милек турында Бердәм мәгълүмат базасын сынау проекты нәтиҗәлелеген раслады.

Форум кысаларында Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә **Россия Дәүләт Советының Төзелеш, ТКХ, шәһәр тирәлеге юнәлеше буенча комиссия** утырышы да узды. Татарстан Президенты 2019 елда Дәүләт Советы Президиумы утырышында кабул ителгән карарларны тормышка ашыру өчен зур эш башкарылганын әйтте. Өлешләп төзүдә эскроу счетка күчү – шуларның иң зурысы. Бүген илдәге торакның 83 проценты яңа кагыйдәләр буенча төзелә. Моннан тыш, алданган өлешчеләр проблемаларын хәл итү кысасында тиешле фонд булдырылган. Ташламалы ипотека программасы кабул ителгән. «Программаны ел ахырына кадәр озайту турында карар кабул иткән өчен Россия Президенты Владимир Путинга рәхмәт белдерәсем килә», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты территорияләрне комплекслы үстерү турында закон кабул ителүенә дә игътибар итте. Республикада өстәмә рәвештә 2,5 млн квадрат метр яңа торак төзергә мөмкин булачак. «Бу чараларның барысы да узган ел нәтиҗәләре буенча илдә рекордлы күләмдә 92,6 млн квадрат метр торак тапшырырга мөмкинлек бирде. Татарстан беренче тапкыр 3 млн квадрат метр чикне узды, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Утырышта Россия Хөкүмәте вице-премьеры Марат Хөснуллин белән илнең төзелеш министры Ирек Фәйзуллин да катнашты.

«ТОТЫП БЕТЕРМИСЕЗ, ДИМӘК...»

Әлеге сүзләрнең нәрсә уңаеннан әйтелгәне турында бераз соңрак, иң әүвәл парламентыбызның утыз икенче утырышында каралган башка мәсьәләләргә күз салыйк.

Бер уйлаганда, депутат Олег Коробченконы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры итеп билгеләп куюны килештерү алай артык зур мәсьәлә түгел, чөнки ул – инде сөйләшенгән, килешенгән һәм төймәгә генә басасы калган эш. Шулай да аның бу вазыйфага билгеләнүе очраклы түгел, дип әйтәсе килә. Сессия утырышларында да авыз йомып утырмады ул, тегеләй яки бу мәсьәлә буенча үз фикерен әйтә, белеп әйтә килде. Аннан соң Олег Коробченко – үз бизнесын нульдән башлаган, үз тырышлыгы белән аякка баскан шәхес. Һәрхәлдә, аны якыннан белүчеләр шулай ди. Татарстан сәнәгатендә дә үз акылыбыз, үз көчебез белән аякка басасы тармаклар бар әле, уңышлар телик аңа.

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында без әледән-әле язгалап торабыз, чөнки ул үзе дә әледән-әле үзгәрүче тере организм кебек. Комитетлар, сессия утырышларында республикабызның финанс министры Радик Гайзатуллин чыгышын тыңлаганда: «Их, акча санаган саен артса иде ул!» – дип куйган чаклар да була үзе. Әмма, мәсәлән, керемнәр буенча бүген без Россия субъектлары арасында бишенче урыннан җиденче урынга төшкәнбез икән. Шулай да, министр әйтүенчә, физик затларга салым кеременең уңай динамикасы күзәтелә һәм бу икътисади уртача хезмәт хакы үсешен тәэмин итә.

Бюджетның керем-чыгым өлешләре, кайсы тармакка күпме акча бирелүе турында саннар китереп тормыйк. Әмма казна акчасының 60 проценты социаль өлкәгә җибәрелүен әйтү кирәктер дип саныйбыз. Парламентның Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин әйткәнчә, социаль тәэминат, халыкка төрле түләүләр күләме узган 2020 ел белән чагыштырганда, 3,6 процентка арткан. Беренче чиратта торган чыгымнар 200 млрд сум булган.

Бер уйлаганда, узган финанс елы артык зарланырлык түгел, без пандемия шартларында яшәргә дә өйрәнеп беттек. Өйрәнеп кенә беткән идек, яңа афәтсанкцияләр чорына килеп кердек. Димәк, ирешкән уңышларга шатланып кул чабып утыра алмыйбыз. Шунысын да әйтик: узган елны профицит белән тәмамлаганбыз, ягъни керемнәр күләме чыгымнардан артып, 11 млрд 601 млн 661 мең 500 сум тәшкил иткән. Бу саннарны министр Радик Гайзатуллин әйткәнчә тиененә кадәр диярлек яздык. Бу «артык» акча быелгы бюджет кытлыгын капларга тотылачак икән…

Кыскасы, акчаны санап тоту әйбәт инде ул, әмма, сак тотуга килгәндә, уйланырлык урыннар бар. Утырышта Республика Хисап палатасы эшчәнлеге турында нотык тыңладык. Хисап палатасы рәисе урынбасары Альберт Вәлиев кимчелекләрне, финанс тәртибен бозу очракларын атады үзе, әмма анализ гомумирәк сүзләр белән ясалды кебек.

Хисап чорында, ягъни узган ел 45 тикшерү уздырылган. Закон бозу очракларын акчага әйләндерсәң, 3 млрд 427 млн сумлык зыян килеп чыга икән. Җинаятьләрнең иң күп өлеше – 51 проценты – идарә, дәүләт һәм муниципаль милек белән эш итүгә кагыла. Икенче урында (32%) – бухгалтерия учеты, диделәр. Казна акчасын башка максатларда файдалану күләме – нибары 3 млн 400 мең сум гына. Бер уйлаганда, дәүләт акчасына контроль дә көчле кебек. Хәтта 2005 елда Президент фәрманы белән дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча Ведомствоара координация советы да оештырылды. Әмма Камалның «Банкрот» пьесасы герое Сираҗетдинча һаман: «Каравыл, талыйлар!» – дип кычкырасы килеп киткәли.

Узган елгы тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 җинаять эше кузгатылган. Әмма бу эшләрнең кемнәргә карата кузгатылганы билгесез. Дөресрәге, без аны ишетә алмадык. Шуны уйлап куям: бәлки, акчага бәйле кыңгыр эшләр, төп фигурантлар турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша җәмәгатьчелеккә җиткереп барыргадыр, халык үз «герой»ларын белсен, диюем.

Альберт Вәлиев тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән документларны прокуратурага тапшырачакларын һәм җинаять эшен тикшерүнең барышын контрольдә тотачакларын әйтте үзе. Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исә: «Тотып бетермисез, димәк», – дип төрттерге. Димәк, кайдадыр нидер эшләп җиткерми. Урлау, ришвәт дигәннәре дөньяның бөтен илләрендә дә бар, аерым бер ил – Россиядә генә коммунизм төзеп булмас, ахрысы.

«Коммунизм» димәктән, утырышта шактый хисләнеп, коммунист депутат Хафиз Миргалимов чыгыш ясаган иде. Беренчедән, ул Татарстан сайлау кодексына һәм аерым законнарга үзгәрешләр кертү турындагы закон проектыннан риза түгел иде. Ул дистанцион электрон тавыш бирү, ягъни үз сүзләре белән әйтсәк, «диванга ятып, төймәгә басып тавыш бирү» дөрес түгел, дип бара, сайлауларның гадел, ачыктан-ачык булу принцибы бозыла, ди. Хафиз иптәш һәркемнең, сайлау участогына килеп, бюллетень алып сайлавын хуплый, моны бердәнбер дөрес юл дип саный. Закон проекты буенча чыгыш ясаучы депутат Альберт Хәбибуллин аны тынычландырырга омтылды, электрон тавыш бирүнең бердәнбер мәҗбүри алым түгеллеген әйтте. Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да, тормыш бер урында тора алмый, закон бозыла дип алдан ук тавыш куптару да кирәк түгел дигән фикердә. Ул пачкалап-пачкалап ялган бюллетеньнәр ыргытуга бәйле гаугалы сайлауларны да искә төшерде әле. Кыскасы, әлеге закон проекты турында фикерләр төрле иде, шуңа күрә ул хәзергә беренче укылышта кабул ителде.

Ә проектка бәйле тәкъдимнәр киләсе сессия утырышына хәтле, ягъни бер ай эчендә парламентка керергә тиеш. Хафиз Миргалимов Георгий тасмасына кагылышлы федераль закон турында да илһамланып сөйләде. Бу закон Георгий тасмасына аерым статус бирү турында булып, Татарстан парламенты аңа үз фикерен белдерергә тиеш иде. Кыскача әйткәндә, беренче мәртәбә 1768–1774 еллардагы рус-төрек сугышларында ук күренә башлаган бу тасма бүген рәсми рәвештә, ягъни закон нигезендә батырлык символына әйләнергә тиеш. Әлбәттә, моңа каршы килүче булмады, тарихының шактый өлеше сугышлардан торган ил өчен Георгий тасмасының «законлы яшәве» кирәктер дә.

Инде килеп, Россия Җинаять кодексына үзгәреш кертү буенча Татарстан Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында берничә сүз. Асылы шул: Россиядә наркотиклар белән бәйле җинаять кылучыларга карата җәзалар бик кырыс, хәтта гомерлеккә төрмәгә дә ябып куярга мөмкиннәр. Ә федераль закон бу төр җинаятьтә катнашкан йөкле хатыннарга, күпбалалы аналарга, балигъ булмаганнарга, инвалидларга карата артык йомшаклык күрсәтә, аларга шартлы рәвештә җәза бирелергә мөмкин. «Наркобароннар» шушы йомшаклыктан файдалана да инде. Утырышта чыгыш ясаучылар фикеренчә, әгәр наркотиклар таратуда катнашучыларның барысына да җәзалар кырысландырылса, наркотикка бәйле җинаятьне оештыручылар без санаган төркемгә кергән гражданнарны: «Сезгә берни дә булмаячак», – дип, җинаятькә тарта алмаячаклар. Әйтүләренчә, бу төр җинаятьләр бандитизмга бәйлеләренә караганда киңрәк колач ала бара икән.

Татарстан парламентының закон чыгару инициативасы кабул ителде. Хәзергә шулар.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан Дәүләт Советында «Язылу бүләк ит» хәйрия акциясе узды. Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да акциягә кушылды. Ул Баулы картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортын «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарына, «Сөембикә» журналына яздырды.

Айдар ШӘЙХИН

Биш акчалар

«Бу эшкә күпме акчалар түгелде?»
«Мин күзлекләремне оныттым»
«Сәгатьләр уникене сукты»

Бу җөмләләрнең барысы да хаталы, чөнки аларда тәрҗемә барышында татар теленең берлек һәм күплек сан категориясе дөрес кулланылмаган. Мондый төр хаталар төрле телләрдә күзәтелә, шуңа күрә грамматикада бу хата белән бәйле булган кагыйдәне аңлата торган махсус төшенчә бар: singularia tantum һәм pluralia tantum. Латин теле белән мавыгуымны гафу итегез, хәзер гади генә итеп аңлатып китим: кайбер сүзләр бары тик күплек санда гына кулланыла ала, ә кайберләрен бары берлек санда гына куллану дөрес (мәсәлән, русча *деньги, часы, очки, alms, money, scissors* һ.б.).

Татар телендә исә *акча, күзлек, сәгать* кебек сүзләр берлек санда да, күплек санда да кулланыла ала, әмма үз урыннарында гына: татар телендә кеше берьюлы бер күзлек кенә киеп йөри ала, *күзлекләр* булса, ул берничә күзлек кигән сәер кеше булачак. Кулдагы яки идәндәге сәгать уникене дә, икене дә суга ала, ә *сәгатьләр* булса, димәк, кемнеңдер өендә суга торган сәгатьләр берничә. Рус телендә нинди генә хәл булса да, *часы показывают, часы бьют,* әмма татар телендә *сәгать суга* һәм *күрсәтә.*

Акча белән бераз катлаулырак. Асылда, *акчалар* дип әйтү гомумән дөрес түгел, чөнки акча – абстракт төшенчә, абстракцияне күбәйтеп булмый. Ул киңәергә мөмкин, ләкин аның микъдары артмый. Ләкин бер очракта *акчалар* дип әйтә алабыз: абстракт *акча* төшенчәсен конкрет банкнота яки тәңкә белән тиңләштерсәк кенә. Шулай да, кесәдән кәгазь акча төшкәндә, анда ничә генә банкнота булса да, «*Акчаң* төште!» дибез, «*Акчаларың*» димибез.

Гомумән, татар телендә кирәксә-кирәкмәсә күплек санын куллану дөрес түгел. Безнең телебездә күплек сан тоемлап та аңлашыла. Санның үзен күрсәткәч, исемне күплек санда куллану кирәк түгел: *биш алма,* биш алмалар түгел. Хәтта парлы предметларны да без күплек санга күчереп атамыйбыз: *бияләй, оекбаш, итек* һ.б.

Мәктәптә һәм уку йортларында укуларның туктылып тору вакытын татарча *каникуллар* дип күплек санда әйтү дә хаталы. Рус телендә бу сүзнең күплек формасында кулланылуы латин теле белән бәйле, чөнки оригиналда бу сүз *canicula* дип яңгырый (сүз уңаеннан, *көчек, кечкенә эт* дигән сүз ул), аннан *dies caniculares* сүзе, соңгысыннан *каникулы* төшенчәсе хасил булган. Әмма татар телендә *каникула* яисә *каникул* дип әйтү дөрес булачак, сүзне рус телендәгечә күплек санга куярга кирәк түгел. *Язгы-җәйге-көзге-кышкы каникул, ел саен була торган каникуллар, парламент каникулы.*

17 ИЮНЬГӘ РОССИЯ ҮЗӘК БАНКЫ БИЛГЕЛӘГӘН ВАЛЮТА БӘЯЛӘРЕ

1 АКШ доллары	56,8691 сум
1 евро	58,9568 сум
10 төрек лирасы	32,9248 сум
10 кытай юане	85,5449 сум
100 казах тенгесе	12,9711 сум
10000 үзбәк сумы	51,8873 сум

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Җуләр

Безнең авылда Мәһифәрваз атлы бер кыз бар иде. Без аны үзебезчә, авылча «Майфәрваз» дип йөрттек. Тәскә-биткә чибәр иде ул, әмма акылга сайрак иде. Авыл кешеләренең: «Андый булып тумаган ул, кечкенә вакытында әнисе ялгыш кулыннан төшереп җибәргән дә, куркуыннан, кыз җуләрләнеп калган», – дип сөйләнүләре бүген дә хәтердә әле.

Әмма Майфәрвазны берәү дә рәнҗетмәде, мыскыл итмәде. Ә без, авыл малайлары, аннан яман курка идек. Берәрсе: «Әнә Гөлшат тилесе килә!» – дип уйнап кына кычкырса да, төрле якка сибелә, иң якын ишегалдына йөгереп кереп, капканы бикләп куя идек.

Малай чакта «Фәлән авыл җуләре», «Фәлән авыл тилесе» кебек сүзләр шактый еш ишетелде. Димәк, һәр авылның үз җуләре булган һәм бу гадәти хәл саналган. Ә халык аларны «Ходай бәндәсе» дип кабул иткән, җае чыккан саен нииндидер яхшылык эшләргә тырышкан. Бу хакта без дуслар белән дә сөйләшкәлибез. Асылда, бер үк фикергә киләбез: акылы һәм тәне зәгыйфьләр безгә сынау өчен, гыйбрәт өчен җибәреләдер, дибез. Хәтта: «Җуләрләрсез яшәү кызык булмас иде», – дип тә өстибез. Монысы – бераз арттырып әйтү инде, ә менә гыйбрәт өчен дию – хак.

Җәмгыятьтә тулы камиллек беркайчан да була алмый, гәрчә шуңа омтылып яшәсәк тә. Чөнки кешеләр арасында «җуләргә сабышу» дигәннәре дә бар әле. Килеп туган төрле хәлләр «башны җуләргә салырга» мәҗбүр итә, бигрәк тә алдап-йолдап, авыр хәлдән чыгарга кирәк булса.

Якын дустым, Казан дәүләт университеты профессоры, инде бакыйлыкка күчкән Хәлил Сәлимов белән «... миңа рәхәт, мин – җуләр» дип көлә-көлә такмаклаган чаклар искә төшеп китте. Көлүен көлә идек тә, әмма башны җуләргә салып, килеп туган авыр хәлдән котылырга омтылуның бер мисалы, алымы иде ул. Һәм, ни гаҗәп, күңелсезлекләрне уен-көлке белән уздырып та җибәрә идек.

Әмма башны җуләргә салу кайвакыт бик урынсыз була. Мин бүгенге дөньяда барган зур сәясәтне күз алдына тотам. Кайбер дәүләтләрнең җитәкчеләре, үз сүзен суз итәр өчен, ниләр генә кыланмый! Юкны – бар, барны юк итеп күрсәтү өчен, теләсә нинди адымга баралар. Шул ук санкцияләрне алсак та, башларын җуләргә салып, таякның ике башлы булуын онытып калалар. Иң аянычы шул: таякның юан башы гадәттә халык җилкәсенә төшә. Кемдер санкцияләрне «үз аягыңа ату» белән чагыштырды инде.

Яңадан Майфәрваз искә төшә. Аның гариплеге бер кешегә дә зыян китерми иде. Дөрес, гарип бала – ана өчен зур бәхетсезлек инде ул, әмма Гөлшат апа беркайчан да, беркемгә дә зарланмады, бәхетсезлеген язмыш дип кабул иткәндер инде. Ә хәзерге сәяси спектакльләрнең пьесасын язган кешелер, режиссерлар, спектакльдә катнашучыларның җуләрләнүләре – Аллаһы Тәгаләдән җибәрелгән сынау түгел, ә кешелек язмышы өчен кеше уйлап чыгарган зур фаҗига. Андыйлар янында безнең авылның Майфәрвазы укалы фәрештә кебек тоела.

ИТ АШАСАҢ, ТЕШКӘ КЕРӘ...

ИКЪТИСАДКА АЗЫК-ТӨЛЕК БӘЯЛӘРЕ КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАШ

Газета хәбәрчесе бүгенге тормышка азык-төлек бәяләре күзлегеннән объектив караш ташларга булды. Икътисадка төрлечә бәя бирергә мөмкин, әлбәттә. Әйтик, торак төзелешен нигез итеп алып, яшәешебезнең матди дәрәҗәсен чамаларга тырышып карарга була. Уртача хезмәт хаклары белән үлчәп карасаң да ярый. Сәнәгать җитештерүе индексын төп критерий итеп алсаң да, кызыклы саннар килеп чыга.

Соңгысы чыннан да кызык инде: комплектлаучы детальләр җитешмәү сәбәпле, заводлар туктап тора, бизнес ачыргалана-зарлана, активлыгын киметә, әмма Россиядә сәнәгать индексы шактый кызу темплар белән үсә. Үткән елның апреле белән чагыштырганда, ул, әйтик, 4,3 процентка арткан, ә гыйнвар – апрель темпы 6,9 процентлы үк үсештә. Юк, статистика шыттыра дип әйтергә җыенмыйбыз һич тә. Үсешне нигездә табигый казылмалар чыгару һәм аларның югары бәяләре тәэмин итә. Ә эшкәртүче сәнәгать тармаклары артка чигә. Автотранспорт чаралары җитештерү, мәсәлән, март аенда ук 45,5 процентка кимегән.

Татарстанның гыйнвар – апрель темплары Россиянең уртача күрсәткечен узып китә. Үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 9,3 процентлы үсештә. Апрельдә исә республиканың сәнәгать индексы 99,2 процент кына күрсәткән, ягъни кимегән. Апас районы сәнәгать җитештерүен 25,9 процентка гына калдырган. Арча районы индексны апрельдә 147,1 процентка җиткергән, Бөгелмә – 168,3кә.

Бу саннар гади кеше колагына бик аз нәрсә сөйли. Шуңа күрә, әйдәгез, азык-төлек бәяләре, аеруча итнеке аша тормышның матди дәрәҗәсен чамаларга тырышып карыйбыз. Азык-төлек бәяләренең март башында ничек сикергәнен, халыкның, паникага бирелеп, ничек үрсәләнүен хәтерлибез бит әле. Бер нәрсәне истә тотыйк: үткән ел авыл хуҗалыгы өчен авыр килде, азык-төлек инфляциясе котылгысыз рәвештә югарыга үрмәләде. 2021 елның апрель – май айларында иткә бәя (сыер ите турында сүз алып барабыз) 365 сум булса, 27 декабрьдә инде 405,82 сум белән бәяләнде, ә быел 27 гыйнварда сыер итенең килосы 410,13 сумга җитте. Айлык ит инфляциясе – 1,06 процент.

Атланмайның бәясе исә декабрь белән чагыштырганда 17,41 сумга күтәрелгән, айлык инфляция 2,97 процент булган. Ягъни махсус хәрби операциягә кадәр үк азык-төлек бәяләре шактый сикергән. Гыйнвар ахыры – февраль ахыры бәяләре күтәрелеше дә итнеке – 1,57; атланмайныкы – 1,39 процент. Уңынчы мартка инде итнең ике атналык инфляциясе 5,45 процентка җитеп, республикадагы уртача бәясе бер килога 439,49 сумга кадәр биеклек яулаган. Апрель уртасында сыер итен уртача 471 сумга гына алу мөмкин булган. 14 апрельдә Тукай районы базарында сыер итенең килосын 750 сумга бәяләгәннәр, Арчада – 405 сумга, Теләчедә – 375кә генә.

Атланмай апрель уртасында Спас районында һәм Казанда кыйммәткә сатылган. Килосы – 740–730 сумнар. Тәтештә – 523 сум гына. Июньдә ит бәяләре чагыштырмача тотрыкланган. Сыер итенең республикада уртача бәясе 8 июньдә – 474 сум 68 тиен. Бәя түбәнәйгән, атналык дефляция – 0,27 процент. Атланмай гына бер атна эчендә 1 процентка кыйммәтләнгән. Үткән елның маенда литры уртача 52,16 сум торган сөт бәясе быел 8 июньгә 66,35 сумга җиткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ит һәм сөт кыйммәтләнсә дә, шикәр һәм тоз кебек үк сикерә алмаганнар, билгеле. 2021 елның 27 маенда килосы 50,95 сум булган шикәр комы быел 8 июньдә 84,7 сумга бәяләнә. Бәя июньдә бераз төшкән, бер атна эчендә 1,32 процентка арзанаю күрәбез. Шикәр комы март ажиотажы вакытындагыдан арзанаймаган диярлек. Паникага бирелеп, капчыклап шикәр алып калучылар «оттырдык» дип әйтә алмыйлар, «Әле ярый алып калганбыз», – дип тынычланалар. Районнарда исә бәяләр диапазоны таң калырлык. Шикәр комы килосының 8 июньдәге бәясе: Биектауда – 96,73 сум, Әлмәттә – 76 сум 98 тиен.

Районга тегe яки бу азык-төлекнең күп җитештерелүе бәянең түбәнлегенә китерми. Киресенчә, «алтын чыккан җирдә кыйммәт йөри» дигән кагыйдә күбрәк күзгә ташлана. Иң күп сөт җитештерүче районнар базарында сөт кыйммәт. Теләчедә литры – 87,49 сум, Балтачта – 76,69; Әтнәдә – 74,65. Катгый кагыйдә түгел бу үзе. Кукмара базары сөтнең литрын 57 сумга гына бәяли.

Базар белән базар арасында бәяләрнең кискен аермасы ачылмаган сер булып кала бирә. Туңдырылган балыкның килосын Аксубай районында 340,24 сумга бәялиләр, мәсәлән. Әгерҗедә – 141 сум 61 тиенгә генә. Аерма – 2,4 тапкыр. Җитештерелгән продукциянең базарда кыйммәткәрәк сатылуы авыл хуҗалыгында хезмәт хакларының кискен үсешенә китерми. Татарстан буенча авыл хуҗалыгында уртача хезмәт хакы – 33 мең 400 сум, үткән елгы белән чагыштырганда – 117 процент. Сөт җитештерү буенча лидерлар арасындагы Әтнә районында уртача айлык хезмәт хакы – 29 мең 744 сум гына, Кукмарада – 30 мең 64, Балтачта – 30 мең 749. Республика күрсәткеченнән байтак түбән ягъни.

Зәй районында уртача хезмәт хакы кимегән, үткән елның 90 проценты кадәр генә калган. Сарманда да шулай ук. Әлмәт районы үткән елгының 97 проценты кадәр уртача хезмәт хакы түли, әмма Әлмәттә хезмәт хакы күрсәткече республиканың уртача күрсәткеченнән күпкә югары – 38 мең 832 сум. Ә үткән ел 40 меңнән артык булган.

Шикәрсез торып була, тозны чеметеп кенә кулланабыз, шуңа күрә бу продуктларның бәясе күтәрелү тормышның матди дәрәҗәсенә йогынты ясаса да, куркыныч ук түгел. Итсез-сөтсез көн күрү кыен. Республикада мөгезле эре терлек саны елдан-ел кими. 2021 елда йөз гектар җиргә 17 баш мөгезле эре терлек туры килгән булса, быел 16 гына, терлек саны алдагы елның 94,5 проценты кадәр. 2014 елның апрелендә йөз гектар җиргә 19 баш мөгезле эре терлек туры килгән. Йөз гектарда мөгезле терлек асрауның потенциалы исә зур. Балтач районында шул мәйданда 53 баш мөгезле терлек асрыйлар, Әтнә районында – 59. Әтнәләр дәрәҗәсенә җиткерсәк, без республикада терлек санын 3,68 тапкыр арттыра алыр идек. Мөгезле эре терлек санын үткән елгының 23 проценты кадәр генә калдырган район бар, 56–68 процентка калдыручылар байтак. Сөт җитештерүдә интенсив юлдан бара Татарстан, ягъни баш саны кими – сөт җитештерү арта. Әмма җитештерү нигездә баш санын да арттырган районнар хисабына бара. Болар сыер санын да үстерәләр, бер сыердан сөт савып алуны да арттыралар. Терлекләрнең баш саны кимегәндә, ит җитештерүне арттыру мөмкин түгел диярлек. Ит җитештерү үткән елгының шул чоры белән чагыштырганда 99 процент кына.

Азык-төлек бәяләре үсешендә җитештерү күләме төп рольне уйнамый, әлбәттә. Бездә җитештерүче дип авыл кешесе түгел, эшкәртүчеләр санала. Соңгылары гадәттә сатып алу бәясен түбән куя, ә базар бәясен күтәрәләр. Эшкәртүнең үзкыйммәте арту белән аңлаталар кыйммәткә сатуларын. Бары тик авыл гына үзкыйммәтнең артуыннан зарланмый, түбән бәядән җитештерүне дәвам иттерә. Авыл хуҗалыгы җитештерүе үзен сәнәгать тармагындагыча тотса: җитештерүне киметеп, бәяләрне күтәрсә, без бик кыен хәлдә калыр идек. Йөз гектар җиргә мөгезле эре терлек санын 4 кенә башка калдырган районнар күләменә тигезләсәк, ит һәм сөт җитештерү күрсәткечен 4 тапкыр киметәчәкбез. Ит – шундый ризык бит инде ул: ашаганда тешкә кереп җәфалый, ашамасаң – тәшкә керә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТОТКА

Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдим иткән мәгълүматлар буенча, бүгенгә республикада тракторларның – 10, урып-җыю һәм туфрак эшкәртүче машиналарның 30 проценты чит илдән кертелә. Авыл хуҗалыгы техникалары өчен запас частьлар алырга ел саен 4,5 млрд сум тирәсе акча тотыла, шул исәптән 2,7 млрд сум – чит илнекеләр өчен.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Министрлык көн саен үзебездә булмаганны республика предприятиеләрендә эшләүне җайлау һәм алып кайтуның башка юлларын эзләү белән шөгыльләнә. Шушы берничә ай эчендә Татарстан оешмалары чит илдән кайтарылган техникага 2 меңнән артык атамалы детальне яки ясарга өйрәнгәннәр, яки җитештерүне торгызып җибәргәннәр. Белгечләр әйтүенчә, үзебезнекеләрнең бәяләре чит ил аналогларыннан уртача 2–3 тапкыр арзанрак.

Европага рәхмәт

Чит илдән кертелә торган техникаларны алыштыруда яки аларга запас частьлар ясауда Мөслим районының данлыклы «Агромастер» компаниясенең роле зур. Ул җитештерү күләме һәм сыйфаты буенча Россиядә әйдәп баручы предприятиеләр рәтендә тора. Компания 300гә якын төрдәге авыл хуҗалыгы машиналары эшләп чыгара. Алар – чәчү комплекслары, дисклы агрегатлар, культиваторлар, җир йомшарткычлар, тагылмалар, тракторлар һәм башкалар. Компания елына 1200–1300 данә продукция җитештерә. Шуның 5 процентын Татарстан ала. Калганы Россиянең 45 төбәгенә, Калининградтан башлап Сахалинга кадәр сатыла. Шулай ук җитештерелгән техниканың 20 процентлап тирәсе Казахстанга китә. Соңгы айлардагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә алар тагын 30–40 төрдәге детальләр ясый башлаган.

– Чит илдән кертелә торган детальләрне үзебезнекеләр белән алыштыру – бер көнлек, яки 24 февральдән соң башланган үзгәрешләр нәтиҗәсе генә түгел, – ди компаниянең җитәкчесе Илгиз Исламов. – Соңгы биш елда мин аңа бик нык әзерләндем. Без эш башлаганда запас частьларның 50 проценты читтән кертелә иде, ә хәзер алар якынча 5 процент кына калды. Кайчандыр Европадан алган гидроцилиндрларны хәзер үзебездә ясыйбыз. Алар чыдамлылык буенча чит илнекеләрдән бер дә калышмый. Бүгенгә 200ләп шундый деталь ясадык. Әле тагын 400 гидроцилиндр ясарга җитәрлек запасыбыз бар.

Җитәкче сүзләренә караганда, санкцияләр кертелгәч, компания 30–40 төрдә детальләр җитештерә башлаган.

– Чынлыкта, цехлардагы җиһазлар чит ил техникаларының детальләрен ясарга мөмкинлек бирә, тик без эшләп кенә өлгермибез, – ди ул. – Европа, бөтен дөнья үзе дә сизмичә, безгә эшләр өчен мөмкинлекләр бирде. Россиядә шул ук техниканы күпкә арзанрак бәядән ясап була. Әйе, бәлки без кайбер сыйфатлары ягыннан чит илнекеләрдән калышабыздыр да, ләкин камиллеккә омтылабыз. Бер караганда, без аларны элек тә эшли алган булыр идек. Ләкин бу – дөньякүләм икътисад. Элек әлеге детальләрнең үзкыйммәте ике тапкыр артыграк иде, хәзер ике тапкыр арзанрак. Безне һәрвакыт ихтыяҗ мәҗбүрили. Шунысы куандыра: без шушы шартларга яраклашу, авырлыкларны ерып чыгу юлларын беләбез.

Ул көнне без Илгиз Исламов белән эш турында гына сөйләшмәдек. Мондый олпат, көчле, гомере буе туган районына хезмәт иткән, нәсел тамырлары тулысынча Мөслимгә бәйләнгән җитәкченең тормышка карашы да укучы өчен кызыклы булыр дип уйладык һәм кайбер фикерләрен сезгә дә тәкъдим итәргә булдык.

Туган җир кадере

«Мөслим – минем туган җирем. Гомеремнең 55 елын шушында яшим. Үземне еш кына «абориген» дип атыйм. Әти-әнием дә шушыннан минем. Әни ягыннан нәсел тамырлары 1732 елга барып ялгана, әтинеке – 1722 елга. Мин – әни ягыннан унберенче, әти ягыннан унынчы буын. Нәселебездә ике мулла булган, калган барысы да – гап-гади кешеләр. Шуларның барысы да Мөслим, Карамалы, Кубәктә яшәгән.

> Олыгайган саен кешенең күңеле нечкәргәннән-нечкәрә икән. Шуңа күрә дә туган ягыма булган ярату, дулкынлану хисләре бөтен барлыгымны биләп ала минем.

Дөрес, гел бу турыда гына уйлап, моңаеп утырмыйм, әлбәттә. Ләкин райондашлар бик якын миңа. Ярдәм сорап килүчеләргә һәрвакыт булышырга тырышам.

«Әтидән сорап кара»

Мин физика, математика, химияне су урынына эчә идем. Һаман да саннар яратам, аларны яттан беләм. Ләкин алтынчы сыйныфтан бирле трактор тирәсендә бөтерелгәнгә, мәктәпне бетергәч, авыл хуҗалыгын сайладым. Институтка укырга киткәндә, әни: «Әтиең дә, абыең да – авыл хуҗалыгы тармагында. Әллә физматка керәсеңме? Мәскәүгә барасыңмы?» – диде. Эндәшмәдем. Сумкаларны күтәреп, туганнан-туган апам белән юлда машина тотып, Казанга чыгып киттек. Шунда барып кергәч, һөнәр сайлау мәсьәләсен әнинең сеңлесе Филүзә апа тагын бер кат күтәреп карады. Акрын гына: «Илгиз, КАИга бармыйсыңмы соң? Әниең дә шулайрак сораган иде», – диде. Мин бер генә җөмлә әйттем: «Син әтидән сорап кара, Филүзә апа». Шушы бер җөмлә җитте аңа. Апа кул гына селтәде.

Ә институтка мине алтын медаль белән экстерн алдылар. Андый студентлар беренче айда ук практика узарга тиеш. Һәм беләсезме мине кая билгеләделәр? Ул елларда Ферма торак комплексында дендрит парклы бар иде. Шунда үсә торган миләшләрне чыпчыклардан сакларга куйдылар мине. 1,86 метрлы, зур гәүдәле, типсә тимер өзәрдәй егетне чыпчык куарга куйсыннар инде! Күз алдына китерәсезме? Шушы буем белән өч көн каравылда тордым да каравычкы ясап куйдым. Аннан соң да атна-ун көнгә түздем әле. Тик болай йөрү гарьләндерде. Кул селтәп, авылга кайттым да киттем.

Пай җире

Авыл халкының колхоздан калган бер юанычы бар. Ул да булса – пай җире. Халык миңа да әллә никадәрле пай җирен ышанып тапшырды. 14 район арасында пай җире өчен иң күп акчаны мин түлим икән. Моны үзем дә белми идем. Беркөн телевизордан әйттеләр. Былтыр ипи булмады. Тегермәндә тартырга диген бодайны халыкка бирдем. Салам булмады, ләкин тешне кысып булса да, анысын да тараттым. Нигә халыкны рәнҗетергә? Ул гомер буе колхозында маңгай тирен түккән, көнне төнгә ялгап эшләгән бит. Кешене алдарга ярамый. Минем үземне күп алдыйлар, ләкин төп принцибым – әйткәнсең икән, сүздә торырга кирәк. Дөрес, ул бик авыр, ләкин әлеге сыйфат еллар белән формалаша. Берничек тә үзең турында гына уйлап эшләп булмый. Син бай икәнсең, эшчеләрең дә яхшы хезмәт хакы алып, мул тормышта яшәргә тиеш.

Институт – табиб, техникум – фельдшер

Ни өчен авылда яшәүчеләр кими? Заманында авыл үз тәртипләре белән салмак кына яшәп ята иде. Тик дөнья күчәре гел әйләнеп тора. Яңалык бөтен өлкәләргә кагылганда, авыл гына аерым утрау булып кала алмый. Прогресс анда да бара. Яшьләр шәһәргә чыгып китә, авылда эш кими. Үзмәшгуль итеп тә карыйлар, ләкин мин аны бик аңлап бетермим. Авыл хуҗалыгы бар безнең. Анда эшләүче кешеләр дә бар. Мәсәлән, мин бер кешегә дә, синең кирәгең бетте, кит инде, дип әйтмим. Кулына гариза тотып кергәненнән дә иң элек китү сәбәпләрен белешәм, ярдәм тәкъдим итәм. Күпчелеге Чаллыга чыгып китә, тик кайберләре кире әйләнеп кайта да эшкә алуны сорап керә. Кире борып чыгармыйм. Безнең егетләр ел дәвамында эш белән тәэмин ителгән. Кемдер кышын токарь булып эшли дә җәен комбайнга утыра. 70 яшенә якынлашкан абзый бар минем цехта. Урып-җыю чорына ат чабышына чыгарга әзерләнгән айгыр кебек ашкына. Ел да: «Киләсе елга комбайнга утырмыйм», – дип кабатлаган кеше югыйсә! Анда бер ай эшләп, премияләр белән бергә 300 меңен ала да кабат станогы артына барып баса. Элек авылда да комбайнда эшләгән кеше кышын фермасына кайта иде. Хәзер эшләргә фермасы гына юк. Ә шәһәрнең түмән бер татыган кеше авылга кире кайтмый инде. Һәркем югары белем алмакчы була, ләкин бөтен кеше мулла булса, атка печән кем сала?

> Институт – табиб, техникум – бар эшне дә эшли алучы фельдшер ул. Техникум бетергән белгечләргә хөрмәтем зур. Аларны һәрвакыт кадерлим, чөнки һөнәри белем алучылар практик яктан бик көчле була. Белем дәрәҗәсе бераз түбәнрәк булса да, техникум бетереп килгән егетләрнең куллары эшкә ятып тора. Бездә дә андыйлар күп.

Инженерга тел кирәкми

Мин китаплар укырга яратам. Германиягә баргач, сумка-сумка китап төяп кайта идем. Алар төрле телдә язылган була. Инженерга тел кирәкми аңа, ул теләсә нинди телдә язылганны аңлау сәләтенә ия. Шуңа күрә саннар, китаплар – минем төп ярдәмчеләрем. Ә җитәкче үз эше белән 24 сәгать яши. Бервакытта да туп-туры өйгә кайтып китмим. Басуларны булса да урап узам, чөнки мин шуның белән яшим. Алтынчы сыйныфтан бирле шушы кварталдан башканы күргән юк бит. Җитәкченең уңыш сере – бик җентекле, тырыш эш нәтиҗәсе. Ул алдан барырга тиеш. Һәр нәрсәнең бөртегенә кадәр зур игътибар бирү таләп ителә. Тормыш безгә һәрвакыт ниндидер проблемалар чыгарып тора. Аларны хәл итәргә, күңелне төшермәскә кирәк. Иң мөһиме – ирешкән уңышлар белән генә туктап калырга ярамый».

Зөһрә САДЫЙКОВА

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КИЛӘЧӘКНЕ САЙЛАГАНДА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кемнәр кирәк?

Кадрлар кытлыгы күп өлкәләрдә сизелә. Хәер, аның булмаган чагы юктыр да. Замана үзгәргән саен, һөнәрләр дә үзгәрә бит. Хәзер иң кирәкле белгечлекләр – ихтыяҗ тәкъдимнән артып киткән тармакларда.

Моннан берничә ел элек Халыкара хезмәт оешмасы (МОТ) белгечләре 2022 елга дөнья күләмендә мәшгульлек күрсәткече артачак һәм ул коронавирус пандемиясе алып килгән торгынлыкны алмаштырачак дип фаразлаган иде. Әлбәттә, ул чакта геосәяси вакыйгалар исәпкә алынмагандыр.

Дөньякүләм икътисади форум белгечләренең тикшеренүләре күрсәткәнчә, 2022 елда күпчелек процесслар автоматлаштырылачак, бу инде IT-белгечләргә ихтыяҗның артуына, ә эшче кулларга кимүенә китерәчәк. Хәер, моны инде фаразлыйсы да юк, үзгәрешләр – күз алдында. 75 млн эш урыны юкка чыгып, аның урынына яңа 133 млн урын барлыкка киләчәк, дип юраган иде форум белгечләре. Тикшерүләр күрсәткәнчә, кешеләрнең физик мөмкинлекләренә кызыксыну кимеп, бүтән когнитив сәләтләргә игътибар артачак.

Һөнәри ориентация һәм карьера ясау буенча консультант Николай Чикуновка да «Киләчәктә нинди һөнәрләр кирәк булачак?» дигән соравы еш бирәләр. Америка ачып гаҗәпләндерми белгеч.

– Иң элек, бу – кешеләрнең төп ихтыяҗларын канәгатьләндерә ала торган һөнәрләр. Әйтик, табиб, чәчтараш, азыктөлек җитештерү, сату буенча белгечләр һәм башкалар. Икенче урында – кешеләрнең үзенчәлекле сәләтләренә бәйле булган һөнәр ияләре. Шул ук иҗат әһелләре керә монда. Өченчедән, механикалаштыру һәм автоматлаштыру белән генә ерак китеп булмаган өлкәләрдә хезмәт итүчеләрне дә санга сукмый мөмкин түгел. Андыйлар гел кирәк, – ди ул.

– Яшьләр сайлый торган төп юнәлешләр ул – ясалма интеллект, генетика, медицина, педагогик белгечлекләр. Кыскасы, болар барысы да – хәзерге икътисад таләп иткән һөнәрләр. Алар импортны алмаштыру җәһәтеннән дә әһәмиятле, – ди Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының югары белем өлкәсендә дәүләт сәясәте департаменты директоры Татьяна Рябко.

Россия Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе, педагогика фәннәре кандидаты Раил Шәмсетдинов фикеренчә, хәзерге чорда белем алу өчен кулай ике төп юнәлеш бар: IT-тармак һәм медицина. Шушы тармак буенча укыган яшьләрнең киләчәге бүгеннән үк тәэмин ителәсе көн кебек ачык.

– Без укыган чорда бюджет урыннары бик аз иде. Хәзер арттырып торалар. Әмма балалар аз, демография күрсәткече

kzn.ru

түбән. Шуңа карап, мәгариф тармагы да үзгәреп тора. 5–10 ел элек юрист белән икътисадчы һөнәре бик популяр иде. Бөтен кеше шул юнәлешкә кызыкты, шуңа укыды. Минем уйлавымча, хәзер ике төп юнәлеш бар: IT-тармак һәм медицина. Үзем дә информатика укытучысы буларак, бу юнәлешкә карата кызыксыну барлыгын беләм. Бөтен тормышыбыз цифрлаштыруга бәйле бит хәзер. Замана һөнәре ул. IT-тармак, технологияләр гел үсештә. Ул гел безнең белән булачак. Бу юнәлештә акча да күп. Шуңа күрә бу өлкә яшьләргә кызыклы. Әлеге тармак буенча белгечләр әзерләргә кирәк һәм бу эш алып барыла да. Күп кенә югары уку йортлары нәкъ менә IT-белгечләр өчен бюджет урыннарын арттыра. Махсус зоналар, технопарклар ачыла. Казанда да Президент Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән цифрлы квартал ачылырга тора. Кыскасы, IT-тармак актив булачак һәм бу юнәлештә кадрлар да кирәк. Бу өлкәне сайлаган яшьләр ялгышмас, – дип, фикере белән уртаклашты ул. – Медицина өлкәсенә килгәндә, аның актуальлеген соңгы еллар күрсәтте. Медицинадан башка ниндидер чирне җиңә алмавыбызны халык та аңлый башлады. Төрле вируслар чыгып тора. Аннан, кеше үзенең саулыгы өчен күбрәк борчыла, ныграк кайгырта башлады. Һәркемнең озаграк һәм сәламәт яшисе килә. Шуңа яшьләр табиб һөнәрен сайлый. Медицина да – акчалы өлкә.

Раил Шәмсетдинов әйтүенчә, эшче кулларга да ихтыяҗ бар. Аныңча, энергетика тармагына караган белгечләр әзерләү аеруча әһәмиятле. «IT-тармак эшләсен өчен, электр энергиясе кирәк. Аны тәэмин итү өчен, димәк, белгечләр дә кирәк. Элек бер булмәдә генә ут яндырсак, хәзер тәүлек буе урамда да ут яна. Аларны карап тотучылар кирәк бит. Эшче кулларның абруен «WorldSkills» кебек чемпионатлар да арттырды», – ди әңгәмәдәш.

Эшкә урнашу мәсьәләләре буенча консультант Надежда Малова фикеренчә, абитуриентларга киләчәк һөнәрен сайлаган вакытта эчке тоемлауларына таянырга һәм табигый сәләтләренә игътибар итәргә кирәк. «Дөнья бик тиз үзгәрә. Пандемия чорын карыйк. Университет әчендә өйрәтелми торган һөнәрләрнең әһәмияте артты, шуларга да ихтыяҗ барлыгы күзәтелде. Кемнәндер үзе өчен якын берничә өлкәсе бар икән, шул тармакларда яңалыкларны карап барырга киңәш итәм», – ди белгеч.

«Яшьләр өчен «вазыйфа» дигән төшенчә юк. Алар хәзер билгеле бер вакыт аралыгы, төгәл расписание буенча эшләргә теләми. Ял итү, күнекмәләрне арттыру, белем алу, сәяхәт итү – аларга шулар кызык. Киләчәк тә – эш белән ял арасында алтын урталык саклый, гаилә һәм шөгыльгә вакыт калдырырга мөмкинлек бирә торган һөнәрләр кулында», – диделәр балаларның сәләтләрен ачыклауда булыша торган үзәкләрнең берсендә.

Җиде юл чатында

Булачак һөнәрне сайлаганда теләккә генә түгел, мөмкинлекләргә дә игътибар итәсең. Юрганыңа карап аягыңны суз, дигәннәре хәзерге вазгыятькә бигрәк тә туры килә. Югары уку йортлары ишекләре абитуриентлар өчен 20 июньнән ачылачак (кайберләрендә иртәрәк тә), ягъни, шул көннән кабул итү кампаниясе башланачак. Августта исә студент исеменә лаек булучылар исемлеге чыгачак.

Быелгы кабул итү кампаниясенең төп яңалыгы – бюджет урыннарының артуы. Якынча 600 меңгә. Һәр икенче кичәге абитуриент бүген студент булырга мөмкин дигән сүз инде бу. Абитуриентлар документларын биш югары белем бирү йортына, берничә белгечлеккә тапшыра ала. Олимпиада җиңүчеләре, ГТО тапшыручылар, активистлар, гадәттәгечә, өстәмә балларга өметләнә ала. Уку йортларының кайсыларында өстәмә имтиханнар көткәнен дә онытмаска кирәк булачак студентларга.

Татарстандагы вазгыятьне алсак, белем бирү йортларына барлыгы 20788 бюджет урыны каралган. КФУ, КНИТУ, КНИТУ-КАИ кебек республиканың төп уку йортларына шуның 70 проценты туры килә. Бюджет урыннары дәүләтнеке саналмаган югары уку йортларына да бирелгән. Быел алар өчәү. ТИСБИ идарә университеты һәм «Иннополис» университетында – 82шәр, Тимирязов исемендәге Казан инновация университетында 53 бюджет урыны булачак. Сүз уңаеннан, быел Татарстанда 11 нче сыйныфны 15648, 9 нчы сыйныфны 37757 укучы тәмамлый.

Бюджет урыны майлы калҗа кебек бит ул. Барысына да эләкмәячәге көн кебек ачык. Теләп тә, түләп тә укырга әзер булганнарның акча янчыгы никадәр тулы булырга тиеш соң? Өч төп югары уку йорты мисалында карыйк.

Абитуриентлар һәм чит илдән килүче яшьләр арасында популяр саналган КФУ быел түләп укучылар өчен белем алу хакын арттырмаска вәгъдә иткән иде. Хәер, тәкъдим ителгән кадәрен дә арзан дип әйтеп булмый.

Әйтик, иң күп акча таләп ителгән белгечлек ул – дизайн юнәлеше. Бер елга уку хакы 260 мең сумнан артыграк. Аннан, гадәттәгечә, медицинага бәйле һөнәрләр. Теш табибы, дәвалау, медицина биохимиясе юнәлешләрендә уку 210 мең сумга якын.

Фәлсәфә, социология кебек юнәлешләр буенча белем алу 150 мең сум тирәсе. Журналистика, конфликтология юнәлешләрендә дә шул ук хәл.

Иҗади һөнәрләрдән җиргә төшсәк, бу тармакларда белем алу өчен дә елына 150–180 мең сум акчаны кызганмаска кирәк булыр (радиофизика, инноватика, нефть-газ юнәлеше, юриспруденция, менеджмент).

Медицина университеты, гадәттәгечә, түләп уку бәясе буенча алдынгы. Биредә күпчелек юнәлешләрдә белем алу хакы 200 мең сумнан артып китә. Мәсәлән, теш табибы булам дисәң, бер елга 230400 сум, педиатр һөнәрен үзләштерергә теләсәң, 200 мең сум түләргә туры киләчәк. Фармацевтика юнәлешендә бер ел уку 159920 сумга төшәчәк.

Быел Казан дәүләт энергетика университетында түләп уку бәясе үзгәрешсез калган. Икътисади һәм гуманитар юнәлешләр буенча белем алырга теләүчеләр өчен ул 113600 сумны тәшкил итәчәк. Техник юнәлеш өчен – 131100 сум. Читтән торып уку хакы 38 мең сумнан башлана.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Зөһрә КӘРИМОВА, практик психолог:

Һөнәр сайлаганда ялгышмау мөмкин хәл түгелдер ул, минемчә. Вакыт узу белән кешенең миссиясе дә үзгәрә бит. Иң мөһиме – йөрәк белән сайлау. Йөрәгеңне тыңларга һәм, беренче чиратта, ул теләгән җиргә укырга барырга кирәк. Билгеле, кемнеңдер моңа мөмкинлеге юктыр, яисә шул ук имтиханнар киртә булып торадыр. Тик теләк ихлас икән, аңа барыбер кайчан да булса ирешергә кирәк. Быел барып чыкмаса, киләсе елга. Шулай кечкенә адымнар белән максатка килергә. Үзегезнекеннән баш тартмагыз.

Укырга керү – катлаулы процесс. Ул стресска да китерергә мөмкин. Хәер, стресс гел булачак, ул кешенең «комфорт зонасы»ннан чыгуына җавабы бит. Әмма аны киметү мөмкин. Бу хакта еш һәм күп уйламаска гына кирәк. Сезгә дигән сезнеке булыр, моңа ышаныгыз.

«Керсәм дә, укый алмам инде», – дип тә уйларга кирәкми. Укырсыз! Билгеле, югары уку йорты – мәктәп түгел. Укытучылар артыгыздан йөгереп йөрмәс. Әмма сезгә кадәр дә укыганнар, сездән соң да укырлар, сессиясен тапшырырлар, имтихан бирерләр. Студент чорының төп кагыйдәсе – бу чордан ләззәт алу! Иң күңелле, мәшәкатьсез, риясыз вакыт ул. Шушы вакыт зурлар тормышының тәмен татырга мөмкинлек бирә.

Сан

«Зур тәнәфес» конкурсы, «Россия – мөмкинлекләр мохите» платформасы һәм Илкүләм технологик олимпиада вәкилләре балаларның һөнәргә карата фикерләрен сорашкан. Кызларның **19** проценты иҗат һәм мәдәнияткә бәйле өлкәләрдә эшләргә теләвен белдергән, **17** проценты – сәламәтлек саклау, **8** проценты мәгариф тармагын сайлаган. Малайларның күпчелеге (**38** процент) киләчәген программалар уйлап табу һәм IT-технологияләр юнәлеше белән бәйләргә теләвен әйткән.

Сәрия МИФТАХОВА

КҮРШЕНЕ СОРАП АЛМЫЙЛАР

Көндез иркен яшәргә ияләшкән күршеләргә бераз тынып торырга туры килмәгәе. Татарстанда көндезге 1дән 3кә кадәр «тынлык сәгате» кертелергә мөмкин. Хәзерге вакытта мондый тәртип илнең 25 төбәгендә бар. Чикләү кертеп кенә күршеләрне, урамда шаулашырга яратучыларны акылга утыртып булырмы?

«Туйдырдыгыз сез!..»

Ике күрше арасын бозу өчен күп кирәкми хәзер. Бигрәк тә шәһәрдә. Боравыңны кабызып, бераз дырылдатып алу яки кычкыртып җыр тыңлау да җитә. Икенче көнгә сиңа караш бөтенләй башка булачак. Әйткәнгә битараф калсаң, полиция хезмәткәрләре дә килеп җитәргә мөмкин. Йокы, тынлык дигәнең күрше мөнәсәбәтләренә караганда да кадерлерәк.

– Без ипотека йортында яшибез. Бала тәрбияләүче яшь гаиләләрнең үзәгенә үткән мәсьәлә бу. Көндез сабыең йокыга гына китүгә, үч иткәндәй, йә бораулый, йә чүкеч белән нәрсәдер кага яки шаулаша башлыйлар. Мондый тавышта бала йоклатып буламы? Башка вакыт таба алмыйлармы икән? Тавышланмагыз дип, һаман саен күршеләрнең ишекләрен кагып та, «Ватсап» төркемендә кисәтү ясап та булмый бит. Шуңа күрә көндез «тынлык сәгате» кертсәләр, бик сөенер идек, – ди Казанда яшәүче декрет ялындагы Эльвира Сәлимова.

Әмма бу фикер белән һәркем килешми. Ремонт башлаган кешенең эшен тизрәк тәмамлыйсы килә. Үз өеңдә музыка тыңлау, телевизор карау, тузан суырткыч кабызуның ни гонаһы бар, янәсе. Андыйлар, сез генә бала үстергән, дип яшь әниләрне сүгә. Шәһәр фатирларында күршеңнең бераз кычкырып сөйләшкән тавышы да ишетелә, башкасын әйткән дә юк. Әнә беркөнне күршеләренең каты басып йөрүе безнең йортта яшәүче Ксениянең эчен пошырган. Китте «Ватсап»та язышу! Туп уйнаган өчен балаларга да эләкте. Хәер, бу мәсьәләне ике көннең берендә искә алалар. Йокыга китә алмаучыларның ачуы тагын да яманрак.

Яшьләр «Ватсап»та парын чыгарса, әбиләр подъезд төбендә зарланыша.

– Безгә фатирны сатканда, өебез шундый тыныч, күршеләр бик әйбәт, дигәннәр иде. Алай ук булып чыкмады. Өстәге катта тавышның беткәне юк. Кичке сәгать 10нан соң тормыш яңа башлана гына әле. Күпбалалы гаилә, ахры. Дөбер-шатыр йөриләр, кычкырышалар, елыйлар. Нинди тәртипсез гаилә бу? Әти-әниләре балаларын тыңлата белми, үзләре дә тыныч кына утыра алмый. Аптырагач, фатирны сатып китикме әллә, дип тә уйлаган идек. Бәхет эше: күршене сорап алмыйлар. Яңа урында шундый ук кеше туры килсә, тагын кая бармак кирәк, – ди пенсионер Зинаида Константинова.

Бигрәк тә фатир арендалаучы гаиләләргә диңгез тубыктан. Кычкыртып, музыка тыңлыйлар, төнгә кадәр бәйрәм. Тулай торакта тынычрак та түгелме икән әле?

Өч ел эчендә 2400 кешегә штраф салынган

Хәзерге вакытта Татарстанда «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» закон гамәлдә. Аның буенча кичке сәгать 10нан иртәнге 6га кадәр тавышланырга ярамый. Ял һәм бәйрәм көннәрендә бу кагыйдә иртәнге 9га кадәр дәвам итә. Узган атнада Татарстан Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында депутатлар әлеге законның ни дәрәҗәдә үтәлгәнен тикшерде. Комитет рәисе Шакир Яһудин белдергәнчә, 2020 елдан алып быелның мартына кадәр законны бозган 2,4 мең кеше штрафка тартылган. Шушы вакыт эчендә 3205 кисәтү ясалган. Мондый очракларның күбесе 2020 елда теркәлгән. Ул вакытта халыкның берникадәр үзизоляциядә утырганын да искә төшерү артык булмас.

Аңлашыла инде, тынычлыкны күбрәк кала халкы таләп итә. Казанда яшәүчеләр, әйтик, күршеләреннән, шулай ук транспорт тавышыннан, төзелештәге, урамдагы, ишегалдындагы, кибет, кафе-рестораннардагы шау-шудан зарланган. Соңгы вакытта исә Дәүләт Советына көндез дә «тынлык сәгате» кертүне сорап, мөрәҗәгатьләр еш килә башлаган. Бигрәк тә яшь әниләр һәм өлкәннәр көндезге 1дән 3кә кадәр тынлык сорый. Әйтик, соңгы өч елда Чаллыдан гына да көндез шаулашуга кагылышлы 40 гариза килгән. Шакир Яһудин әйтүенчә, депутатлар республика законына өстәмә үзгәрешләр әзерләү мәсьәләсен өйрәнәчәк.

Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова да әлеге тәкъдимгә карата үз фикерен белдерде. Аның әйтүенчә, иң мөһиме – халыкның фикерен белергә кирәк.

– Без әлеге тәкъдимгә ничек кенә карасак та, парламентарийларның бурычы – халык мәнфәгатьләрен исәпкә алу. Республикада яшәүчеләрнең андый ихтыяҗы бар һәм күпчелекне тәшкил итә икән, димәк, ул канәгатьләндерелергә тиеш. Димәк, алар мәсьәләне хәл итү юлларын табарга тиеш, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эт өрсә, авызын каплап булмый...

Кыскасы, проблема, депутатларга уйланырга җирлек бар. Көндез тынлык сәгатьләре кертү турында Татарстан торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе буенча җәмәгать контроле төбәк үзәгенең башкарма директоры Дмитрий Романовның фикерен белештек. Мондый чикләүләр кертүнең әллә ни авырлыгын күрми ул. Аның фикеренчә, хәл итәсе тагын да зуррак мәшәкатьләр бар.

– Дөресен әйткәндә, безгә мондый шикаятьләр бик аз килә. Әйтик, бертуктаусыз ремонт ясаудан зарланучылар бар. Аның каравы йортларның «Ватсап» чатларында, шаулыйлар, дип күп язалар. Үзара сәгатьләр билгеләп, аңлашкан вакытлары да була. Бу – шәхси очраклар. Яңа йортка күчкәч, хуҗаларның ремонт ясыйсы килә. Көндез билгеле бер сәгатьләр кертелгәндә, бу эшләр тоткарланып торачак, – ди Дмитрий Романов. – Элек андый проблема юк иде. Кешеләр башкача, таләпчәнрәк дип әйтимме шунда. Менталитет та үзгәрә, һәркемнең үз кагыйдәсен кертәсе килә. Мондый чикләү кертелсә, начар булмас, күршеләр шауларга ярамавын белеп торачак. Әмма эт өрсә, аның авызын каплап булмый бит. Моны никадәр хупларлар, белмим. Әмма миңа калса, бер сәгать тә җиткән.

Татарстанда бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец әйтүенчә, әлеге закон проекты балалары булган әниләргә ярдәм итүне күздә тота.

– Бу тәкъдим нәкъ менә балаларга, бигрәк тә сабыйларга ял итәргә мөмкинлек бирүгә бәйле. Гомумән, мин балалары кычкырган гаиләләргә карата дәгъвалар булачагына шикләнәм. Бу тыю күбрәк ремонт үткәрүчеләргә кагыла. Чүкеч белән кагу һәм бала елау арасында аерма бар. Шулай ук төнге клуб урнашкан йортта иртәнгә кадәр музыка кычкыртып, йокларга ирек бирмәү белән төнлә бала уянып кычкыру – икесе ике нәрсә, – ди Ирина Волынец.

Татарстанның атказанган артисты, баянчы Илфат Шәехов фатирында тавыш яздыру студиясе урнашкан.

– Дөбер-шатыр кычкырып, тавышланып эшләмибез. Берәүнең дә зарланганы юк әле. Киресенчә, күпләр баян уйнаганны ятарып тыңлыйбыз, диләр. Хәзерге фатирларда бөтен нәрсә ишетелә: күршеңнең нәрсә эшләгәнен бик тиз чамалыйсың. Әмма иң яманы – исерек күрше белән бораy тавышыдыр, мөгаен, – ди Илфат Шәехов. – Көндез «тынлык сәгате» кертәләр икән, мин шат кына. Кеше ял итеп алырга тиеш. Закон – бер хәл, иң мөһиме – мөнәсәбәт. Мин күршеләремнең һәркайсын беләм. Алар белән уртак тел табып яшим. Өстәге күршенең эштән арып кайткан чаклары була. Комачаулыйм икән, шалтырата – шулай сөйләшеп куйдык. Һәр нәрсәдә чама булырга тиеш.

Белгеч сүзе

Гөлнара БЕГЛОВА,
«Ялилов һәм Партнерлар» юридик фирмасы юристы:

– «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» республика законын бозучылар административ җаваплылыкка тартыла. Әлеге статья кисәтүне дә, административ штраф салуны да күздә тота. Әйтик, гражданнарга 500дән 1000 сумга кадәр штраф яный. Бу хәл бер ел эчендә тагын кабатланса, штраф күләме 1500–2000 сум булырга мөмкин. Гамәлдәге закон нигезендә, җавапка тарту өчен гражданнарның субъектив фикере нигез булып тора. Димәк, һәркем тынлыкны бозуны үз хисләреннән чыгып бәяли. Минемчә, бу дөрес түгел. Зыян күргән як законны явыз ният белән кулланырга да мөмкин.

Әлбәттә, көндезге «тыныч сәгать» кечкенә балалары булган һәм өлкән яшьтәге кешеләр өчен бик кирәк. Әмма моны кертсәң, явыз ниятләрне бетерү өчен, минемчә, рөхсәт ителгән тавышның чикләрен һәм аны үлчәү принципларын беркетергә кирәк. Юкса аны кабул иткән очракта, әлеге закон тагын да күбрәк бәхәсләр китереп чыгарачак.

ТӨНГЕ ВАКЫТ
22.00–6.00
22.00–9.00 (ялларда)

ТЫЕЛА



транспорт чараларындагы тавыш сигналларын вакытында сүндермәү

пиротехника куллану



кешеләрнең тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китергән очракта телевизор, радиоприемник, магнитофон һәм башка тавыш чыгара торган, шул исәптән транспорт чараларында, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларында һәм күңел ачу үзәкләрендә урнаштырылган җайланмаларны куллану

музыка коралларында уйнау, сызгыру, җырлау, шулай ук тынычлыкны бозган тавышлар чыгару

ремонт, төзелеш, төяү-бушату эшләре

20 июнь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
06.30, 07.10, 08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 01.0 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Уроки истории». Волжская Булгария 6+
00.35 «Здоровая семья» 6+
00.50 «Если хочешь быть здоровым» 12+
02.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Син һәм мин». Салават Миңнеханов һәм Гүзәлем концерты 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 «Мин бу җирне матурларга тудым». Әнгам Әтнабаев иҗатына багышланган кичә 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Башваткыч» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Виктория Исакова в многосерийном фильме «ЗАКЛЮЧЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
00.00 «Их звали травники» 16+
01.10 «НА ПОРОГЕ ЛЮБВИ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.00, 17.00, 20.25 Новости
06.05, 16.05, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Челси» (Англия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.05 «ЗАСТЫВШИЕ ДЕПЕШИ» 16+
17.05 Смешанные единоборства. Fight Nights. Фёдор Емельяненко против Фабио Мальдонадо. Трансляция из Санкт-Петербурга 16+
18.00, 04.00 «Нас не стереть!» 0+
19.20 «Громко». Прямой эфир
20.30 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы.
23.40 Смешанные единоборства. UFC. Трансляция из США 16+
00.50 «Спортивный детектив. Повелитель времени» 12+
01.50 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Атланта Стим» – «Омаха Харт» 16+
02.40 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 «Самые сильные» 12+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ» (S) 16+
23.25 «ПЁС» (S) 16+
03.15 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Лаборатория любви» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Морок» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ВОЗМЕЗДИЕ» 16+
19.00 «БЕДНАЯ САША» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Тест на отцовство» 16+
03.10 «Давай разведёмся!» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «СНЕГ И ПЕПЕЛ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.50 Новости дня 16+
09.35 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ 12+
11.20 «Открытый эфир» 16+
13.25, 14.05 «СПУТНИКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Открытый эфир» 16+
21.50 «Между тем» Премьера! 12+
22.15 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Дэн Сяопин. Китайское экономическое чудо» 12+
23.05 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №105» 16+
23.55 «ДВАЖДЫ РОЖДЕННЫЙ» 12+
01.15 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
02.40 «Провал Канариса». Док. фильм 12+
03.25 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.55 «БЕЗ ПРАВИЛ» 16+

21 июнь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
06.30, 07.10, 08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ-2» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Уроки истории». Улус Джучи. Золотая Орда 6+
01.00 «Соотечественники». «Солнечные сосны» Шишкина 12+
01.25 «Здоровая семья» 6+
01.40 «Если хочешь быть здоровым» 12+
02.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Җырларымны сезгә юлладым». Бәширә Насыйрова концерты 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Родная земля» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Яшәү – мизгел». Татарстанның халык артисты Нәфкать Нигъмәтуллин концерты 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
01.05 Марат Мухин хитлары 6+
03.15 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
00.00 «ВОЙНА ЗА ПАМЯТЬ» 12+
01.45 «СОРОКАПЯТКА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 15.00, 17.00, 19.20 Новости
06.05, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 Специальный репортаж 12+
09.20 Футбол. Лига чемпионов. «Барселона» (Испания) – ПСЖ (Франция) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 «Кубок PARI Премьер» 12+
13.00, 15.05 «ЗАСТЫВШИЕ ДЕПЕШИ» 16+
16.05 Все на Кубок PARI Премьер! Прямой эфир.
17.05 Смешанные единоборства. UFC. Хабиб Нурмагомедов против Конора МакГрегора. Трансляция из США 16+
18.00, 04.00 «Нас не стереть!» 0+
19.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Нижний Новгород». Прямая трансляция из Санкт-Петербурга.
22.55 «Есть тема!» 12+
23.15 «НЕСЛОМЛЕННЫЙ» 16+
01.50 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Нэшвилл Найтс» – «Остин Акустик» 16+
02.40 «Андрей Аршавин» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+

НТВ

04.45 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПОД ЗАЩИТОЙ» (S) 16+
23.25 «ПЁС» (S) 16+
03.10 «Их нравы» (0+
03.30 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «В пламени свечи» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «НОТЫ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «БЕДНАЯ САША» 16+
22.50 «Порча» 16+
23.25 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.35 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.45 «Пять ужинов» 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕЗ ПРАВИЛ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.50 Новости дня 16+
09.20 «Освобождение». Док. сериал 16+
09.45 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25, 14.05 «СПУТНИКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Открытый эфир». Премьера! 16+
21.50 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.15 «Великая Отечественная в хронике ТАСС». Док. фильм 12+
23.20 «Легенды армии». Николай Абрамов 12+
00.10 «Обыкновенный фашизм» 16+
02.25 «Оружие Победы» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 20–26 ИЮНЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)

Хезмәт баскычыннан очып диярлек менеп китү мөмкинлеге ачылыр. Әмма сез кубрәк эшләргә һәм барысы өчен дә җавап бирергә әзерме? Шул хакта уйланырга кирәк булыр.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)

Алдын-артын уйлап бетермичә, тегә яки бу карарга килә күрмәгез. Кызып китеп, кирәкмәгән тарафка юл алуыгыз яки кирәкмәгән әйбергә ризалык бирүегез бар.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)

Бу атнада үзегезне бик матур очрашулар, күңелгә сары май булып ятардай бүләкләр, кызыклы хәлләр көтә. Кайберәүләр өчен сәяхәткә чыгу мөмкинлеге шәйләнер.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)

Гамьлелек һәм сабырлык кирәкмәгән стресстан котылуга һәм шул рәвешле көчегезне саклап калуга ярдәм итәр. Атна уртасында алдыгызда кинәт кенә барлык ишекләр һәм моңа кадәр җентекләп сакланылган үтә яшерен серләр ачылыр. Һәр яңа әйбергә шикләнеп карау гадәте галәмәт тә уңай нәтиҗәгә китерер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)

Бу атнада эштә кинәт кенә үсеп китү мөмкинлеге пәйда булырга мөмкин. Тормышыгызда зур үзгәрешләргә әзер торыгыз. Бердәнберегез, сөенече белән уртаклашып, үзегезне куандырыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)

Бер дустыгызның акыллы киңәше ярап куяр. Атна уртасында көтелмәгән, әмма матур очрашу булачак. Әйбәт кенә акча керер.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)

Үткәнгә йомгак ясап, шәхси тормышыгызда үзегез өчен яңа сәхифә ачарга вакыт! Алда яңа мөмкинлекләр көтә, аларны кулдан ычкындырмаска гына кирәк. Тик яшерен серләрегез белән генә уртаклашмагыз, юкса...

ЧАЯН (24.10 – 22.11)

Табышлы гына эш тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Ике дә уйламыйча, ризалашыгыз – укенмәячәксез! Шәхси тормышыгыз да илһамландырачак һәм сөендерәчәк.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)

Чираттагы ялга чыгарга вакыт. Бик уңышлы, бәрәкәтле, файдалы һәм отышлы узачак ул. Атна ахырында күңелгә зур тынычлык иңдерердәй хәлләр булып алачак.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)

Тирәгездәгеләр сездән рәхәтләнеп файдалана, ә үзләреннән – ни ит, ни йон... Әмма шулай тоела гына бугай бу. Шуңа күрә алар тарафына авыз ачып кырын сүз әйтү кирәкмәстер. Якыннарыгыз әйбәт яңалыклары белән сөендерер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)

Атна башында күңелле вакыйгалар, бүләкләр, романтик хисләр көтелә. Болар үзегезгә гүя канатлар куеп, шикләрегезне таратып, көч-куәт өстәп җибәрер. Өстәвенә әле кесәгез дә калынаеп китәр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)

Сез хәзер аеруча мөлаем. Әмма көнләшүгә җирлек тудыра күрмәгез, юкса бердәнберегез белән уртак тел табу авыр булыр. Балаларыгызның уңышларыннан күңелегез күтәрелер.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе һәм финанс эшчәнлегендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы финанс министры **Гайзатуллин** Радик Рәүф улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен шәхси эшкуар **Әхмәтова** Мәдинә Габделбарый кызы; милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен «Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районының җирле татар милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасы рәисе **Богданова** Лилия Фуат кызы; «Ульяновск өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасы башкарма комитеты рәисе **Сафин** Рәмис Фарук улы; Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасында чуваш милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе киңәшчесе **Гафаров** Иршад Әхмәт улы; җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы урынбасары, полиция полковнигы **Руденко** Евгений Анатольевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы-оештыручысы **Гатиятов** Расип Рәшит улына, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең мәктәпкәчә һәм башлангыч гомуми белем бирү кафедрасы доценты **Җамалетдинова** Зәлфирә Исхак кызына, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең мәктәпкәчә һәм башлангыч гомуми белем бирү кафедрасы өлкән укытучысы **Сәгъдиева** Илсөя Тәлгать кызына, «Ульяновск өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасының мәгариф һәм мәктәпкәчә яштәге балалар оешмалары белән эшләү бүлеге мөдире **Сәйфетдинова** Ирина Ренат кызына, «Иннополис лицее» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Сулимова** Надежда Алексеевнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ИРТӘНГЕСЕ КУРКЫНЫЧ ТҮГЕЛ

Кул ою – күбебезгә таныш халәт. Еш кына иртәнге якта – йокыдан торгач борчый ул. Икенче берәүләр көн дәвамында кул оюдан интегә. Табиблар һәр ике очракта да игътибарлы булырга киңәш итә. Ник дигәндә, кул ою бик күп чирләр турында кисәтергә мөмкин, ди алар.

Табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА белән кул оюы турында сөйләштек.

:: Диләрә Рәхимовна, кул оюы нинди чирләр турында кисәтә ала?

– Кул оюның сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Шулай да ул еш кына муендагы хилафлыклар аркасында пәйда була. Нерв зарарланганда, инсульт вакытында да кешенең кулы ойый. Шикәр чире, умырткасында бүсер булган, артрит диагнозы куелган кешеләр дә кул оюдан зарланырга мөмкин.

:: Кайсы очракларда кул оюдан курку урынсыз? Кайсы очракта, киресенчә, чаң сугарга кирәк?

– Кешенең иртәнге якта, йокыдан торгач кына кулы оеп алса, куркырга кирәкми. Моны булдырмас өчен мендәрне алыштырырга, дөрес итеп – янга яки аркага ятып йокларга кирәк. Уртача катылыктагы ортопедик матраста йоклау да хәерле. Әгәр кешенең кулы, бармаклары бөтенләй эшләмәсә, кичекмәстән табибка мөраҗәгать итәргә кирәк.

:: Кул оюга нәрсә ашавыбыз да йогынты ясыймы?

– Һичшиксез, йогынты ясый. Кул оюы еш кына организмга В, А төркеменә керүче витаминнар, магний, кальций кебек микроэлементлар җитмәгәндә дә борчый. Болар үз чиратында нервның зарарлануына да китерә ала. Шикәр, исерткеч эчемлекләр белән мавыгу да кул оюга сәбәпче булырга мөмкин.

:: Кулдан тыш, баш түбәсе, аяк, умыртка яны, калак сөяге тирәсендә дә оюлар була бит.

– Умыртка яны, калак сөяге тирәсендә оюлар сирәк очрый. Моңа нигездә кабырга арасы невралгиясе сәбәпче. Дөрес, ул очракта аны ою дип тә әйтеп булмый. Ул күбрәк умыртка янын, калак сөяген чәнчү, төртүне хәтерләтә. Аяк нервлары зарарланган булса, ул да ойый. Моңа шулай ук, нигездә, шикәр, химик ризык, исерткеч эчемлекләр белән мавыгу, организмда тупланган токсиннар сәбәпче.

vk.com

:: Кул оеган мизгелдә хәлеңне ничек җиңеләйтеп була?

– Йокыдан торгач, кул оеса, кулны җиңелчә генә массажлап алырга кирәк. Кул оюы инсульт яки нерв зарарлану белән бәйле булса, хәлеңне берничек җиңеләйтәм димә. Бу очракта кичекмәстән табибка мөраҗәгать итәргә кирәк. Кул муендагы хилафлыклар аркасында оеса, муенны массажларга мөмкин. Шунысын да истә тотарга кирәк: кул оеганда кайнар ванна, мунча керергә ярамый!

:: Кисәтү өчен тагын нинди кагыйдәләрне истә тотарга?

– Кул оюны кисәтү өчен, тукланудан тыш, эшләгәндә, машинада барганда дөрес итеп утыру да мөһим. Йоклаганда, әйткәнемчә, янга яки аркага ятарга кирәк. Корсакка ятып йоклаган кеше еш кына кул оюдан интегә. Ортопедик мендәр, матраста яту да мөһим.

Исеңдә тот!

Дәва – аяк астында

Кузгалак – витаминлы, файдалы үлән. Ул ашкайнату системасына уңай йогынты ясый, бавыр һәм үт куыгы эшчәнлеген яхшырта. Кан агуны туктата, азкалылыктан, йөрәк һәм кан тамырлары авыруларыннан ярдәм итә. Шулай ук тире авыруларыннан, кычытудан булыша, аллергиядән коткара.

▶ Ангинаны дәвалау өчен һәм бизгәктән яңа өзелгән яфракларын һәм каты булмаган сабакларын чистартырга, яхшылап юарга да артык суын саркытырга кирәк. Кайнар су белән пешекләргә, турарга һәм агач кашык белән изәргә. Соңыннан марля аша эмаль савытка суын сыгып, 5 минут кайнатырга. Төнәтмәне суыткычта сакларга кирәк. Көненә өч тапкыр, ашаган вакытта берәр кашык эчәргә киңәш ителә.

▶ Кузгалак составына керүче суда эреми торган хуш исле органик матдәләр, аскорбин, К һәм С витаминнары үртлар зарарланган вакытта ярдәм итә. Шуңа күрә кузгалак яфракларыннан әзерләнгән төнәтмә авыз куышлыгын чайкау өчен кулланыла.

▶ Бил сызлаганда мондый төнәтмә әзерләргә була: бер кашык кузгалак тамырларына 300 мл кайнар су салып, 15 минут кайнатырга, өстен каплап куярга. Берничә сәгатьтән сөзәргә һәм шуны көненә өч тапкыр ике кашык эчәргә кирәк.

▶ Цистит булганда төнгә каршы кузгалак төнәтмәсе белән ванна керергә була. Моның өчен 1 литр суга ярты кило кузгалак алырга, сүрән утта 10 минут кайнатырга һәм шуны ваннага салырга кирәк. Суның температурасы 36 градус булырга тиеш. Процедура вакыты – 10 минут.

▶ Эч киткән вакытта да кузгалактан әзерләнгән дару ярдәм итәр. 2 кашык туралган тамырларны 0,3 литр кайнар суда төнәтергә, ярты сәгать су «мунча»сында тотарга кирәк. Суытып, сөзәргә дә күләмен башта алынган кебек дәрәҗәгә җиткерергә. Көненә өч мәртәбә, ашарга ярты сәгать кала 2 кашык эчәргә кирәк.

Белеп тор!

Үзе дә, согы да файдалы

✓ Бәрәңге согында иммунитетны яхшырта торган С витамины бар.

✓ Икегә аерылган юка чәчләрне шулай ук бәрәңге согы белән дәвалыйлар. Аны чәч төбенә сылап, 20 минут тотыгыз да юып төшерегез.

✓ Коры бит тиресен бәрәңге согына манылган мамык белән дымландырыгыз.

✓ Бәрәңге согы йөрәк өчен дә файдалы, ул холестерин күләмен киметә.

✓ Гастрит вакытында бәрәңге согын ун көн эчеп, ун көн тәнәфес ясау мөһим. Иртән ашарга ярты сәгать кала, аны бер стакан эчәргә кирәк.

✓ Бәрәңге согы бавырны һәм үт куыгын агулы матдәләрдән чистарта.

✓ Аны еш эчкәндә, ашказаны-эчәк тракты эшчәнлеге яхшыра.

✓ Бәрәңге суын көнгә 3 мәртәбә ашар алдыннан эчсәң, файдасы зур. Бәрәңге согы 10 минут эчендә бозыла. Аны сыгу белән эчәргә кирәк. 4–5 атна эчендә ул – гастрит, колитны, 6–8 атна эчендә ашказаны җәрәхәтен бетерә. Яшь бәрәңге согы аеруча файдалы. Тәмле булсын өчен, аңа бал яки мук җиләге согын кушарга мөмкин.

Үзем сынадым

ЮТӘЛ КИМЕДЕ

Бер ай элек яхшы ук ютәлләп авырдым. Төнлә буыла-буыла йөткерә идем. Бер танышым җайлы гына рецепт өйрәтте, шуның файдасы күрдем. Ютәлдән мәк сөте коткара икән. Бик җиңел әзерләнә. 2–3 бал кашыгы мәккә бераз кайнар су салып, яхшылап изегез. Изелгән мәк өстенә бер стакан кайнар су салып, бераз төнәткәч, сөзәргә кирәк. Әлеге төнәтмәне көн саен йоклар алдыннан бер стакан эчәргә. Файдасы шундук сизелә.

Әлфия ГОМӘРОВА. Әлмәт

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ШИФАСЫ – ЯФРАГЫНДА

Мунча себеркесе әзерләү вакыты җитеп килә. Питрауга кадәр (җәйнең кыл уртасы – 12 июль) һәм аннан соң бер атна – чын себерке бәйли торган вакыт, диләр. Рус халкы исә Троица бәйрәме (каен бәйрәме дип тә йөртелә, быел 12 июньдә) узгач ук, бу эшне башкарып куя ягын карый. Балык Бистәсендә яшәүче 62 яшьлек Петр Андреев безгә мунча себеркесе бәйләү серләрен чиште.

СЕБЕРКЕ БӘЙЛӘҮ БУЕНЧА 3 КИҢӘШ

✓ Себеркенең озынлыгы 50–60 см булырга тиеш.
✓ Үләннәрне 30 см чамасында кисеп урнаштырабыз.
✓ Ботакларны өстән тигезлибез. Кыскаракларын себерке эченә куеп калдырабыз.
✓ Тоткычының калынлыгы уртача 6 см булган себерке – чабыну өчен иң уңайлысы.

Карт та, яшь тә булмасын

«Питрауга кадәр үлән шифасы – яфракта, Питраудан соң – тамырда», – ди Петр Николаевич. Мунча себеркесен Питрау тирәләрендә җыюдан да яхшысы юк. Себеркене каен ботаклары очындагы яфраклары башкалары белән бер зурлыкта булгач җыярга кирәк. Яфраклар шул Питрау җиткәндә тигезләшә дә инде. Тигезләшкәнен котмәсәң, кипкәч, коелып бетәчәк.

Мунча себеркесе өчен ботакларны артык яшь агачтан да, картыннан да җыймыйлар. Иң яхшысы – 15–20 еллык каеннар. Ботакларны, файдалы үлән җыйган кебек, аяз көнне, чык кипкәч, иртәнге якта яки кон сүрелә башлагач җыярга киңәш ителә. Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, ачыклыкта үскәненә караганда, урман эчендә үскән агач яфракларының сыйфаты яхшырак. Яфраклары коелмасын, хуш исен җуймасын өчен, себеркене урман эченнән җыю кирәк.

vk.com

Ак әрем хикмәте

Бәйләүгә килгәндә, әзер ботакларны берәр көн караңгы җиләс урында, әйтик, келәттә яки сарайда тоту яхшы. Болай эшләгәндә, ботаклары бераз кипшерә һәм себерке сабы бушамый. Мунча себеркесенә төрле үләннәр – әйтик, мәтрүшкә, бөтнек, ромашка кыстырып бәйләүдән дә яхшысы юк. Петр Николаевич үзе себерке уртасына ак әрем куеп калдыра икән. Эссе мунчада әрем исе шундук таралып китә. Мунчаны да сафландыра, аннан тән тиресенә дә зур файда. Себеркегә бер-ике озын кычыткан куеп калдыручылар да бар. Кайнар суда пешекләгәч, чакмый. Чабынганда, кычыткан согы тәнгә үтеп керә һәм күзәнәкләрне чистарта икән. Мунча себеркесендәге юка ботагы исә мунчага балның хуш исен тарата.

Петр Андреев, бөтен тәмен белеп чабынучы кеше буларак, каен себеркесе белән генә канәгатьләнми. Имән себеркесе ныклыгы, берничә мунчага җитүе белән алдыра, ди ул. Яшь чия ботакларыннан әзерләнгән себерке дә бик әйбәт: тәнне һәм буыннарны дәвалый. Әрекмән себеркесен 6–7 зур яфрактан бәйлиләр. Ул башны чабу өчен бик әйбәт: кан тамырларын киңәйтә, кан басымын җайга сала. Кайвакыт артыш куагыннан ясалган себерке дә кулланыла икән. «Тәнне чәнчи чәнчүен, аның каравы файдасы зур», – ди Петр Николаевич. Артыш себеркесе белән бил, муен һәм җилкә өлешләрен чабу яхшы. Ә менә сирень ботакларыннан ясалган себеркене чабыну өчен түгел, ә хуш исе өчен генә куллана. Мондый себерке мунча эссесен йомшартып, бөтен тәнгә рәхәтлек өсти.

Белеп тор!

ПЕТРУШКАНЫ ЮУ СЕРЕ

Салкын суда түгел, ә җылы суда юарга кирәк, бу очракта хуш исе озаграк сакланачак. Саклауга килгәндә (барлык яшел тәмләткечләрне), юеш чүпрәккә төреп, полиэтилен капчыкка салып кую әйбәт. Бик озак шиңмәячәк!

ТӘМЛӘТКЕЧ ӘЗЕРЛИБЕЗ

Бакчада үскән яшел тәмләткечләрне җыеп, кышка әзерләп куйсаң, бөртеге дә әрәм булмый. Укроп, рәйхан, сельдерей, чабыр, кипкән әче һәм татлы борыч, кипкән кишернең барысын бергә блендерга салып ваклыйбыз. Яшелчә катнашмасын кечкенә банкаларга тутырып куябыз. Кышын куллану өчен менә дигән тәмләткеч!

НОГЫТ БОРЧАГЫНА МАЙ КИРӘК

Телеңне йотарлык ногыт борчагы әзерләү ысулын өйрәтик әле. Моның өчен суын кайнап чыккач ук түгәргә кирәк. Шуннан соң, салкын су салып, 3 аш кашыгы үсемлек мае өстәргә һәм пешереп җиткерергә.

Тәмле булсын!

Витаминлы пәрәмәч

Роза ИДРИСОВА рецептлары

Витаминлы үләннәр һәм суган кыяклары картайганчы, бик тәмле, өстәвенә витаминлы да пәрәмәчләр пешереп калыйк әле. Камырны гадәттәгечә басабыз.

✓ **Кузгалак пәрәмәче.** Кузгалакны ваклап турап, бераз гына шикәр комы өстибез һәм кул белән йомшартабыз. Чыккан суын түгәбез. Камыр җәймәләренә бераз шикәр комы, кузгалак салып, пәрәмәч ясыйбыз. Җоен аска каратып, майда йөздереп пешерәбез.

✓ **Яшел суган һәм йомырка пәрәмәче.** Суган кыякларын ваклап турыйбыз. Бераз тоз салып, кул белән йомшартабыз. Йомырканың сарысын ваклап турыйбыз, агын эре тишекле угыч аша чыгарабыз. Майда йөздереп пешерәбез.

Бакчачы почмагы

Сорауларга бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә.

:: Суган кыягын колорадо коңгызына охшаш ниндидер бөҗәк ашый. Тозлы су сибеп карадым – булышмады. Нишләтим икән?

Ландыш Гарифуллина

– Суган кыягын ашый торган корт (луковая трещалка) ияләшкән, димәк. Суганга гына түгел, сарымсакка, лаләгә, ландыш чәчәкләренә дә зыян салырга мөмкин ул. Әлеге комсыз корткычлардан яфрак җепселләре генә кала. Суган, сарымсакка химик препарат сибеп булмый, әлбәттә. Бу очракта «Фитоверм» биопрепаратын кулланырга кирәк. 15әр көн саен 3 тапкыр шуны сипсәгез, бөҗәкләр юкка чыгачак. Болай эшләргә дә була: чәчәк ата башлаган әремнең өске өлешен җыеп (800 грамм чамасы), шуны бер чиләк салкын суга салып куярга. Бер тәүлектән соң 30 минут дәвамында кайнатып алырга. 1 чүмеч әрем суына 1 чүмеч чиста су салып, түтәлләргә сибәргә. Ә инде чәчәкләрне «Актара», «Искра», «ИнтаВир», «Карбофос» препаратлары белән эшкәртергә мөмкин. Көздән бу җирне казып калдырырга кирәк. Икенче елга анда башка әйбер утыртырга киңәш ителә.

:: Роза куакларын кырмыска басты. Күкәйләреннән юрган сырып куйганнармыни! Болардан ничек котылыйм икән?

Әнҗе Хафизова

– «Муравин», «Гром», «Кинмикс», «Алатар», «Великий воин» кебек препаратларны инструкциясендә күрсәтелгәнчә сибегез. Чәчәк – ризык түгел, «химия» кулланудан курыкмагыз. Кырмыскадан соң гадәттә үлән бете пәйда булырга мөмкин. Караштырып торыгыз: монысы барлыкка килсә, тагын берәр препарат белән эшкәртегез. Тәпләренә көл сипсәгез дә була. Яфракларына тисә дә ярый. Өстән генә сипмәгез.

:: Теплицадагы кыяр үсентеләренең бөтен чәчәкләре диярлек кысыр. Нишләтергә дә белгән юк...

Нурания Гарипова

– Гадәттә көннәр суык тору, салкын су сибү, кояш нурлары җитмәү сәбәпле кысыр чәчәкләр барлыкка килә. Бу хәлдән котылу өчен, гибрид сортлы кыярларның (серкәләнү өчен бал кортлары кирәкми торган сортлар) астан 5 нче яфрагына кадәр тармакларын, чәчәкләрен, мыекларын өзәргә кирәк. Кыярлангач, 7–8 нче яфракка кадәр кыярларын гына калдырып, сабакларын өзәргә. Шуннан инде тармакларының очын гына өзеп ташларга. Тиешле озынлыкка үсеп җиткәч, тагын очларын өзәргә. Болай эшләгәндә, кыяр мулдан булачак.

ҖИДЕ КАТ УЙЛА, БЕР КАТ КЕР

Ниһаять, чын җәйгә аяк бастык. Күңел табигатькә, бигрәк тә су янына тартыла. Үзе рәхәт, үзе хәтәр чор. Елның-елында нәкъ менә шушы чорда хәвеф-хәтәр, бигрәк тә суга бату очраклары арта бит. Рөхсәт ителмәгән урында су кереп, гомереңне куркыныч астына кую гөнаһмы? Мөселманнарга кояшта кызынырга ярыймы?

Шушы сораулар белән «Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВка мөрәҗәгать иттек.

:: Һава торышы су коенырлык булмаганда суга кереп батып үлү яки балык тотканда суга батып үлү үз гомереңә куркыныч янаганын белә торып үзеңне үлемгә китерү була бит. Бу суицид саналмыймы?

– Кеше үз гомерен куркыныч астына куярга тиеш түгел. Фәлән урында су коенырга ярамаганлыгын, суның салкын, һава торышының начар икәнен белә торып керсә, ул үзенә үзе зарар китерүче була. Моны суицид, төгәлрәге, шуңа якын гамәл дип әйтергә була. Әгәр кеше балыкны гаиләсен туендыру өчен түгел, кызык өчен генә тотканда батып үлсә, бу гөнаһ санала. Әгәр балыкка мохтаҗлыктан барган булса, бу очракта ул суицид булмый, гаиләсен туендыру юлында үлгән кеше саналачак.

:: Суга батып үлгәннән соң мәетләре табылмаган кешеләр турында ни әйтерсез?

– Әгәр бу кешенең батып үлгәнлеген 100 процент белсәк, аны искә алып Коръән укыла, догалар кылына. Җеназа намазы мәсьәләсенә килгәндә, ул кешенең мәете булган вакытта гына укылырга тиеш. Әгәр суга баткан кешенең мәете табылмаса, җеназа намазы укылмый.

:: Су коенганнан соң чайканмый гына намаз укырга ярыймы?

– Әгәр кеше суга госел алам дигән ният белән чумса, авызын-борынын чайкатса, ул геселле санала, тәһарәте дә була. Аңа шул килеш намаз укыса да рөхсәт ителә. Ник дигәндә, су аның бөтен тәненә тигән була.

:: Хатын-кызлар һәм ир-атлар ислам дине кануннары буенча ничек су коенырга тиеш?

– Иң элек ир-ат белән хатын-кызларга бергә су коенудан сакланырга кирәк. Коенган очракта, аларның гаурәт җирләре томаланган булырга тиеш. Ир кешеләрнең гаурәте – кендектән алып тез астына кадәр. Хатын-кызларның бите, беләзектән куллары, тубыктан аяклары гына күренеп торырга мөмкин. Гүзәл затларның башка барлык урыннары капланган булуы шарт. Бүген ир-атлар, хатын-кызлар өчен дә шундый махсус коену киемнәре бар. Әгәр кеше су буенда үзе генә булса, аны беркем дә күрми икән, ул очракта бу шарт түгел. Кешеләр янында су коенганда гаурәт урыннары капланган булырга тиеш.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Су коену урынында ашап-эчәргә ярыймы?

– Су коенган урында ашау-эчү дин ягыннан тыелмый. Әмма ул ризык хәләл булырга тиеш. Исерткеч эчемлекләр кулланган кешеләр янында да ашарга ярамый. Бу очракта чисталык, пөхтәлек турында да онытмаска кирәк. Ашаганнан соң ул урынны җыештырып китү дә мөһим.

:: Мөселманнарга кояшта кызыну рөхсәт ителәме?

– Мөселманнарга кызыну тыелмый. Әмма бу очракта да гаурәт урыннар капланган булырга тиеш. Кеше күрми, кеше йөрми торган урында кызынсаң, гаурәт урыннарны каплау мәҗбүри түгел.

Гыйбрәт өчен

Дөрес булмаган теләк



Бер тәкъва кеше Аллаһыдан шайтанны күрсәтүен сораган. Аның танышлары: «Аллаһыдан иминлек сора. Шайтанны күрсәң, нишләрсең?» – дигәннәр. Әмма әлеге кеше аларның сүзләренә колак салмаган. Аллаһы Тәгалә аның болай соравына җавап итеп, шайтанны күрсәткән.

Шайтанны күргән кеше аңа сугарга теләгән. Мәлгунь аңа: «Әгәр синә тагын 100 ел яшәү язмаган булса, мин сине, гамәлең өчен җәза буларак, һичшиксез, һәлак итәр идем», – дигән. Шайтанның сүзләренә алданган кеше: «Минем әле озын гомер кичерәсем бар икән, шуңа күрә хәзер ни теләсәм, шуны кылыйм, ә аннары тәүбә кылырмын», – дип уйлаган. Бу рәвешле әлеге кеше гыйбадәтләрен калдырган, гөнаһлы гамәлләргә кучкан һәм, ахыр чиктә, үлгән.

Нәсыйхәт: бу кыйсса көчле теләкләрдән сак булырга кирәклеген аңлата, чөнки алар куркыныч. Адәм баласы Аллаһыдан иминлек сорарга һәм мәгънәсез теләкләрдән ерак булырга тиеш. Шайтанның кешене ялгыштыра торган бик күп хәйләләре бар. Шуларның берсе – кешене алдау. Әгәр кеше берәр яхшы гамәл кылырга яки Аллаһының әмерен үтәргә җыенса, шайтан шунда ук аңа вәсвәсә кыла башлаганын беләбез.

(«Рухуль Бәйан» китабыннан)

Йөгез, бер дога!

Хезмәт хакын алганда укыла

«Әл-хәмду лилләәһи раббил-гааләмиин. Вәс-саләәтү вәс-сәләәмү галәә расүлинәә мүхәммәдин вә әәлиһии әҗмәгыйин. Әллааһүмәрзукънәә ризкан хәләәлән таййибә. Вәстәҗиб дүгаа-әнәә йәә раббәл-гааләмиин. Әллааһүммә иннәә нәгуузү бикә минәл-фәкъри вәд-дәйни, раббәнәә әәтинәә фид-дуньйәә хәсәнәтәүв-вә фил-әәхыйрати хәсәнәтәүв-вә кыйнәә газәәбән-нәәр».

Мәгънәсе:

«Аллаһым! Исәнлек эчендә тагын бер ай уздырдык. Шөкерләр булсын. Безләргә пакь һәм хәләл ризыклар бир. Хезмәт хакларыбызны яхшы һәм хәерле җирләргә сарыф итүне насыйп ит. Акчабыз белән безне начар юлларга бастырма. Ибраһим пәйгамбәргә биргән бәрәкәт кебек безгә дә бир, йә Рабби! Дәүләтебезне һәм милләтебезне һәрвакыт яхшы эшләргә юнәлт, догаларыбызны кабул кыл, Аллаһым!»

Сорау – җавап

«Иске таш» мәчете имам-хатыйбы Рамил хәзрәт ЮНЫС җавап бирә.

:: Укыган догалар нигә кабул булмый?

– Йә сез сораган әйбер әлегә сезгә хәерле түгел яки ихласлыгыгыз җитми. Гөнаһлардан тәүбә итмәгән булсагыз да, дога кабул булмый.

:: Баланы җәй айларында сөннәткә утырту начар түгелме?

– Дин буенча моның бер гөнаһы да юк.

:: Ни өчен хатын-кызның якынлыктан баш тартырга хокукы юк? Ни өчен ул гел риза булырга тиеш? Ул очракта мондый якынлык көчләүдән нәрсә белән аерыла? Бу гаделсезлек була түгелме?

– Бу сорауга ике сүз белән генә җавап биреп булмый. Никахның беренче елларында җенси якынлыкка карата мөнәсәбәтегез ирегезнеке белән туры килдеме, әллә инде ул вакытта ук төрлечә карый идегезме? Бәлки, сезнең теләгегез 8–10 сәгатьлек эш көне, җыештыру, пешерү, балалар тәрбиясләү кебек көндәлек мәшәкать аркасында үзгәргәндер? Бәлки, моңа гормоннар сәбәпчедер…

Ирләр белән хатын-кызларның физиологиясе төрле. Теләк булмау сәламәтлеккә яисә психологик халәткә бәйле булырга мөмкин. Мәсәлән, сез үзегезне, ирегезне кабул итә алмыйсыздыр, мохит, арыганлык, балачактан калган ниндидер фикерләрнең сезгә комачаулавы бар. Һәр очрак үзенчәлекле. Сезнең реакциягезнең сәбәбен ачыкларга кирәк. Элек икегездә дә теләк булса, кайчан һәм ни сәбәпле үзгәргәнегезне искә төшерегез.

Моның сәбәбе теләк булмау гына түгел, тирәнрәк ятеренгән. Ир белән хатын арасындагы җенси якынлык – аларның үзара мөнәсәбәте күрсәткече. Эмоциональ якынлык булмаса, җенси якынлык та ярсыткыч, ачу китерә, усалландыра торган бер нокта булып тора. Уртак түшәк проблемасы ул – эчке конфликтның тышка чыгуы. Кайбер парлар җенси якынлыкны сүзсез дә мәхәббәт аңлату, хисләреңне белдерү, үзара аңлашу чарасы итеп күрә. Андый пар өчен якынлык – гаиләне ныгытуга китерә торган бер тылсым.

Ир-хатын булып яшәү ул бурыч – түгел, ә икенең дә бергә булырга теләк белдерүе. Ир белән хатын арасында рухи бәйләнеш булса, алар барлык мәсьәләләрне уртак фикергә килеп хәл итсә, андый гаиләдә хатынның якынлыктан баш тартуы һәм ирнең канәгать булмавына бәйле проблемалар тумый да.

:: Ике кредит түлим. Диндә ул рөхсәт ителми бит. Хаҗга барсам, ул кабул булырмы икән?

– Әгәр сез бурычыгызны график буенча түләп барсагыз, шул ук вакытта хаҗга барырга да мөмкинлегегез бар икән, моның бер куркынычы да юк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

РИНАТА ТЭЙ: «ХАТЫН-КЫЗ КӨЧСЕЗ БУЛА АЛМЫЙ»

Җырчы Рината ТЭЙ белән аралашканнан соң, хатын-кызның ни дәрәҗәдә көчле була алуына тагын бер кат инанасың. Эстрадага килү юлы да шактый мавыгулы, кызыклы аның. Тамашачы өчен кыю, бераз бунтарь тоелган Рината тормышта нинди соң?

:: Ни хәл?

– Аллага шөкер, бер көе. Соңгы арада ныклап иҗатта кайныйм. Күптән түгел генә яңа җырым дөнья күрде, бүген исә шул җырга клип төшерергә ниятләп йөрим.

:: Рузилә (җырчының чын исеме – Рузилә Сәмигуллина), ни өчен нәкъ менә Рината Тэй тәхәллүсен сайладыгыз?

– Рузилә – әти-әнием сайлаган һәм мулла кушкан исемем. Сәхнәдәге кыю образыма туры килә торган Рината исеменнән аермалы буларак, Рузилә эчке дөньямның сыйфатларын үзенә җыйган кебек. Нечкә күңелле, гади. Мәктәптә укыган чакта, әти-әнидән: «Ни өчен миңа Рузилә исемен куштыгыз?» – дип сораганым хәтердә. Заманында бик популяр булган ул, сыйныфта да дүрт Рузилә идек без. Моның өчен бик рәхмәтлемен, исемемне бик яратам.

Ә тәхәллүскә килгәндә, кечкенәдән үк Рината исеменә гашыйк мин. Әтиемнең исеме Ринат чөнки. Җырчы булырга хыялланып йөргән чакта да, мин сәхнәгә Рузилә булып түгел, башка исем астында чыгачакмын, дип уйлый идем. Шулай итеп, Казан мәдәният институтына укырга кердем. 2007 елда «Рахат-лукум» төркемен оештырып җибәреп, 2012 елга кадәр өчәү җырладык. Ул таркалгач, 2012–2018 елларда Линара Батталова белән «Кыю кызлар» булдык. Ул чакта Рината онытылып торгандыр инде. Дуэтыбыз таркалуны шактый авыр кичердем. Ирем Сәгыйрьгә рәхмәт, ул шулкадәр ярдәм итте. Сольный проект башлап җибәрергә дә ул рухландырды, миндә өмет уятты. Хыялымдагы Рината исемен дә ул исемә төшерде.

:: Сәхнәдәге образыгыз башка җырчыларныкыннан аерылып тора. Без яңалыкка сак карарга күнеккән бит инде, сезне дә аңламаучылар юк түгелдер?

– Эстрададагы образым – бик күп эзләнүләр нәтиҗәсе. Нинди булырга тиеш ул – Рината Тэй? Шушы сорауга җавап бирергә тырышам. Интернет, телевидение, мода журналлары, соңгы яңалыклар – барысын күзәтеп барам. Стилистлар белән эшлим. Мактаучылар да, аңламаучылар да бар. Мин соңгы арада чалбарлы костюмнарга өстенлек бирәм. «Нигә күлмәк, итәк кимисез? Сез бит – хатын-кыз!» – диләр. Бүген образыма гаиләмдәге вазгыять тә йогынты ясый, ахры: ничектер ябык, күпмедер дәрәҗәдә ир-атларга хас булган стильне якынрак күрәм.

:: Тәнкыйтькә ничек карыйсыз?

– Тәнкыйтьчеләргә рәхмәттән башка сүзем юк. Дөньяда бар яктан да камил кеше юк. Тискәре ягымны күрсәтүчеләр миңа камилләшергә ярдәм итә. Уңай ягымны күреп, мактыйлар икән, ул сыйфатымны ике тапкыр арттырырга тырышам.

:: Читтән караганда бик кыю күренәсез. Чынлыкта нинди сез?

– Гап-гади авыл кызы. Кеше нәрсә әйтер икән, дип куркып, читләр фикеренә бәйле булып үскән бала. Бүген мин бу бәйлелегемне юкка чыгарырга тырышам. Чөнки һәркем үз язмышы өчен үзе җаваплы һәм үз юлын күңеле теләгәнчә үтәргә хаклы.

:: Бик авырткан урыныгыз булса да, юл фаҗигасенә очрап, могҗиза белән исән калган тормыш иптәшегез Сәгыйрьнең хәлен сорамый кала алмыйбыз...

– Чыннан да, бик авырткан урыным. Бу хәлләргә октябрьдә өч ел була. Ул чакта миңа нибары 32 яшь иде... Күпме авырлыклар күрелде. Соңгы арада бу турыда уйлаган чакта йөрәгем кыса. Менә тагын күземә яшьләр тулды... Ничек кенә булса да, ирем исән калды. Бүген Сәгыйрьне аякка бастырырга һәм улыбызга тиешле тәрбия бирергә Аллаһы Тәгаләдән көч һәм сабырлык сорыйм.

Кызганыч, Сәгыйрьнең хәлендә үзгәрешләр юк. Хастаханәдән хастаханәгә йөрибез. Әле менә күптән түгел ике айдан артык ятып чыкты, бүген инде – өйдә. Сәгыйрьне карарга абыйсы ярдәм итә, мин исә көчемнән килгәнчә матди якны кайгыртырга тырышам. Аңа ничек рәхмәтле булуымны белсәгез! Аллага шөкер, Сәгыйрь сөйләшә. Минем җырлавымны бик ярата. Очрашкан саен янында җырлап кына утырам. Яздыртылганны ачарга рөхсәт юк. «Зинһар, үзең җырла», – ди.

:: Улыгыз йөз-кыяфәткә әтисенә охшаган...

– Әтисенең копиясе ул! Шундый ул бүләк иткән өчен Аллаһыма мең шөкер итәм. 10 яшьтә генә булса да, нәкъ өлкәннәрчә фикерле. Яшәргә, эшләргә көч бирүчем ул минем. Исән-сау гына була күрсен...

:: «Син әле яшь, ташла аны, яңадан кияүгә чык», – дип, ярага тоз салучылар әле дә бармы?

– Бар. Андый кешеләрне тыңлап торам да сүзләрен үткәреп җибәрәм. Яшьме, яшь түгелме, мин – Сәгыйрьнең тормыш иптәше. Һәм мин аны бик яратам. Ничек кенә авыр булса да, бу сынауларны мин тиешле дәрәҗәдә, кеше сүзенә карамыйча узарга тиеш.

Блиц-сораштыру

– Сезнең өчен җыр – нәрсә ул?

– Күңел халәтем, тормышым, сүзләр белән аңлатып бетерә алмаслык хисләр.

– Иң бәхетле көнегез?

– Әти-әнием – исән-сау, улым – янымда, ә үзем кияүдә булган һәр көн.

– Мөмкин булса, тормышыгызны үзгәртер идегезме?

– Юк.

– Хатын-кызның көчсезлеге – аның артык көчле булуында, диләр. Килешәсезме?

– Хатын-кыз көчсез була алмый. Ул ире янында гына үзен көчсез итеп күрсәтә.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Тукай районының Иске Байлар авылыннан **Гөлфинә Шакирова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Айгөл Рәхимова башкаруындагы «Сәбәбен тап», Раяз Фасыйховның «Шомыртлар» һәм Филүс Каһиров репертуарындагы «Соңдыр шул» җырларын яшергән идек.*

Әлеге җыр елга үсемлекләре турында. Аларның да, нәкъ кешеләрнеке кебек, үз хәсрәте, үз кайгы-сагышлары бар, ди җырчы.

Сине күргәч, аның бәгыре ал чәчкәләр кебек алсулана. Күзләреңнән күзен алмый гына йөрәк серләрен сөйләргә тели җырчы.

Әлеге җыр – камыт кияргә ашыкмаучы егетләрнең гимны. Бер генә килгән яшьлекнең кадерен бел, диелә җырда.

22 июнь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Таң атмады бүген...» Әдәби-музыкаль композиция 12+
06.30, 07.10, 08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ-2» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп әйрәник» 0+
16.00 «Никто не забыт, ничто не забыто. Мазитов Назип Минхамидович. 1914–1943». Телефильм 12+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Уроки истории». Золотая Орда 6+
00.35 «Соотечественники». Фешин. Монолог художника 12+
01.00 «Здоровая семья» 6+
01.15 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Иөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Яңа сулыш». Айдар Галимов концерты 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Ватандашлар» 6+
12.40 «Айлы кичтә». Энҗе Шәймөрзина концерты 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Татар халык җырлары» 6+
20.00 «Таң атмады бүген». Әдәби-музыкаль композиция 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
01.05 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Бар фасылга – бер асыл». Татарстанның халык артисты Рузия Мотыйгуллина турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 Павел Деревянко, Андрей Мерзликин. «КРЕПОСТЬ» (S) 16+
00.30 Премьера. «Парад победженных» 12+
01.20 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

04.00 «22 июня, ровно в четыре утра... Реквием Роберта Рождественского»
05.10 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.00 «22 июня, ровно в четыре утра... Реквием Роберта Рождественского»
01.10 Алексей Воробьёв, Владимир Гостюхин, Кирилл Кяро, Николай Иванов. «ТРИ ДНЯ ЛЕЙТЕНАНТА КРАВЦОВА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.00, 17.00, 20.10 Новости
06.05, 16.05, 20.15, 22.55 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 19.50 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Нижний Новгород». Трансляция из Санкт-Петербурга 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
13.00, 15.05 «ЗАСТЫВШИЕ ДЕПЕШИ» 16+
17.05 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков против Жаирзинью Розенстрайка. Трансляция из США 16+
18.00, 04.00 «Нас не стереть!» 0+
20.55 Футбол. Чемпионат Европы среди юношей (U-19). Англия – Сербия. Прямая трансляция из Словакии
23.25 «Есть тема!» 12+
23.45 «Karate Combat 2022. Эпизод 1» 16+
01.20 «Второе дыхание. Дмитрий Саутин» 12+
01.50 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Сиэтл Мист» – «Атланта Стим» 16+
02.40 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 «Самые сильные» 12+
05.35 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД ЗАЩИТОЙ» (S) 16+
23.25 «Квартирник НТВ у Маргулиса». «Брестская крепость» (S) 16+
01.05 Премьера. «Поиск» (S) 12+
01.50 Юрий Борисов, Мари Ворожи. «СЕМЬ ПАР НЕЧИСТЫХ» (S) 16+
03.10 «Их нравы» (0+
03.30 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Мужнина порча» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «КАКОЙ ОНА БЫЛА» 16+
19.00 «БЕДНАЯ САША». 9-я – 12-я серии 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.05 «Верну любимого» 16+
00.40 «Понять. Простить» 16+
01.40 «Тест на отцовство» 16+
03.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

03.30 Мемориальная акция «Свеча памяти»
05.25, 08.20, 09.25, 10.15, 11.15, 11.40, 12.30, 13.15, 14.15, 15.15, 16.15, 17.15, 18.15, 23.30 «Неизвестная война. Великая Отечественная». Документальный сериал 16+
08.00, 09.00, 10.00, 11.00, 12.00, 13.00, 14.00, 15.00, 16.00, 17.00, 18.00 Новости дня 16+
19.00 Вечер памяти «В сердце матери»
04.00 «НЕ ЗАБЫВАЙ» 16+

23 июнь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Утканнар сагындыра» 6+
06.30, 07.10, 08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 00.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ-2» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Безнең Республика – безнең гамәл» 12+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Уроки истории». Культура Золотой Орды 6+
02.00 «Соотечественники». Геннадий Прытков. Актером быть просто 12+
02.25 «Путь». Храм никогда не бывает пустым 12+
02.40 «Не от мира сего». Истинная и мнимая свобода 12+
03.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
05.00 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». Музыкаль телевизион фильм 12+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БИТ Шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Яратып яшик». Раяз Фасыйхов концерты 12+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Габдрахман». Док. фильм 12+
23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 Многосерийный фильм «КРЕПОСТЬ» (S) 16+
00.30 «Невский пятачок. Последний свидетель» 12+
01.25 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.00 «Альфред Розенберг. Несостоявшийся колонизатор Востока». Фильм Алексея Денисова 16+
00.55 Данила Козловский, Андрей Терентьев, Дмитрий Волкострелов, Владимир Яглыч, Екатерина Климова, Борис Галкин, Даниил Страхов, Сергей Маховиков, Игорь Черневич, Зоя Буряк. «МЫ ИЗ БУДУЩЕГО» 16+
03.10 Игорь Петренко, Владимир Яглыч, Алексей Барабаш, Екатерина Климова. «МЫ ИЗ БУДУЩЕГО-2» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.35, 15.00, 17.00, 20.00 Новости
06.05, 19.15, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.25 Футбол. Лига чемпионов. «Манчестер Сити» (Англия) – «Тоттенхэм» (Англия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.05 «КЛЯНЁМСЯ ЗАЩИЩАТЬ» 16+
16.05, 17.05 «13 УБИЙЦ» 16+
18.45 Матч! Парад 16+
20.05 Футбол. Лига чемпионов. «Ливерпуль» (Англия) – «Барселона» (Испания) 0+
22.55 «Есть тема!» 12+
23.15 «Karate Combat 2022. Эпизод 2» 16+
00.50 Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Смоленска 0+
01.20 «Второе дыхание. Валерий Минько» 12+
01.50 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Остин Акустик» – «Лос-Анджелес Темптейшен» 16+
02.40 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 «Самые сильные» 12+
04.00 Смешанные единоборства. АСА. Абдул-Азиз Абдулвахабов против Харкана Диаса. Трансляция из Москвы 16+
05.05 «Несвободное падение. Оксана Костина» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ПОД ЗАЩИТОЙ» (S) 16+
23.25 «ЧП. Расследование» (S) 16+
23.55 «Поздняков» (S) 16+
00.10 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.05 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.55 «Их нравы» (0+
03.10 Игорь Лифанов в детективном сериале «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Проклятая монета» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «ПОДАРИ МНЕ ЖИЗНЬ» 16+
19.00 «БЕДНАЯ САША». 13-я - 16-я серии 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.05 «Верну любимого» 16+
00.40 «Понять. Простить» 16+
01.40 «Тест на отцовство» 16+
03.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.00 «6 кадров» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «НЕ ЗАБЫВАЙ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.50 Новости дня 16+
09.30 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25, 14.10, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
15.10 «Специальный репортаж». «День Победы. Противостояние» 16+
15.50 «БУДУ ПОМНИТЬ» 16+
18.50 «Открытый эфир». Премьера! 16+
21.50 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.15 «Код доступа». «Гаага. Приговор для трибунала» 12+
23.05 «Легенды науки». Владимир Демихов. Премьера! 12+
23.55 «САШКА» 12+
01.20 «БЕССМЕРТНЫЙ ГАРНИЗОН» 12+
02.55 «ИДИ И СМОТРИ» 16+
05.15 «Легендарные полководцы. Петр Румянцев». Док. фильм 16+

24 июнь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Утканнар сагындыра» 6+
06.30, 07.10, 08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 00.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Классный час» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тызрак! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Юлчы» 6+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
00.50 «Уроки истории». Казанское ханство 6+
01.35 «Здоровая семья» 6+
01.50 «Если хочешь быть здоровым» 12+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
04.00 «Иөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Күрешергә вакыт табыйк». Ил-Саф концерты 12+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Иөрәктән – йөрәккә». Россиянең халык рассамы Абрек Абзгильдин турында телеочерк 6+
13.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова концерты 6+
15.30 «Нәсыйхәт» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Туган җир» 12+
19.35 «Заман көзгесе» 6+
20.05, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 К.Тинчурин. «СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Ком сәгате» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 К 60-ЛЕТИЮ ВИКТОРА ЦОЯ. ПОСЛЕДНИЙ КОНЦЕРТ 12+
22.45 Премьера. «ГРУППА «КИНО» – 2021» (S) 12+
00.40 «Алые паруса - 2022». Прямая трансляция из Санкт-Петербурга (S)
01.05 «ЦОЙ – «КИНО» (S) 16+
01.50 «Информационный канал» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 00.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Богдан Ступка, Владимир Вдовиченков, Игорь Петренко, Магдалена Мельцаж, Михаил Боярский, Владимир Ильин, Юрий Беляев, Ада Роговцева, Борис Хмельницкий. «ТАРАС БУЛЬБА» 16+
00.40 «Алые паруса - 2022». Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
01.05 Инна Коляда, Илья Оболонков, Андрей Карако, Зоя Антонова, Марта Голубева. «ОДИНОЧКА» 12+
03.05 Анастасия Задорожная, Илья Иосифов, Ада Роговцева и Жанна Эппле. «ПЛОХАЯ СОСЕДКА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.35, 15.00, 17.00 Новости
06.05, 18.05, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 Специальный репортаж 12+
09.25 Футбол. Лига чемпионов. «Бавария» (Германия) – ПСЖ (Франция) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 «Лица страны. Елена Никитина» 12+
13.00, 15.05 «КЛЯНЁМСЯ ЗАЩИЩАТЬ» 16+
16.05, 17.05 «В ПОИСКАХ ПРИКЛЮЧЕНИЙ» 16+
18.25 Футбол. Чемпионат Европы среди юношей (U-19). Франция – Италия. Прямая трансляция из Словакии
20.25 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Прямая трансляция из Москвы
22.00 Матч! Парад 16+
22.55 «Есть тема!» 12+
23.15 «Karate Combat 2022. Эпизод 3» 16+
00.50 Автоспорт. Российская Дрифт серия «Европа». Трансляция из Москвы 0+
01.40 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. Финал. «Сиэтл Мист» – «Лос-Анджелес Темптейшен» 16+
02.30 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Трансляция из Москвы 0+
03.30 Новости 0+
03.35 «Самые сильные» 12+
04.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Элвин Брито против Луиса Паломино. Прямая трансляция из США

НТВ

04.45 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ПОД ЗАЩИТОЙ» (S) 16+
23.55 «Своя правда» с Романом Бабаяном (S) 16+
01.40 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
02.05 «Квартирный вопрос» (S) (0+
02.55 «Таинственная Россия» 16+
03.40 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Порванные нити» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ!» 16+
19.00 «УРОКИ ЖИЗНИ И ВОЖДЕНИЯ» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.25 «Тест на отцовство» 16+
03.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.45 «6 кадров» 16+
04.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Легенды госбезопасности. Исхак Ахмеров. Мистер «Резидент» 16+
06.45 «ПОЛЕТ С КОСМОНАВТОМ» 12+
08.40, 09.20, 13.25 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
14.00 Военные новости 16+
14.05, 18.55 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА» 16+
18.40 «Время героев». Премьера! 16+
21.15 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
22.15 «Битва оружейников. Автоматическое оружие под малоимпульсный патрон. АК-74 против М16» 16+
23.00 «БУДУ ПОМНИТЬ» 16+
00.40 «ЗАБУДЬТЕ СЛОВО СМЕРТЬ» 12+
02.00 «ТЕНЬ» 16+
03.50 «БЕССМЕРТНЫЙ ГАРНИЗОН» 12+

25 июнь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Фадис Ганиев 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 « Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Татар сүзе-2021» 6+
14.20 «Яңа татар җыры-2» конкурсының гала-концерты 6+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ Шоу». Динара Шәйдуллина 12+
23.00 «ПОДКИДЫШ» 6+
00.40 «Вехи истории». Расцвет татарской культуры 12+
01.05 «Каравай». Ансамбль народной музыки «Тойве» 6+
01.30 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Моңга чорналган язмыш. Александр Ключарев» 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Н.Гыймадинова. «СИХЕРЧЕ». Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Татарстанның халык артисты Зәйнәб Фәрхетдинова концерты 6+
22.25 И.Абдуллин. «ТИЛЕ ЯШЬЛЕК». Туймазы татар дәүләт драма театры спектакле 12+
00.35 Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале 6+
03.00 «Башваткыч» 12+
03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» (0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Парад побежденных» 12+
11.20 «Видели видео?» 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
13.35 «Порезанное кино» 12+
14.35 К юбилею Натальи Варлей. Фильм «СЕМЬ НЕВЕСТ ЕФРЕЙТОРА ЗБРУЕВА» 12+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.20 «Семь невест ефрейтора Збруева» 12+
16.50 Премьера. «Наталья Варлей. Одна маленькая, но гордая птичка» 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «На самом деле» 16+
19.25 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 Лига Бокса. Интерконтинентальный Кубок. Финал. Прямой эфир из Москвы (S)
00.30 К 110-летию со дня рождения Сергея Филиппова. «ЕСТЬ ЛИ ЖИЗНЬ НА МАРСЕ?» 12+
01.30 «Наедине со всеми» 16+
03.45 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.25 «Доктор Мясников» 12+
12.30 Ольга Сухарева, Владимир Яглыч, Татьяна Васильева, Александр Самойленко, Валентин Смирнитский. «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕРТВА» 16+
18.00 «Привет, Андрей! Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Юлия Пожидаева, Дмитрий Мазуров, Марина Калецкая, Виктория Рунцова и Алексей Овсянников. «ЧУЖАЯ СЕМЬЯ» 12+
00.55 Татьяна Колганова, Святослав Астрамович, Дарья Бранкевич, Алексей Фатеев. «ЗАПАХ ЛАВАНДЫ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Элвин Брито против Луиса Паломино. Прямая трансляция из США
08.00, 09.05, 12.05, 15.00, 16.55 Новости
08.05, 12.10, 17.00, 19.00, 22.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 «НУ, ПОГОДИ!». Мультфильм 0+
09.30 «13 УБИЙЦ» 16+
13.00, 15.05 «КЛЯНЁМСЯ ЗАЩИЩАТЬ» 16+
16.05 Профессиональный бокс. А. Бетербиев – М. Браун. Трансляция из Канады 16+
17.25 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Прямая трансляция из Москвы
19.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Сочи» – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
23.00 «Макларен». Док. фильм 12+
00.50 «МОЛОДОЙ МАСТЕР» 12+
02.40 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 «Самые сильные» 12+
04.00 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Трансляция из Москвы 0+
05.00 Смешанные единоборства. UFC. Арман Царукян против Матеуша Гамрота. Прямая трансляция из США.

НТВ

05.15 «ЧП. Расследование» (S) 16+
05.40 Наталья Гребенкина, Дарья Чаруша. «ДЕНЬ ОТЧАЯНИЯ» 16+
07.20 «Смотр» (S) (0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» (S) (0+
09.20 «Едим дома» (S) (0+
10.20 «Главная дорога» (S) 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым (S) 12+
12.00 «Квартирный вопрос» (S) (0+
13.05 «Однажды...» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) (0+
15.00, 16.20 «Следствие вели...» (S) 16+
18.00 «По следу монстра» (S) 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым.
20.20 «Основано на реальных событиях». «Подвиг разведчика» (S) 16+
00.00 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном (S) 16+
00.50 «Квартирник НТВ у Маргулиса». «Эпидемия» (S) 16+
02.05 «Дачный ответ» (S) (0+
02.55 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.25 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
07.25 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ» 16+
11.20 «ПЕРЕЕЗД». 1-я и 2-я части 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 97-я и 98-я серии 16+
22.40 «ПСИХОЛОГИЯ ЛЮБВИ» 16+
02.25 «ГОРДОСТЬ И ПРЕДУБЕЖДЕНИЕ». 1-я – 3-я серии 16+
05.05 «Лаборатория любви» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ШКОЛЬНЫЙ ВАЛЬС» 12+
07.00, 08.15, 03.45 «ЗОЛОТЫЕ РОГА» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.35 «Легенды кино». Георгий Вицин 12+
09.25 «Улика из прошлого». «Тройка, семерка, туз. Тайна карточной мафии» 16+
10.05 «Загадки века». «Советский призрак над странами НАТО» 12+
10.55 «Война миров». Док. сериал. «Катуков против Гудериана» 16+
11.40 «Не факт!» 12+
12.10 «СССР. Знак качества» с Гариком Сукачевым». «Требуйте долива после отстоя пены. Что пили в СССР» 12+
13.15 «Легенды музыки». Виктор Цой 12+
13.40 «Круиз-контроль». Премьера! 12+
14.15, 18.30 «УЗНИК ЗАМКА ИФ» 12+
19.30 «ФРОНТ ЗА ЛИНИЕЙ ФРОНТА» 12+
22.25 «ФРОНТ В ТЫЛУ ВРАГА» 12+
01.00 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+
02.15 «МЕДОВЫЙ МЕСЯЦ» 12+

26 июнь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Очрашулар әзләп». Габделфәт Сафин концерты 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы- шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». Гүзәл Гарәфиева 12+
11.00 «Безнең Республика – безнең гамәл» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 «Татар сүзе» II халыкара бәйгесе җиңүчеләренең гала-конерты 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Профсоюз – союз сильных» 12+
20.45 «Батырлар» 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Рамилә Сәхәбетдинова 12 +
22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
23.00 «МОЙ ДРУГ МИСТЕР ПЕРСИВАЛЬ» 6+
00.45 «Ком сәгате» 12+
01.35 «Татар халык җырлары» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Ватандашлар» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 Р.Бохараев. «Тимер борчак». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 6+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+. Әхтәм Зарипов турында телеочерк 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Нәсыйхәт» 6+
13.35 «Яңа татар җыры-2022» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе 6+
23.45 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 Р.Бохараев. «ТИМЕР БОРЧАК». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 6+

1 КАНАЛ

05.40, 06.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ») (S) 16+
06.00 Новости
07.45 «Играй, гармонь любимая!» 12+
08.25 «Часовой» (S) 12+
08.55 «Здоровье» 16+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 К 85-летию Николая Дроздова. «Шесть мангустов, семь кобр и один полускорпион» 12+
11.15 «Видели видео?» (0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» (0+
13.20 Юрий Колокольников, Антон Хабаров. «ВОСКРЕСЕНСКИЙ» (S) 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Воскресенский» (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.10 «Биологическое оружие лаборатории дьявола» 16+
19.15 «Большая игра» 16+
20.05 «Как развести Джонни Деппа» 16+
21.00 «Время»
22.35 Премьера. Екатерина Васильева, Сергей Газаров, Алексей Веселкин. «АНИМАТОР» (S) 12+
00.25 «Анна Ахматова. Вечное присутствие» 12+
01.55 «Наедине со всеми» 16+
03.25 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.30 Ольга Иванова, Сергей Загребнев, Татьяна Лютаева, Анатолий Котенёв, Святослав Астрамович. «ЛЮБОВЬ ДЛЯ БЕДНЫХ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00 Вести
11.25 «Доктор Мясников» 12+
12.30 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕРТВА» 16+
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова. 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Премьера. «Адмирал Колчак. Жизнь и смерть за Россию» 12+
03.20 «ЛЮБОВЬ ДЛЯ БЕДНЫХ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Арман Царукян против Матеуша Гамрота. Прямая трансляция из США.
08.00, 09.05, 15.05, 17.25, 19.30 Новости
08.05, 14.00, 15.10, 17.30, 22.05 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 «НУ, ПОГОДИ!». Мультфильм 0+
09.20 «НЕУДАЧНИКИ». Мультфильм 0+
09.30 «В ПОИСКАХ ПРИКЛЮЧЕНИЙ». 16+
11.30 Вольная борьба. Чемпионат России. Прямая трансляция из Кызыла
14.25 Мотоспорт. Кольцевые гонки. Чемпионат России по мотоингу. Супербайк. Прямая трансляция
15.40 Мотоспорт. Кольцевые гонки. Чемпионат России по моторингу. Суперспорт. Прямая трансляция
16.25, 21.35 Матч! Парад 16+
17.55 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Прямая трансляция из Москвы
19.35 Смешанные единоборства. UFC. Арман Царукян против Матеуша Гамрота. Трансляция из США 16+
23.00 «Karate Combat 2022. Эпизод 4» 16+
01.00 Мотоспорт. Кольцевые гонки. Чемпионат России по моторингу 0+
02.10 Вольная борьба. Чемпионат России. Трансляция из Кызыла 0+
03.30 Новости 0+
03.35 «Самые сильные» 12+
04.00 Бокс. Матч ТВ Кубок Победы. Трансляция из Москвы 0+
05.05 «Несвободное падение. Борис Александров» 12+

НТВ

05.00 Илья Шакунов, Татьяна Черкасова, Михаил Горевой. «ХОЛОДНОЕ БЛЮДО» 16+
06.35 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) (0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 «Своя игра» (S) (0+
15.00, 16.20 «Следствие вели...» (S) 16+
18.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Ты не поверишь!» (S) 16+
21.25 «Звезды сошлись» (S) 16+
22.55 «Секрет на миллион». «Юрий Кузнецов» (S) 16+
00.55 «ДЕНЬ ОТЧАЯНИЯ» 16+
02.35 «Таинственная Россия» 16+
03.20 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
07.10 «ПСИХОЛОГИЯ ЛЮБВИ» 16+
11.10 «ТОТ, КТО РЯДОМ» 16+
15.15 «УРОКИ ЖИЗНИ И ВОЖДЕНИЯ» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 99-я и 100-я серии 16+
22.45 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ» 16+
02.25 «ГОРДОСТЬ И ПРЕДУБЕЖДЕНИЕ». 4-я – 6-я серии 16+
04.55 «Лаборатория любви» 16+

ЗВЕЗДА

04.55 «ПОДКИДЫШ» 6+
06.05 «ФРОНТ ЗА ЛИНИЕЙ ФРОНТА» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
10.30 «Военная приемка» 12+
11.20 «Скрытые угрозы». «Альманах №84» 16+
12.10 «Секретные материалы». «Киевский Нюрнберг» 16+
13.00 «Код доступа». «Украинская идея. История болезни» 12+
13.50 «Сделано в СССР». 12+
14.05 «НЕСЛУЖЕБНОЕ ЗАДАНИЕ» 16+
16.05 «ВЗРЫВ НА РАССВЕТЕ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
20.00 «Легенды советского сыска» 16+
22.55 «ДЕЙСТВУЙ ПО ОБСТАНОВКЕ!» 12+
00.10 «ПОСЛЕДНИЙ ДЮЙМ» 12+
01.35 «ШКОЛЬНЫЙ ВАЛЬС» 12+
03.10 «ПОЛЕТ С КОСМОНАВТОМ» 12+
04.30 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 20 июнь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Гаяз Исхакый. «Татар кызы». Моноспектакль.
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 21 июнь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Лирик концерт

Чәршәмбе, 22 июнь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 «Утлы еллар кайтавазы». Концерт

Пәнҗешәмбе, 23 июнь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Александр Ключарев. «Тау әкияте» балетыннан фрагментлар. 1 нче өлеш

Җомга, 24 июнь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Александр Ключарев. «Тау әкияте» балетыннан фрагментлар. 2 нче өлеш

Шимбә, 25 июнь

8.10 «Керим әле урманнарга...»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине әйрәтәм»
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Мирсәй Әмир. «Тормыш җыры». Радиоспектакль. 1 нче өлеш

Якшәмбе, 26 июнь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35, 16.10 Мирсәй Әмир. «Тормыш җыры». Радиоспектакль. 2–3 нче өлешләр.

ЕРЫК АВЫЗ

Аукционда тутый кош сатыла. Бик кайнар бәхәсләрдән соң аны бер бай кеше сатып ала.

– Шәт, – ди ул, – бу кошыгыз сөйләшә беләдер?

– Ничек кенә әле! Бәя хакында сатулашу барганда, сезнең белән кем сүз көрәштерде дип беләсез?

***

Утырышлар залыннан чыккан судья, эчен тотып, тәгәри-тәгәри көлә.

– Нәрсә булды? – дип сорый аннан коллегасы.

– Үтергеч көлке анекдот ишеттем.

– Йә, миңа да сөйләп күрсәт, булмаса.

– Ярамый, ул анекдот өчен әле яңа гына берәүгә 15 ел чәпәдем.

***

Чукча, һава ничек булыр икән дип, ауга чыгар алдыннан шаман янына киңәшкә бара. Тегесе учак янында сикергәләп алгач, яхшы һава вәгъдә итә, аннан төгәл мәгълүмат алыр өчен, синоптик янына килә.

Синоптик тәрәзәгә күз сала да һичбер икеләнүсез җавап бирә:

– Һава әйбәт булачак!

– Каян белдең?

– Әнә бит, чукча ауга китеп бара!

МОРТАЗАНЫҢ ЯШЕЛ ДӘВАСЫ

Баулы районы Мортаза авылының данын читләргә ит тә, сөт тә түгел, бодай үрентесе танытκан. Эшмәкәр Әхмәтовлар үстергән яшел дәвадан күпләр сәламәтлегенә сихәт табарга өлгергән инде. Бодайның хикмәте нәрсәдә? Агроном ир белән табиб хатын гаиләсе бүген ниләр майтара? Мортаза авылы сукмакларын без дә урап кайттык.

Ишекне ачасың, ә анда – лаборатория. Гадәттә, авыл өчен табигый булмаган күренеш бу. Без теплицаларда мул уңыш үстерүчеләрне күреп ияләнгән анысы. Монысы никтер гаҗәп кебек тоелды. Салкын бер бинаның киштәләрендә ямь-яшел бодай үрентеләре үсеп утыра, очларына көмешсыман чыклар эленгән. Туфракта түгел, суда үсәләр. Бер караганда, моңа аптырарга да кирәкми. Тәрәзә төбендә дә үстереп була лабаса. Әмма барыннан да бигрәк яшь эшмәкәрләрнең авыл тормышына яңа юнәлеш алып килүе сокландырды. Дөрес, беренче вакытта аларга шикләнеп караучылар да аз булмаган. Кеше көлдереп йөриләр шунда, дигән сүзләр дә килеп ирешкәләгән. Тик бодай үрентеләреннән ясалган продукциягә ихтыяҗ булуын күргәч, киресенчә, соклана башлаганнар. Кемдер үзенең кечкенә генә кишәрлегендә үстергән сарымсак, суганны, алма, җиләген сата алмый җәфалана. Монда исә тәме әллә ни искитәрлек булмаган бодай үрентесе сутын әллә кайлардан соратып алалар. Вәт кызык ичмаса. Киштәләрдәге бодай үрентеләренә карагач, беренче чиратта, әнә шундый уйлар сызылып үтте.

– Бу үрентеләрне тәрәзә төбендә теләсә кем үстерә аладыр? – дип сорыйм Алинәдән.

– Без дә башта әшне шулай башлаган идек. Әмма шартлар, таләпләр дигән нәрсә бар. Җылы тәрәзә төбе белән суык бүлмә бер түгел. Температураны да сакларга кирәк. Монысы – бер. Икенчедән, чимал мәсьәләсе. Басуда бодайны нинди ашламалар кулланып үстергәннәрен белмибез бит. Үз җиребездә ирем Айрат бодайны меңләгән гектарда бернинди химиясез үстерә. Шуңа күрә башкаларга да экологик яктан чиста продукция дип курыкмыйча сатабыз. Өченчедән, белми үстерсәң, ул агуга да әйләнергә мөмкин. Үрентеләрне 11–12 сантиметрга җиткәнче генә үстерәбез. Моның өчен 12 көн кирәк. Әнә чыкларны күрәсезме, бу – тереклек бар дигән сүз, – ди Алинә Әхмәтова.

Кешегә көн саен 50 грамм, ягъни өч чәй кашыгы үренте җитә. Моннан салат ясыйсыңмы, төнәтеп эчәсеңме, икмәк пешерәсеңме... Анысы – синең эшең. Алинә безне дә үлән чәе, бодай үрентесе белән сыйлады. Сыгынтыдан яңа чапкан печән исе аңкый. Авыл кешеләре дә бодай үрентесен кулланамы? Бу сорауга җавап биргәндә дә, Алинә Мортаза халкына бер дә тел-теш тидермәде. Киресенчә, мактап кына куйды. Баулыдан килеп эшләгән эшмәкәрләргә дә авыл бик якты урынга әйләнгән.

– Авыл кешеләре башта аңлап җиткермәде. Хәзер, киресенчә, Мортазаны чит төбәкләргә танытасыз, дип безнең белән горурланалар. Бу товар авылга түгел, күбрәк шәһәр халкына кирәк. Авыл кешеләре болай да сәламәт, – ди ике дипломлы белгеч.

Дөрестән дә, үз товарын күкләргә чөя, кыстап алдырта торганнардан түгел Алинә. Берәү, файдасын күреп, икенчегә әйтә. Сатып алучылар шулай табыла. Бүген алар җитештергән продукциядән илнең 40 төбәгендә файдаланалар. Депутатлар, артистлар, табиблар да әллә кайдагы Мортазага шалтырата. Продукцияне бер шәһәрдән икенчесенә суыткычлар белән җиһазландырылган машиналар тарата. Сату алымнарын өйрәнергә Мортазага хәтта Мәскәүдән кадәр киләләр икән. Алинә исә, эшебезнең бернинди сере дә юк, ди.

Халыкның дару ашыйсы килми. Менә шуны аңлаганнар үз итә дә инде әлеге продукцияне. Бодай үрентесе сутында исә кальций, калий, магний, тимер, цинк, натрий, фосфор, селен, клетчатка – барлыгы 92 төрле витамин һәм микроэлементлар бар икән. Организмга хәл кертә, иммунитетны күтәрә, ябыгырга ярдәм итә. Үз башыннан кичкәч, Алинә сәламәтлекнең никадәр кадерле икәнен яхшы белә.

– Организмны тыңлый белергә кирәк. Иртән торганда, сулпәнлек сизелә икән, димәк, нәрсәгәдер кытлык бар, – ди ул. – Өченче баламны тапкач, бик авыр булды. Анализлар начар, табибларның файдасы тими. Шул вакытта дару да эчәсе килмәде. Аптырагач, халык медицинасы белән кызыксына башладым. Интернетта бодай үрентесе турында язма күзгә ташланды. Моны миңа Аллаһ күрсәткәндер. Без – табигать балалары. Бодайның файда китерәчәгенә ышандым. Аны тәрәзә төбендә үстереп, эчә башладым. Аякка бастым, яшәү мәгънәсе артты. Менә шуннан соң белгәннәремне башкалар белән уртаклашу теләге туды. Яшәү көче күпкә кадерлерәк.

Сәрия МИФТАХОВА

САЛКЫН, ӘММА УҢЫШЛЫ ҖӘЙ

Быел яхшы, ә урыны-урыны белән хәтта рекордлы уңыш җыеп алу өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Журналистлар белән очрашуда белгечләр әнә шулай дип белдерде. КФУ профессоры Юрий Переведенцев әйтүенчә, җәй уртача температура 15 градустан артып киткәч башлана.

– Узган ел Казанда җәй 9 майда башланган иде, быел ул 20 көнгә соңарып – 30 майда гына килде. Җылы вакыт исә якынча 20 сентябрьдә, уртача температура 10 градуска төшкәч тәмамлана. Казанда җәй уртача дүрт ай дәвам итә, – диде Юрий Переведенцев.

Белгеч әйтүенчә, температура характеристикалары буенча һава торышы җәйге чорда тотрыклырак. Әгәр 1976 һәм 2021 еллар аралыгын алсак, Россиядә җәйге температура арта, дип белдерде ул.

– Соңгы елларда безнең илләрдә климат җылынуга таба бара. Идел буе федераль округында көньяк-көнчыгыш районнарда явым-төшем аз була, ә бездә язгы һәм кышкы чорда алар арта, җәен кими. Бу авыл хуҗалыгы өчен яхшы түгел, – диде галим.

Ә менә быелгы язның яңгырлы килүе, аннан соң акрын гына җылытып җибәрүе язгы культуралар тишелеп, әйбәт итеп үссен өчен яхшы шартлар тудырды, дип саный галим Марсель Таһиров.

– Бу ел үзенчәлекле, – ди ул. – Без мондый яңгырларны иртә язда һәрвакыт көттек. Быел явым-төшем күп булды, кайбер урыннарда хәтта артыграк та. Ләкин мин май һәм июньдә яуган яңгырлар барыбер артык булмый, дип саныйм. Алар мул уңыш алыр өчен әйбәт.

Шулай да әлегә уңышның күпме булачагын алдан фаразлау кыенрак, чөнки алга таба күп факторлар йогынты ясый.

– Уҗым культуралары да, язгылар да, кузаклылар да, терлек азыгы үскән кырлар да бик матур, – диде ул. – Һава торышы бүгенге кебек җылы булса һәм ул сакланса, табигать үзенекен эшләячәк. Быел үсемлекләр 15 көнгә соңарып өлгерсә дә, яхшы, ә кайбер урыннарда хәтта рекордлы уңыш җыеп алу өчен барлык мөмкинлекләр дә бар.

Галим сүзләренә караганда, артык эссе дә кайбер культуралар өчен уңай түгел. Мәсәлән, бәрәңге өлгерер өчен 15–17 градус җылылык яхшы булса, бөртеклеләр өчен 25 градус кулай.

КФУның Метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев сүзләренчә, майда уртача температура 3,5 градуска түбәнрәк булган. Быел 5,5 ай эчендә барлыгы 330 мл явым-төшем яуган.

– Норма буенча 160 мм булырга тиеш. 18 майда тәүлегенә 28 мм явым-төшем яуды, бу – абсолют рекорд булмаса да, сирәк күзәтелә торган күренеш. Мондый хәл 1983 елдан бирле булмады, – диде ул.

Аның каравы, салкын һава булгач, шәһәр халкын черкиләр тешләп җәфаламаган. Мондый температура коену сезонына да йогынты ясамый калмады, билгеле.

– Коену өчен 20 һәм аннан югарырак температура яхшы дип санала. Хәзерге вакытта Казан тирәсендәге Куйбышев сусаклагычындагы суның җылылыгы 15 градусны тәшкил итә. Башка елларда бу вакытта 17,5 градус була торган иде. Ә тиешле норманы Татарстан сулыклары 21 июньгә генә җыя. Быел исә су июльнең икенче яртысында гына җылынып бетәчәк, – дип аңлаттылар.

Хәер, галимнәр быел июль дә артык эссе булмаячак дип фаразлый. Августта да артык җылы һава торышына өметләнмәскә киңәш иттеләр.

Зәһрә САДЫЙКОВА

ӘНИЛӘР НИЧЕК ТҮЗДЕ ИКӘН?

Үзегез дә сизәсездер, Җиңү бәйрәмен без ниндидер бер күтәренке рух белән каршы алсак, сугыш башланган көнне сагаеп көтәбез. Бу аңлашыла да, 1941нең 22 июне – илебездә кайгы җиле кагылган капкалар ачылган көн. Берничә көннән һәр кеше, хәтер өермәсен уйнатып, шул капкаларны кабат ачарга мәҗбүр.

Бөек Ватан сугышы елларының эзләрен барлаган Тәэминә ханым БИКТИМИРОВА белән хатирәләр яңартабыз.

:: Тәэминә ханым, сез үзегез дә – сугыш чоры баласы. Беренче чиратта ниләр искә төшә?

– Ничек яшәдек икән дә ничек исән калдык икән, дип уйлыйм. Әниләр ничек түзде икән? Күз алдына шул чорда ашаган ризыклар килә: кузгалак, кычыткан, ат кузгалагы, черек бәрәңге... Гектарлап печән чапкан әниләргә, кич кайтканда, икешәр кашык он бирәләр иде. Он булгәнне карарга амбар алдына балалар җыела. Без дә шунда. Кайтып җиткәч тә, онны ашка туглап җибәрәбез. Әнә шундый зур хыяллар белән әнинең ике ягыннан тын гына атлыйбыз...

:: Тарихтан белгәнебезчә, сугышның 26 нчы көнендә илдә икмәк карточкасы бирелә башлаган. Шәһәр халкы шуның ярдәмендә нормада күрсәтелгән өлешен ала алган. Авыл кешеләренә ул бирелмәгән. Ни өчен?

– Икмәкнең бөтен кешегә дә җитәрлек булмаганын акылым белән генә аңлый алам. Фашистлар басып алган урыннарда сөрү җирләренең 47 проценты гына калган, йөз меңнәрчә колхоз, совхоз, МТСлар җимерелгән. Болар өстенә 1943 елда булган корылык үстерелгән игеннең яртысын диярлек көйдереп бетергән. Әнинең өзгәләнгәне бүгенгедәй хәтеремдә. Безне кочаклап: «Һай, балалар, күкрәгемә терәп, ипи кисеп ашаткан көннәрем булыр микән сезгә?» – дип елый иде ул. Фронт өчен көн-төн эшләп, үзләренә бер грамм ашлык ала алмаган бәхетсез аналар балаларына нәрсә ашатырга тиеш булдылар икән? Бу сорау да җавапсыз кала. Ул чорда закон дигәннәре бик рәхимсез иде бит. Бер уч бодай өчен башлары зинданда черегән кешеләр күп булды. Бу, аңлашыла ки, беренче чиратта бер тәгам ризыгы булмаган авыл кешеләренә кагылды.

:: Тылдагы хатын-кызлар башына төшкән тагын бер бәла – урман кисү. Анда күргән газаплар турында авылдашлардан минем үземә дә күп ишетергә туры килгән иде.

– Еллар үткәч, Бөек Ватан сугышы чорында хатын-кызларның урман кискәндәге фидакарь хезмәтләрен, башларына төшкән ачы газапларын тасвирлаган бик күп тарихи документларга юлыктым мин. Шуларның берсендә болай дип әйтелә: «Горький, Киров, Казан, Ярославль, Калинин, Октябрь, Пенза һәм башка тимер юлларны кирәк кадәр утын һәм агач материаллары белән тәэмин итәр өчен, ТАССР 3590 кеше һәм 1670 баш ат җибәрергә тиеш. Бу эшкә күбрәк хатын-кызлар һәм фронтка яраклы булмаган ир-атлар тартылсын». Датасы – 1942 елның 12 феврале. Татарстан бу боерыкка буйсынмый кала алмый, әлбәттә. Бу җәһәттән миндә Әтнә районы Күәм авылыннан Котдус Мостафин истәлекләре саклана. «...Билдән кар ерып, хатын-кыз урман кисә. Ул бичараларга, үз нормасын үтәү өстенә, киселгән агачны төннәрен вагоннарга төяттерәләр. Һәр авылга – бер вагон. Ябык вагоннарга төяү – үзе бер газап. Шул авыр хезмәттә норма тутырсаң, 600 грамм ипи бирәләр. Кайвакыт ашханәгә дә кертеп ашаталар...» Урман кисүдә эшләгән хатыннарны да күп тыңлаганым булды. Ашханә дигәннәре бар җирдә дә булмаган шул. «И ул Суслонгер урманнары, – дип искә ала иде авылдашым Һаҗәр апа. – Өйдән алып килгән бәрәңгене санап, һәр көн өчен бүлеп куя торган идек. Туйганчы ашаулар кайда инде ул?! Имән чикләвеге, өшегән миләш җыя идек. Сафи Гайшәсе: «Бәгырьләрем, әйдәгез, шул столовый дигәннәренең исен генә иснәп торыйк», – дип тилмерә иде. Шулай да норманы тутыра идек».

:: Урман кисәргә киткән кызларның тагын бер проблемасы булган бит әле. Аны хатын-кызлар гына кисмәгән. Алар янында фронтка яше җитмәгән үсмерләр дә, сугышка яраксыз ирләр дә эшләгән. Хәтта җинаятьчеләр белән дә бергә эшләргә туры килгән.

– Миндә Казан медицина көллиятенең татар теле укытучысы Мөсәмирә ханым Сәлиева истәлекләре саклана. «Сугыш вакытында Кира урманнарын күп кискән минем авылдашларым. Бер елны уголовниклар белән эшләргә туры килгән. Аларның кем икәнлекләрен белгәч, кызлар, йокларга ятканда, бер-берсенә бау бәйләп ята торган булганнар. Шалаш авызына комган, буш банкалар тезеп куялар икән дә, ул-бу сизсәләр, барысы да сөрән салып, урман хуҗаларын аякка бастыралар икән», – дип сөйләгән иде ул миңа. Гомумән, татар кызлары эшчәнлекләре, сафлыклары белән аерылып торганнар. Тик халкымның иң гүзәл, иң матур сыйфаты – эш сөючәнлеге үзенә үк дошман булып кайткан. Бу – татар халкының фаҗигасе, дисәм дә, ялгыш булмас. Кайда авыр хезмәт – шунда татар, шунда татар кызлары.

:: Иң авыр эш дигәннән, аларның тагын берсе – торф чыгарудыр, мөгаен?

– Тылда эшче көчләр җитешмәүдән интеккән авыр көннәрдә Татарстан үзенең меңнәрчә хатын-кызларын Мәскәү янындагы Шатура кырларына торф чыгарырга җибәрә. Торф Мәскәү шәһәрендәге һәм өлкәсендәге сугыш кораллары ясый торган заводларны, электр станцияләрен эшләтүгә, торак йортларны җылытуга китә. Әйтергә кирәк, татар кызлары торф чыгарган урман-кырлар географиясе бик киң: Мәскәү, Вологдадан алып Себер киңлекләренә кадәр җәелә. Бу хакта фәнни хезмәтләр басылып, азрак әдәби әсәрләрдә телгә алынса да, шунысы гаҗәп: нәкъ менә татар кызларының язмышлары, эшләгән эшләре ни өчендер бер җирдә дә яктыртылмый. Милләтебез өчен бик кызганыч факт бу.

:: Тарихтан белгәнебезчә, торф чыгаруда эшләгән хатын-кызлар өчен татар һәм башкорт телләрендә «Правда» исемле махсус газета да чыгып килә. Безнең өчен шунысы да мөһим: аны күп еллар редакциябездә эшләгән күренекле журналист Мәрьям апа Дибаева әзерли.

– Мәрьям апа Мәскәү өлкәсендәге торфчы кызлар янына 1944 елда, ире Самат Дибаевның фронтта һәлак булган хәбәрен алып, бәләкәй кызчыгын энисе тәрбиясендә калдырып китә. Берүзе материаллар җыеп, мәкаләләр яза, Мәскәүгә килеп, типографиягә тапшыра һәм, бөтен тиражны күтәреп кайтып, баракларда, палаткаларда өләшеп йөри.

:: Безнең кызлар җирле халыкны чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтеп кайтканнар, дип тә ишеткәнем бар иде.

– Үзәккә үткән нәрсәләр тагын да була әле. Шуларның берсе – юынырга урын булмау. Бу хакта Түбән Көек авылыннан Әминә апа Хисмәтова болай дип сөйләгән иде: «Калинин, Смоленск өлкәләрендәге авылларда мунча, бәдрәф юклыгына исебез китә иде. Без яшәгән йортның хуҗасы мичкә яга да, кызгач, күмерен тартып, төбенә салам җәя. Чишенеп, шунда кереп китә, мукәләп чыгып, бер чуен су белән тышка чыгып коена. Әбинең мичене без дә кергәләдек. Соңгы баруыбызда бер вагоннан мунча ясадык. Бер егет мич чыгара белә икән. Аны каравга бөтен авыл халкы җыелды. Шаккаттылар. Җитәкчеләр дә, авыл халкы да юынырга өйрәнде. Идән юу гадәте дә юк иде. Хуҗа хатын берәр җиргә китсә, идәнне су белән җебетеп, көрәк белән кырып чыгабыз да кайнар су белән шытырдатып юабыз. Идән сап-сары була. Хуҗа хатын хәйран кала иде».

:: Бер караганда, татар кызларын ил буйлап йөртеп тилмертүләре аңлашылып та бетми кебек. Сугыш башлануга, үзебездә дә тормыш бик катлаулана бит.

– Татарстан – иң якын тыл, фронт ихтыяҗларының күбесе монда үтәлә. Өстәвенә Казан, Яшел Үзән, Чистай һәм башка шәһәрләргә Ленинград, Мәскәү, Одесса, Киев, Херсон кебек шәһәрләрнең 30дан артык предприятиесе күченеп килә. Аларны да тизрәк урнаштырасы, эшче көчләр белән тулыландырып, фронт өчен хәрби продукция чыгаруны җайга саласы бар. Илгә төшкән афәтнең беренче көннәреннән үк фронтка киткән ирләр урынына, моңарчы балаларын үстереп, өй тирәсендә йөргән хатыннар һәм яшүсмерләр килә. 1942 елның беренче яртысында ук Казанда завод-фабрикалар өчен 18 мең яшүсмер эшкә тартыла. Бер үк вакытта хәрби заводларга кадрлар әзерләү өчен һөнәр мәктәпләре ачыла. 1943 елның 1 июленә ФЗӨләрне 35 мең яшүсмер тәмамлап, завод-фабрикаларда, төзелештә һәм транспортта эшли башлый. Күбесе, өйләренә кайткач, вакытында килеп җитә алмыйча, төрмәләргә утыртыла. Бу җәһәттән Татар Алаты кызы Вафина Мәрзия апа сөйләгәннәр бик тә күңелгә уелып калган. Аны 13 (!) яшьтә ФЗӨгә җибәрәләр. Ике ел буе Юдинода рельслар чистарта. «Юан-юан агачларны, шпалларны күтәреп ташый идек. Иңбашларыбыз суелып каный иде. Көннәрдән беркөнне, ачлыкка чыдый алмыйча, кайтып килергә рөхсәт сорадым. Җибәрделәр. Әмма буран чыгу сәбәпле, бер көнгә соңга калып килдем», – дип сөйләгән иде ул. Шуның өчен аны төрмәгә утырталар...

:: Тәэминә ханым, сез тылда фидакарь хезмәт куйган хатын-кызлар турында шактый гына мәгълүмат җыйгансыз, иң мөһиме, алар белән аралашырга өлгергәнсез. Бүген сезне нәрсә борчый?

– Сөргенгә тиң шушы хезмәтнең беркайда да күренмәве, искә алынмавы, билгеләнеп үтелмәве йөрәкне әрнетә. Сугышта катнашучыларга, аларның толларына барыбер азмы-күпме кадер-хөрмәт күрсәтелде. Ә тыл хезмәткәрләре берничек тә искә алынмады. Ул чор хатын-кызларының тиңдәшсез батырлыгы турында сөйләгән документлар архивта саклана әле. Аларның исемнәрен барлау, фидакарь хезмәтләре турында бәян итүне тарихчыларыбызның изге бурычыдыр дип саныйм.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

▸ Бөек Ватан сугышы чорында ил азатлыгын яклап көрәшкә күтәрелгән гүзәл затларыбызның саны **850** меңгә җитә. Хатын-кызларның сугыш хәрәкәтләрендә турыдан-туры бу дәрәҗәдә күпләп катнашуын тарих моңа кадәр белми.
▸ Бу чорда республикабызда **3500** шәфкать туташы, **3** меңнән артык санитар-дружиначы әзерләнә.
▸ Сугыш елларында Татарстан сәнәгать предприятиеләренә өстәмә көч булып, **41** мең хатын-кыз эшкә килә.

99 ЯШЬЛЕК ФӘРДИЯ ГАТИНА:

«ЮБИЛЕЕМДА ТРАКТОРГА УТЫРАСЫМ КИЛӘ»

Спас районының Көек авылында яшәүче Фәрдия апага авырлыкларны күп күрергә туры килә. Җиде яшеннән, әтисенә ияреп, колхозда эшли башлый. Сугыш башланганда, унсигезе тулган гына була. Кулында трактор йөртү таныклыгы булган кызга ирләр эше кала. 15 ел буе трактор йөртә ул. Әле дә бер хыял белән яши: 100 яше тулган көнне яңадан тракторга утырасы килә.

Без шалтыраткач, телефонны Фәрдия апа үзе алды. 99 яшендә искиткеч зиһене белән генә түгел, бөтен дөнья яңалыклары белән таныш булуы да шаккатырды.

– Кызым, минем язмышымны тыңлар өчен бер көн җитмәс. Язам дисәң, китап кирәк, – диде ул. – Хәзер бик рәхәт тормышта яшимен. Элеккеге сагыш-хәсрәтләрне уйлап утырырга тырышмыйм. Күңелемне төшергәнем юк. Ике балам кайтып хәлемне белеп тора. Авылда сеңлем яши, аның кызы килеп булыша. Әле үзем дә зарлана алмыйм. Бакчама бәрәңге утырттым. Хәрәкәт тә кирәк бит.

Тракторны чарасызлыктан йөртә башлый ул. Ул чакта авылда ирләр юк, булганнары да йә кулсыз, йә аяксыз. Ә эшләргә кирәк. Фәрдия апа шуңа тәвәккәлли дә инде. Трактор маркасын әле дә хәтерли, «ЧТЗ» иде, дип аның турында да сөйләп бирде. Ул чакта тракторны сүтеп җыярга да туры килә аңа. Ир йөрәкле хатын-кыз була ул. Булачак ире белән дә басуда таныша. Харис абый аннан 4 яшькә кечерәк була.

– Миңа дигән егетләр үлеп бетте бит. Исән калганнарын матур кызлар эләктерде. Начар яшәмәдек без Харис абыең белән. Бер-беребезне ярты сүздән аңладык. Өч бала үстердек. Беребез – көндезге сменада, икенчебез төнлә эшләде. Ике ел бергә яшәгәч, балабыз туды. Шул кечкенә баланы калдырып та эшләп йөрдем инде. Әле икенчесен тапкач, комбайн да йөрттем, – дип искә ала ул.

Харис абый 68 яшендә яман чирдән үлеп китә. Хәсрәт ялгыз гына йөрми. 49 яшен тутырган улы Вилданда да мәкерле авыру табыла. Ничек кенә тырышсалар да, аны коткара алмыйлар. Шул улының малае Ринатны да югалта алар.

– Хәсрәтемне җиңәргә догаларым булышты. Намаз укып, җаныма тынычлык таптым. Аллаһы Тәгалә үзенә сыенганнарны ташламый ул, балам, – ди Фәрдия апа.

Без сөйләшкән арада, Фәрдия апага кунак килде. Сеңлесенең кызы Нурзилә апа икән. Фәрдия апа телефонны аңа бирде.

– Без апабызга бик сокланабыз. Күзләр генә тимәсен инде, дибез. Аллага шөкер, бер зарланмый ул. Мәет тә юып йөри әле. Авылда гына түгел, тирә-якта яшәүчеләр дә хөрмәт итә үзен. Ашларга килеп алып китәләр, – ди Нурзилә апа. – Олы яшьтә булса да, биш вакыт намазын калдырмый, ничә еллар инде айлар буе ураза тота. Бөтенебезгә үрнәк ул. Дөрес уйлавы, дөрес яшәве белән шушы яшькә җитте дә инде. Хәлен белеп шалтыратсаң да, зарланмый. Кайчак кан басымы күтәрелеп китсә дә, безгә сиздерми.

Нурзилә ападан Фәрдия апаның гомер озынлыгының серен сораштык. Баксаң, бар да күңел чисталыгыннан тора икән. Фәрдия апа сайланып ашамый, диеталар да тотмый. Үт куыгын алдырганына да күп еллар инде. Әле менә кичке унда тамагы ачып киткәч, аш пешереп ашаган. Йокысыннан да зарланмый. Ничек тә ял итеп алырга тырыша. Кояш чыкканчы йоклап ятканы юк икән. Иртәсен зарядкадан башлый. Бакчасындагы яшелчәсенә су сибә. Хәтере яхшы, колагы ишетә, күзе күрә, аяклары йөри. Фәрдия апа язмышына бик рәхмәтле.

– Сынады, күтәрә алырлык сынаулар бирде. Дөньяны шулкадәр яратып яшимен. Балаларым кайтып тора, туганнарым янәшәмдә. Әле менә сеңлемнең малае тракторда утыртып йөртәм, дип тора. Янында йөртмәкче. Әле миндә көч һәм куәт бар. Рульгә үзем утырачакмын, – ди Фәрдия апа. – Гомер буе бер теләк белән яшим. Яшьлек елларына кайта алмасам да, тракторга утырып, урам әйләнеп кайтасы иде!

ХЫЯЛЫЙ ЕГЕТ

Апаста яшәүче Илнур Азизовның тумыштан аяклары тыңламый. Кечкенәдән күңелендә бер хыял яши аның: унсигезе тулганчы, ул барыбер йөреп китәчәк. Тик бу хыял чынга ашмый кала. Илнур исә бирешми. Тормышта үз урынын табып яшәргә тырыша. Үзен ничек бар шулай кабул итеп, яңа хыяллар белән яна. Алдына максат куя: фатирлы, гаиләле булырга!

– Мин гел хыял белән яшәдем. Йөреп китәсемә ышанычым зур иде. Аякка басар өчен ничек кенә дәваланып карамадым. Бармаган табибым калмады. Йөри торгач, язмышым белән килештем. Аякларым йөрмәсә дә, яшим бит әле, дип сөендем. Ә яшәү шулкадәр рәхәт. Авыр чакларымда да, шатлыгымда да әнием янәшә булды. Аңа чиксез рәхмәтлемен. Ә бит кайчандыр аңа, бу баланы ятимнәр йортына тапшыр, дип тә әйтәләр, – дип искә ала Илнур.

Тормышны яратуы әллә кайдан күренеп тора аның. Очрашканда исәнләшмичә китми. Әллә каян таный. Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр арасында узучы бәйгеләрдә еш очратырга туры килә үзен. Соңгысында янәшәсендә чибәр кыз да бар иде. Баксаң, Илнур гаилә корып җибәргән. Тормыштагы зур теләге кабул булган аның. «Һәр иртә кайнар коймак кына ашыйм хәзер», – дип шаярта.

– Фәнзия белән Яшел Үзәндә шифаханәдә дәваланганда таныштык. Баштарак гел телефоннан сөйләшеп тордык. Әмма мин аның янәшәмдә булуын теләдем. Шуңа да эшне озакка сузмадым, тоттым да тәкъдим ясадым. Ул үзе дә каршы килмәде. Арчадан 218 чакрым ераклыктагы Апаска килен булып төште, – ди Илнур.

Кыз сорарга барганда Илнур бик борчыла. Коляскада утыручы кияүне кире бормаслармы? Юл буе уенда шул гына була. «Әгәр Фәнзия кире уйласа, нишләрмен?» – ди. Шөкер, кызның гаиләсе җылы каршы ала. «Фәнзиянең дә аяклары авырта. Шунысы сөендерә: ул йөри ала! Инде хәзер бер-беребезгә бик ияләндек. Язмышыма хатыным өчен көн дә рәхмәт укыйм», – ди Илнур.

Фәнзиясе дә ирен яратуын яшерми.

– Миңа Илнур янәшәсендә бик рәхәт. Ул бик ярдәмчел. Без аның белән бөтен эшләрне бергә эшлибез. Тормышта төрле чаклар була, әмма тиз аңлашабыз. Ирем – миңа үрнәк. Көчле рухлы. Мине дә шундый булырга өйрәтә, – ди Фәнзия.

Фәнзияле булгач, тормыш бөтенләй үзгәрә. Илнур районның боз сараена эшкә урнаша. Эшен яратып башкара. Машина йөртә башлаганына да байтактан икән инде. Спорт белән дә дус. Кул көрәшендә җиңүләр яулый. Шигырьләр дә иҗат итә. Алар күбрәк төнлә языла икән. Төрле иҗади бәйгеләрдә дә катнаша, әллә ничә тапкыр беренче урын алган.

– Мин авыру дип, беркайчан да күңелне төшермәскә кирәк. Шөкер, мин гел яхшы уйлар белән яшим. Булдыра алмам инде, барып чыкмас, дип утырганым юк. Кайчак үземнең йөри алмаганымны да онытып җибәрәм. Дусларым, туганнарым күп. Алар мине гел үз итә. Шуңа да мин үземне алар кебек тоям. Арба гына йөри алмаганны искә төшерә, – ди ул. – Тормышта төрле хәлләр була. Кайчак күңел төшенкелегенә бирелеп, таза-сау кешеләр кирәкмәгән адымга бара. Хаталар кылалар. Ә бит гомер бер генә бирелә. Шуңа да аның кадерен белеп, башкаларга үрнәк булып яшәргә кирәк.

Бу көннәрдә Илнур күзенә операция ясаткан. Уң күзе начар күрә башлаган булган. Әйтүенчә, операциясе уңышлы чыккан. Зарлана торганнардан түгел ул. Киресенчә, дөньяны яратып, аны тагын да матуррак күреп яшисе килә аның.

Игълан тактасы

КЕМДӘ БАР?

▸ 8 яшьлек малай өчен җәйге киемнәр кирәк иде.

Ләйсән. Казан

* * *

▸ Ир-атлар өчен 42–43 үлчәмле аяк киемнәре, 50–52 үлчәмле өс киемнәре кирәк.

Гөлзада. Казан

КЕМГӘ КИРӘК?

▸ 10–12 яшьлек кыз бала өчен җәйге күлмәкләр, туфлиләр бар.

Лариса Иванова. Казан

* * *

▸ 11–12 яшьлек малай өчен спорт киемнәре бар.

Миләүшә. Чаллы

* * *

▸ 40–42 үлчәмле киемнәрем бик күп. Кайбер җәйге күлмәкләр бер дә киелмәгән. Шуларны бик тә мохтаҗ кешегә тапшырыр идем.

Гөлгенә. Чаллы

РӘХМӘТ ИШЕТҮ РӘХӘТ

▸ Моннан бер ел элек «Ватаным Татарстан» газетасы аша ярдәм сораган идем. Язма басылып чыкканнан соң, балаларыма киемнәр, күп итеп ризык алып килделәр. Мәрхәмәтле кешеләр әле дә миңа ярдәм итеп тора. Газета укучылар ярдәме белән эшкә урнаштым, коммуналь хезмәтләр өчен җыелган бурычымнан котылдым. Мин моның өчен редакция коллективына чиксез рәхмәтемне җиткерәм.

Зөһрә. Яшел Үзән

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА: «ШАГЫЙРЬ БУЛУ – ХОДАЙ БҮЛӘГЕ»

Татар шигърияте ни хәлдә? Ни өчен кайбер жанрлар сүрелә, кайсылары калкып чыга? Яшьләр иҗатын нинди сыйфат үзгә итә? Болар һәм башка мәсьәләләр хакында шагыйрә Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА белән сөйләштек. Бу көннәрдә юбилеен билгеләп үткән шәхеснең гыйбрәтле язмышы да читтә калмады.

«Татар-информ»

:: Шагыйрь булу ул – ...

– Ходай бүләге. Аннан качып, аңа күз йомып булмый. Дөрес, шагыйрь булу тормышта комачау да итә. Шуңа күрә кайчандыр ир хатыны булып, балаларымны тәрбияләп кенә яшәргә теләгән идем. Фаил белән шулай ниятләгән идек тә. Балаларны үзебез җитештергән ризыклар белән тәрбияләп: кәҗә алып, тавык-чебеш үрчетеп, өй янында бакча тотып тормыш итәргә хыялланган идек. Мин бит – авыл баласы, эштән курка торган кеше түгел. Җирне яратам. Быел язны өзелеп көттем, ул соңарып кына, ялындырып кына килде. Дачага килсәм, саф һавада акрын гына йөреп, тәнем дә, җаным да сихәтләнер төсле иде.

:: Ир хатыны булып яшәргә риза идем, дисез. Сәләт шулай йомылып калыр идеме икән?

– Булган сәләт йомылмый инде ул. Барыбер язылыр иде. Әмма гаиләм беренче урында булыр иде. Шөкер, командировкаларда еш йөрсәм дә, иҗатка бирелеп, вакыты белән көннәр буе эш өстәле яныннан кузгала алмый утырсам да, балаларым һәм оныкларым тәрбияле булды.

:: Иҗатыгызда беренче урында тарихи шәхесләр тора. Тукайга багышланган поэма шагыйрьнең шигъри юлларына җавап рәвешендә язылган. «Каюм коесы» поэмасын укып, галим Каюм Насыйри дөньясы белән танышабыз. Фазыл Туйкин биографиясен, иҗатын ачыклау... Саный китсәң, сез эшләгән эшләр байтак. Әмма «Без – Тукайлы халык», – дип язган шагыйрәне танырдылармы соң?

– Җавабын үзең дә беләсең бит инде. Әмма дәүләт бүләкләренә лаек дип тапмасалар да, халык таныды, шунысы сөендерә. Иҗатыңның канатлы сүзләргә әйләнүе дә күңелле. Кая гына барсам да, мәктәп булсынмы ул, клубмы, башка урынмы – күбесендә «Без – Тукайлы халык» шигаренә тап буласың. Бик күп җирләрдә аның кем сүзе икәнен дә белмиләр. Бик аз җирләрдә генә аска исем-фамилиямне теркәп куялар. Хәер, «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән юлларның Шәүкәт Галиев шигыреннән алынганын да белүчеләр бик аз. Озын сүзнең кыскасы, поэмам юлларының халык күңеленә кереп калуына мин бик риза. Әмма шундый иҗатны да күрмәмешкә салышулары йөрәккә авыр.

:: «Поэма белән танылып булмый, аны халык укымый» дигән фикер дә бар бит әле.

– Ул фикерне үземә дә әйткәннәре бар. Әйтик, Рәдиф Гаташның иң сөймәгән жанры – поэма. «Казан утлары»нда эшләгән дәвердә ул поэманы бастыру ягында түгеллеген ачыктан-ачык әйтә иде. Үзе дә поэма язмады. Безнең буында күләмле шигъри әсәр иҗат итүчеләр әле бар иде, бездән соң исә бөтенләй бик аз. Ни өчен желекне суыра, эзләнергә мәҗбүр итә торган жанрны сайладыммы? Чөнки элек-электән сюжетлы әсәрләр яратам. Ул бит бер укудан күңелдә кала. Шул ук смотр-конкурсларны гына алыйк. Мәктәп баласы да, өлкәннәр дә чыгыш ясар өчен сюжетлы әсәрне сайлый. «Рәнҗү» циклын, мәсәлән, бик күпләр төрледән-төрле конкурсларда ятлап сөйлиләр. Чөнки темасы халыкның йөрәгенә тия торган. Әти-әниле килеш балаларның ятим үсүе – безнең җәмгыятьнең чире, мөгаен, шуңа күңелгә якын кабул итәләрдер аны. Башка шагыйрьләрне алып карасак та, шушы ук күренешкә тап булабыз. Мисалга Зөлфәтнең «Мәхәббәт»ен, Мөдәррис Әгъләмнең «Бердәнбер»ен атасак та, җитәдер.

> Ә поэманың кадерсезгә әйләнүенә мин шаклар катам. Безнең язма әдәбиятыбызның үзәге, Кол Галиләр заманыннан калган, безне милләт итеп таныткан жанр ул.

Элек аңа караш икенче иде. Илдар Юзеев поэмаларын, мәсәлән, радиодан да укыдылар, йотлыгып тыңлый идек. Ул чакта поэмага кизәнмәделәр. Әдәбиятта һава торышын тудыра торган иптәшләр әлеге жанрда иҗат итми, мөгаен, шуңа тискәре караш барлыкка килгәндер.

:: Хәзер шигърияттә публицистика популяр.

– Публицистика – элек-электән көчле жанр ул. Дөрес, хәзерге көн проблемаларын бәреп әйтә торган шигырьләр Айдар Хәлимнән соң сүрелеп калган иде. Хәзер янә шытып килә. Бәлкем әле Айдар биеклегенә җитүчеләр дә табылыр.

:: Яшьләр шигъриятенә нинди бәя бирәсез?

– Көчле шагыйрьләр бар. Йолдыз Миңнуллина, Луиза Янсуар шигъриятен әйтүем. Ләкин ул – үзгә шигърият. Чөнки бу буын күп укый, дөнья әдәбияты үрнәкләре белән таныш. Ә без күбесенчә татар әдәбиятын укыдык, рус классикасын өйрәндек. Хәзерге шигъриятнең эпиграфларын гына кара: чит ил шагыйрьләре, философлары сүзләре язылган. Борынгы татар әдәбияты үрнәкләре бик азларында гына күренгәли. Мин моны начар дип тә, яхшы дип тә бәяләмим. Үзгә булуын гына искәртәм.

:: Сез берара үзегезнең иҗатны да онытып, ирегез Фаил абый Шафигуллин мирасын барлау, халыкка җиткерү белән шөгыльләндегез. Әле дә шул юнәлештә эшлисез. Максатыгызга ирештегезме, Фаил абыйны бүген беләләрме?

– Максатыма ирештем дип әйтә алмыйм. Бу тырышлыкны башкача бәяләүчеләр, начар сүзләр ирештерүчеләр дә булды. Хәер, ул – безгә хас күренештер. Каюм Насыйри да бит: «Милләт өчен 35 ел буе тырыштым, шуның кадәр үк кыен ашадым», – дигән. Шуның шикелле минем хакта да, Фаилне флаг итеп күтәрде инде, дигән сүзләр әйттеләр. «Кешелек тавы» дигән китабын чыгаргач (анда бер өлешендә – әдәби әсәрләре, икенче өлешендә мәкаләләре урын алган иде), чубен-чарын тутырып гонорар эшли, дигән сүз тараттылар. Юкса бер мәртәбә дә гонорар алганым булмады. Хәтта «Өй салуның ние бар?» дигән китабын чыгарганда, тәзүчесе икәнемне дә күрсәтмәделәр. Китапның мөхәррире Харрас Әюп иде, ул моны гонорарга бәйле, дип аңлатты. Юкса, төзүчесе мин икәне язылган китаплар чыккач та, гонорар артыннан йөргәнем булмады. Гомумән, акча сорап йөргәнем юк. Бирсәләр бирәләр, юк икән – юк. Әндәшми калу гадәтем бар. Әнкәй безне, сүз артыннан йөрмәгез, дип тәрбияләде. Әмма Ризван Хәмиднең бу китап турында: «Дуслары төзеп тапшырган кульязма китап булып чыкты», – дип бәяләмә язуы йөрәккә тиде. Нишләптер Ризван Хәмид миңа гомер буе каршы булды. Дөрес, Заһид Мәхмүди әлеге бәяләмәгә каршы бик зур мәкалә язды. Анда нәшрияткa да каты гына эләккән иде. Үзе әйтүенчә, шул хәлләрдән соң аның китапларына 12 ел буе юл ябык булган. Ә Ризван Хәмидкә килсәк, Фаилнең 50 еллык юбилеен үткәрүгә аяк чалырга бик тырышса да, нияте барып чыкмады. Гәрчә Фаилнең якын дусты саналса да... Ә бит Фаил аның күпме пьесасын редакцияләде, булдыра алганның барысын да эшләде. Алар инде үткәндә калды. Хатыны Гайшәнең «үлгәндә Ризванның теленДә синең исемең генә булды» дигән сүзләре – үзе бер гыйбрәт.

:: Эльмира апа, язучының иҗатташлары арасында дусты буламы?

– ... Мин башта үземне кагуларын Фаилне һәлак итүчеләрне эзләтмәсен өчен шулай кыланалардыр дип аңлый идем. Рәхәт тормыш кичермәдем бит. Элек дус булган кешеләрнең акрынлап ерагаюларын да шуңа бәйләп кабул иттем. Әмма алай гына булмаган шул... Бу сорауга җавапны, иҗат ялгызлыкны ярата, дип йомгаклап куйсак, хәерлерәк булыр.

:: Фаил абыйның үлем сәбәпләре нишләп ачыкланмады икән?

– Мин бер ел буе эзләттем, табылмады. Сәламәтлегем бөтенләй какшагач, прокуратура юлында йөрүдән туктадым. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, диләр. Икенче бер җинаятьне ачыклаганда очы чыкмасмы, дип тә уйлаган идем. Инде кырык ел да үтеп китте, «кыңгыр эш» ачылмады. Өметем өзелде.

Үзем исән чакта, хәлемнән килгәнчә аның әсәрләрен дөньяга чыгарырга тырышырмын. Аны бит бик яратып укыйлар. Урысча чыккан «Снег на голову» китабын гына алыйк, 50 мең тираж белән чыкты ул. Мондый тираж иң укыла торган китапка гына бирелә иде. Шушы китапны 10 ел чамасы элек Татарстан китап нәшриятына кабаттан бастырырга бирдем. Вафатыннан соң чыккан русча тәрҗемәләрен дә өстәп. Дөнья күрсә, иң укыла торган китап булыр иде. Күрәсең, китапның укылышлы булуы әллә ни әһәмияткә ия түгелдер. Бу кыенлыкларе күңелне төшерә, билгеле. Китабың чыкса, канатланып иҗат итә башлыйсың бит ул. Ләкин аңа карап иҗат туктамады. Матбугатта шигырьләрем басылып килә, редакцияләргә, редакторларга игътибарлары өчен бик зур рәхмәт.

:: Хатын-кызга әдәбиятта икенче төрлерәк караш бугай.

– Артыннан этеп баручы булса, җиңелрәк. Минем андый кешем булмады, мин иҗат белән, үз көчем белән яшәдем.

:: Сезнең быел юбилей елы. Үткән гомердән канәгатьме сез?

– Үземнең гомердән канәгать. Ләкин әйткәнемчә, Ходай биргән гомеремне рәхәт итеп яши алмадым. Тынычлык җитмәде миңа. Гомерем тоташы белән стресс хәлендә үтте. Билгеле, балаларым юанычым булды, иҗатым... Үземнең хисапка, кызларым да ярдәм итеп, «Толларның да җаны бар» дигән китабымны чыгардым, аңа сөенеп йөрим. Ул фәкать Фаилгә багышланган әсәрләрдән генә тора. Мин әле дә аның белән яшим.

:: Иң зур теләгегез нинди?

– Иң зур теләгем: татар гаиләләре үз туган телен чит итмәсен, какмасын иде. Заманнар авыр бит, телебезне күпсенүчеләр, кагучылар бездән башка да хәттин ашкан. Балалар нәселен, ата-анасын яратсын, милләте белән горурланып үссеннәр. Андыйлар туган телләрен белә дә, ярата да.

Татар гаиләләре бер бала белән чикләнмәсен, дип тә телим. Баланы тугансыз итү – бәхетсез итү бит ул. Без биш бала үстек. Менә хәзер авырган вакытта туганнарым булмаса, я балам берәү генә булса, дару белән генә тернәкләнә алмас идем. Әткәй-әнкәема туган җанлы итеп тәрбияләүләре өчен гел рәхмәт укыйм. Барыбызга да исәнлек-саулык телим.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

РАВИЛ САБЫР

ПАТИМӘТТӘЙ МАЛАЕ

(хикәя)

Равил Сабыр – журналист, язучы. «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Нефтяные вести» газетасы баш мөхәррире. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә үткәрелгән әдәби бәйгенең «Роман» номинациясендә «Фәхрине үтереп ташладылар» романы белән өченче урынга лаек булды.

Патимәттәй бүген персидәтелгә барган. Авылның хәбәрләр агентлыгы шундый яңалык тараткан иде берсендә. Әйтерсең лә, дөнья Татарстанны бәйсез дәүләт итеп таныган, бөтен кеше шуны сөйләде:

– Патимәттәй персидәтелгә барган бит әле бүген.

...Патимәттәй түгел инде ул – Фатима әби. Бик еш искә төшерәм мин аны – иң кечкенә чагымдагы Фатима әбине дә хәтерлим әле хәтта.

Дүрт-биш яшьләр булгандыр инде миңа, көн саен көтү каршыларга төшә идем. Кич җиттеме – мин күпер башында. Уйнап йөреп соңга калсаң, бөтен авыл буйлап эзләргә кирәк сыерны. Әллә нишләп кайтмый иде. Картайгач, гуләйт итүдән туктады үзе тагын. Шуннан соң, үзе кайта башлагач дигән сүзем, озак та тормады, чөгендер ашап күбенеп үлде. «Сыер апкайтырга» гына булса, бәлки, мин алай кич саен күпер башына атлыгып та тормас идем инде. Анда бит әле көтү кайтканын көтеп утырганда әллә ниләр ишетәсең. Син песи борчагын чемченеп утырганда хулиган сыерларның хуҗалары – авылның әби-бабае башларыннан үткәнне искә төшереп утыра, җыен кызык-мызык сөйлиләр шунда. Әби миңа көн саен бер уч кәнфит алып килә торган иде. Әле кәнфитнең дә ниндие – шоколадка манчылган чикләвек! Әле менә шушы юлларны язганда да авызда шул кәнфитнең тәме килеп китте. Хәлвә-хәлвә дип мең мәртәбә кабатласаң да, хәлвә тәме килми, дигән булалар тагын. Хәзер тәмле кәнфитләр күп, Фатима әби алып килә торганы гына юк.

Ә Патимәттәйнең персидәтелгә баруы ул – авыл гайбәтчеләре өчен азык кына түгел, безнең ише яза белмичә кәгазь пычратып утыручыларга рәхәтләнеп, тәмләп, озаклап, ләззәт кичереп язу өчен бер кызык вакыйга да.

Патимәттәйнең малае бар. Ул аңа Әлтәф дип исем кушкан. Тик әби – табигате белән тупасрак бәндә. (Әшәке тупас та түгел ул үзе. Хәер, аны ике сүз белән генә аңлатып та булмый, укый-укый аңларсыз әле, шәт.) Калын тавышлы үзе. Каты итеп сөйләшә. Шунлыктан улы Әлтәф исемле булса да, ул аны «Алтаф», тәгәрләгә, «безнең Алтаф» дип йөртә. «З»сы – Минзәләчә.

– Безнең Алтаф өйләнер иде ул. Имгәттеләр бит аны! Җан җиренә типтеләр яшь чагында.

Ә Әлтәф – мәңге дә өйләнмәс адәм затларының берсе. Аңа хатын кирәкми, аракы кирәк.

– Безнең Алтаф кайтырлык җиргә генә киткәнмени ул?! Тупачка киткән бит ул!

Тупач – сигез чакрым ераклыктагы күрше авыл. Шундый якын булса да, Патимәттәй сүзләрендә хаклык та юк түгел, чөнки Әлтәф Тупачка гусеничный трактор белән киткән.

Патимәттәйнең малаен сөеп, «безнең Алтаф» дип сөйләшүе авыл кешеләре теленә дә кучте. Берсендә шулай су буеннан кәшәкә сугып кайтабыз малайлар белән. Никтер иртәрәк кузгалынылган. Ә иртә кайтуыбызны без сәгатькә карап белмибез, бүтән нәрсәдән чамалыйбыз. Хикмәт шунда ки, көн саен без җыйнаулашып өйгә кайтканда Әлтәф гусеничный тракторы белән колхоз басуыннан кар тотып кайта да, үзенең бәрәңге бакчасына кереп, анда да бер-ике мәртәбә бөтерелә. Үз бакчасында кар тотудан бигрәк, җирне таптый гына инде. Ә теге юлы кайтып барганда иртәрәк кузгалуыбызны шуннан чамаладык, бакчада трактор юк иде. Бер малай әйтә:

– Иртә икән әле, безнең Алтаф та кайтмаган бит әле! – ди.

Сөендергән иде берсендә безнең Алтаф бала-чаганы! Озак уйлап тормаган, тоткан да Игәнәне буып куйган бу. Трактор үз кулында бит. Авылда буа кирәк, дип, ел саен сөйләшәләр иде.

Элегрәк бик шәп буа булган бездә. Тик Игәнәдә түгел, ә Минзәлә елгасында. Бик шәп он тарта торган су тегермәне дә булган. Бинасы хәзер әнә көтүлек уртасында утыра. Тимер койма ясап куйдылар да хәзер атларны шунда ябалар. Наратлы Кичүнең су тегермәненә бөтен якын-тирәдән килә торган булганнар. Бик сирәк кеше генә төбенә төшеп җитә алган. Су җибәргәч, балык җыя торган булганнар. Шуларны искә төшереп, картлар, буа кирәк, дип, гел сөйләшәләр әле. Әлтәф бер яртыны кәкрәйткән дә Игәнәне буып куйган. Сунның барыбер каяндыр агарга тиешлеге башына килмәгән инде моның, торба-мазарлар хуеп интекмәгән. Буып куйды – бетте-китте. Шундый шәп таптаган тракторы белән буа балчыгын, хәтта елга, юлын үзгәртеп, Әлтәф буасын әйләнеп ага башлады. И рәхәтләнгән иде инде безнең ише бала-чага! Башта елга үзәнендә калган балыкны капчыгы-капчыгы белән җыйдык, аннан соң, елга күтәрелгәч, су кереп рәхәтләндек. Чап-чоп сикерәбез ярдан, мин сиңа әйтим! Безнең Алтафка рәхмәтләр укыйбыз.

Тик болары соңрак булган хәлләр аның, ә буа буган көнне Патимәттәйне персидәтелгә барырга мәҗбүр иткән вакыйга болай булды. Әлтәф буаның эшен бетергән дә, кемгәдер ниндидер шабашка эшләп, балык сатканмы инде шунда, тагын бер ярты алган. Анысын да кәкрәйткән дә буаны, китмәсенгә, тагын да ныграк таптарга, ныгытырга уйлаган. Тракторына утырып буа өстендә бер-ике бөтерелгәч, чүт кенә төшеп китмәгән бу елгага. Ә колхоз персидәтеленә Әлтәфнең ни кыланып ятканы турында килеп сөйләгән булганнар инде. Персидәтел Әлтәф буасы янына килеп туктаганда, тегесе нәкъ төшеп китәргә маташа икән. Безнең Алтафны өстерәп чыгарган да хуҗа, ачуыннан селтәп торып җибәргән моны. Бөтерелә-бөтерелә тәгәрәгән безнең Алтаф.

– Сиксән яшьлек анаңны кем карар, дип уйлыйсың... фәлән-төгән, – дип акырган персидәтел. Әлтәф өенә кайткан да анасына, персидәтел кыйнады, дип әләкләшкән.

Икенче көнне Патимәттәй таң тишегеннән иртәнге нәрәткә кәнсәләр янына килә, ди. Һәрвакыт карадан киенеп йөри иде, мәрхүмә. Еш кына юарга хәле булмагандыр инде. Кара яулык, җиргә тиям-тиям, дип җилфердәп бара торган озын итәкле кара күлмәк. Бите дә кояшта күп йөреп каралган. Яулык читләрендә йөзенең кояш тимәгән урыннары күренгәләп китә. Көчле яңак. Иләмсез киң һәм очлы борын. Олы туры авыз. Бәләкәй кара күзләр. Сирәк каш. Тар маңгай. Җыерчыкларга баткан бит. Безнең Алтафны Патимәттәй киемнәренә киендерсәң, мөгаен, сирәк кеше аның Фатима әби түгел, ә Әлтәф икәнен таныр иде. Әбекәй тумыштан гарип кәкре бармаклары белән (алары да икесенеке бертөсле) яулык астыннан чыккан тыңлаусыз чәчләрен төзәтеп куя. Шул чагында тураебрак басмакчы була да, тик булдыра алмый – әби биленнән бөгелеп, алга авышыбрак йөри – картлык. Патимәттәй кәнсәләр төбенә килеп җитә. Чүгәләп тәмәке көйрәтеп утырган абзыйлар – бригадир-механик-мазарлар – тәмәкеләрен яшерә. Фазыл дигән берсе, исәнләшкәч, сорый әбидән:

– Патимәттәй, әле иртә таңнан нинди йомыш белән йөрисең?

– Менә, апаем, персидәтел кичә безнең Алтафны кыйнаган!

– Әйе шул, түтәй, мин дә күрдем. Сукты ул аңа, сукты! Хак, – ди Фазыл. Кызык кызыл. Калганнар мыек астыннан гына елмаеп тора. Әбекәйгә шул җитә кала:

– Мондамы ул персидәтел?

– Әйе.

– Кайсы ишек аныкы?

– Иң түрдәге уң яктагы ишек, түтәй, шунда утыра ул.

Патимәттәй – дөнья карчыгы – әкрен генә атлап кереп китә. Нәрәткә җыелган халык персидәтелнең ишек төбенә җыелып тыңлый. Әчтә мондый сөйләшү бара:

– Әби, исәнме! Иртә таңнан нишләп йөреш әле?

– Менә, улым, синең янга килдем әле. Син алай бик холыксызланма. Алай бик холыксызлансаң, яратмаслар.

– Ни сөйлисең син? Нәмәкәй булды тагын?

– Менә безнең Алтафка суккансың.

– Кем әйтә аны?!

– Менә кеше сөйли.

– Кем сөйли, кем?

– Менә әле яңа гына Фазыл да әйтте...

Ишек төбендә җыелып торган халык – ялт(!) урамга. Вакытында сызганнар, чөнки икенче мизгелдә үк ишеккә типкән тавыш ишетелә. Шунда ук ачуыннан кызарынган йөзле персидәтел килеп чыга да, урам ягына карап:

– Фазы-ы-ыл! – дип акыра. Тегесе башын иеп килә инде – каш ясыйм дип күз чыгаручы.

– Син Фатима әбигә ни сөйләдең?

– Соң, күргәнне әйттем инде, иптәш персидәтел, күрдем бит сукканыгызны...

– Кайча-а-ан? Бик алай очлы күзле булсаң, өеңә алып кайтып калхуздан урлаган әйберләреңне күрсәтермен мин сиңа, яптырный малахай!

– Кеше урлаганны без дә күрсәтә алабыз инде аны-сы...

– Сыпыр моннан!

Искә төшереп утырсаң, хәтер яңара икән дигәндәй, тагын бер кызык хәл бар икән әле. Берсендә әни, бәрәңге яргыч алып кайт әле, дип җибәргән иде Патимәттәйләргә. Килдем, җомышымны әйттем. Патимәттәй белән малае бәләкәй генә ишегалдыннан яргыч эзли башладылар. Тәртип юк инде анда, нине кайда тотып атканнар, шул килеш ята.

– Әле менә яңа гына шушында күргән идем җугыйса, – ди безнең Алтаф. Гел шул сүзне кабатлый.

– Бүтән кеше булса, эзләп тә тормас идем, Тәгъзимәнең файдасы бик күп тия бит, аңа бирмичә ярамый, – дип кабатлый Патимәттәй. Язын бәрәңге утыртканда әни аларга булышырга дип җибәргән иде мине, бер-ике сәгать селкенеп кайткан идем шунда. Һәрберсе үз сүзен сөйләп, бөтерелеп йөриләр болар. Ярты сәгатьләп эзләгәч, таптык тагын. Иске-москы такталар арасында яткан икән.

И-и-и, малай! Бар иде заманалар, диярсең. Хәзер, Патимәттәй булмагач, авыл ятим калгандай ничектер. Бер күңелле кешесе кимеде авылның. Әйбәт кеше иде, мәрхүмә. Авыр туфрагы җиңел булсын.

Безнең Алтаф та бик күңелле инде анысы. Болай булган берсендә.

Патимәттәй малае дүпел булып килеп кергән дә безгә, кухняда әзрәк утыргач, урындыктан идәнгә авып төшкән. Әйтеп-әйтеп караганнар да безнекеләр, селкенми дә, ди, теге. Шунда әни:

– Барыгыз әле, теге сыер бугы түгә торган тасны апкерегез, таска салып илтеп ташларга кирәк моны өенә, – дигән.

Селкенә башлаган безнең Алтаф. Шактый гына җәфалангач, торып баскан да бу: «Мин сезгә таска салырга чучкамыни», – дип мыгырдана-мыгырдана чыгып киткән.

Үткән җәйдә авылга кайткач, безнең Алтафны аның капка төбендә очраттым. Ихатасын карамый, урыс әйтмешли, бөтен нәрсәсе дә «на честном слове» гына тора. Исәнләшкәч, сорый бу:

– Әле укып бетердеңме, Равил?

– Менә бетереп кайтыш.

– Юарга кирәк дипломыңны!

– Син миңа үзеңнекен юдырттыңдыңмы соң?

– Юк бит минем диплом.

– Юктыр шул, – дидем мин һәм китеп бардым. Уйлап барам. Ни турында гына сүз чыкса да, барыбер аракыга очын чыгара безнең Алтаф. Хәтта бәяләрне дә, фәлән шешәлек, дип кенә җиффәрә. Йорт тиздән җимерелеп төшәчәк, өйләнү турындагы уй, күрәсең, башына ялгышып та килеп кермидер. Уйларымны Патимәттәй малаеның баз астыннан чыккан төсле калын тавышы бүлә:

– Рави-и-ил!

– Нәрсә бар?

– Әйдә авылга кайт, персидәтел итәбез сине.

– Ярар, – мин әйтәм.

Өйдә әни белән бераз безнең Алтаф турында сөйләшеп алабыз.

– Кичә кергән иде әле ипи сорап, – ди әни.

1995 ел

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 ЯЗЫЛ!
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
30 июньгә кадәр газетага язылучылар арасында ТАНДЫР уйнатабыз

6 айга язылу бәясе
П2435
җомга саны
488 сум 10 тиен
П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1099 сум 32 тиен

Квитанцияләр 5 июльгә кадәр кабул ителә. 7 июль көнне уйнатыла.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 7 июленә хәтле дәвам итә. Акциянe оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Тулырак: vatantat.ru 16+

Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат

тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

«АРЧА ОСТАСЫ»

Капка-коймалар, мангал, атынчыклар, бакча өчен урындык-өстәлләр, беседкалар, чардуганнар.

+7-906-326-82-68 Зәлфәт



Реклама



Рәис Габдулла

10 июнь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: микроб, гепард, Ибн, Фельцман, куду, Гус, кару, Агата, Ишим, он, тиз, ороч, вафля, Рем, арахис, Миякә, нисбәт. **Вертикаль буенча:** игелек, горур, Лучано, Роальд, чех, цукат, имән, бадәм, иваси, Риза, ямс, ингуш, фрак, ишле, әпә, Нәсим, ямь.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Татарстан гимны текстында нинди сүзләр юк?
А) «Халкым тели изге теләкләр»;
Б) «Бергә булсак, көчле беләкләр»;
В) «Яши бездә төрле милләтләр».

2 Быел 14 нче мәртәбә уздырылучы республикакүләм табиблар бәйгесе ничек атала?
А) «Ак халатлар»;
Б) «Ак чәчәкләр»;
В) «Ак йөрәкләр».

3 Идел буе федераль округына ничә төбәк керә?
А) 14;
Б) 15;
В) 16.

4 Татарстандагы шикәр заводлары кайсы районнарда урнашкан?
А) Зәй һәм Нурлат;
Б) Нурлат һәм Буа;
В) Зәй һәм Буа.

5 Быел Катарда узасы футбол буенча дөнья чемпионаты кайсы айда башлана?
А) октябрь;
Б) ноябрь;
В) декабрь.

Җаваплар: 1) Б; 2) Б; 3) А; 4) В; 5) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 284

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриринең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+